1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН
2021 ИЮЛЬ № 7

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398



бала табарга ҖЫЕНМЫЙМ
яңа модамы, әллә...

«Сөтлекәй» торты
ТӘМ ҺӘМ ТӨСЛӘР ярышы

РӨСТӘМ АСАЕВ
җырчыга нәрсә җитми

Ирина ЕРГИЗОВА: «Миңа бөтен ишекне дә туган телем ачты!»

Мин әни булдым, әни!

Мин әни булдым, әни!

Мин әни булдым, әни!

Шушы сүзне әйткән мизгелдә барысы да үзгәрә! Аралар тагын да якыная, җылына, күңелләр бер-берсен сүзсез дә аңлый... Бер үк кичерешләр аша узганнарның якынлыгы башка аның. Сүзләр, хәрәкәтләр, теләкләр бөтенләй үзгә төсмер ала. «Минә әни ни өчен ул вакытта шулай дигән, шулай эшләгән (яки эшләмәгән) икән», – дип уйлыйсың... Барысы да мәңгелекнең үзе кебек гап-гади, чөнки син – Әни! Ә Әниләр инде бер телдә сөйләшә...

Өр-яңа проект башлыйбыз. «Мин әни булдым, әни!» дип атала ул. Бер фоторәсемдә өч буын – әниегез, сез һәм кызыгыз (улыгыз): буыннар чылбыры шулай тезелә!

Җылылык, яктылык, нур бөркеп торган мондый фотосурәтләр сездә дә бардыр – кушылыгыз!



Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА

ИРТӘН

Бербөтен җиһанның мең телем өметен
Син узар сукмакта калдырам.
Син әле йоклыйсың, мин инде зарыгып
Син үтәр көннәрне сагынам.
Сагынам җилләрнең таң белән исүен,
Тибрәтеп тәрәзәң пәрдәсен.
Син әле белмисең,
Синең һәр карашың –
Күңелгә иң газиз бер рәсем.

Бербөтен гомернең мең өлеш җылысын
Калдырам син узар юлларда.
Таңнарда уянып, таңнарга куанып,
Чыгарсың бәхетең юлларга.

Багарсың күкләргә, йолдызлар күзләрсең,
Кып-кызыл алмалар өзәрсең.
Эзләрсең, табарсың, сер булып тамарсың,
Җуярсың һәм кабат эзләрсең.

Уң булсын бу җирдә син табар, син багар
Һәр энҗе, һәр тараф, һәр болын.
Юлыңа җанымның җылысын түшәдем,
Аңла һәм югалтма син, Улым!

■ Әбиемнең әнисен миңа күрергә насыйп булмады. Нәселебездә аның турында йөргән риваятьләрдән ишетеп беләм: Хөсниямал әби тугыз бала үстергән, коточкыч ачлык елларында да аларны саклап калган. Зирәк абыстай, дигәннәр аны. Ә улым бу яктан бәхетле – ул минем әбием белән үсә. Нурия әбиемә 92 яшь, улым белән аларның яшь аермасы – 90 ел. Әмма әбием әле бөтен дөнья яңалыклары белән кызыксына. Безгә балалар караша! Гомәр – аның алтынчы туруны.

Венера АИТОВА. Казан.

Фото: Анна Арахамия.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2021




Фото: Анна Арахамия

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Ирина Ергизова
Фото: Эрик Асаев

Мөхәррирләр
Чулпан Галиәхмәтова
Сөмбел Гаффарова
Алсу Шакирова
Фәгыйлә Шакирова
Верстка
Резеда Галиуллина
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр
Ильмира Сөләйманова
Олег Сердюк

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 1.07.2021 ел.
Чыгу көне: 6.07.2021 ел.
Заказ Е-2269
Тираж 9498

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы
ПАП рәсми каталогы буенча:
Татарстанда П2204 (ярты еллык),
П8299 (берьеллык)
Татарстаннан читтә: П0279

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+



Фото: Газинур Хафизов

Баш мөхәррир сүзе



Гаиләбез архивында кайнатама – шагыйрь Зөлфәткә татар әдибе, Башкортстанның халык шагыйре Наҗар Нәҗмидән 1996 елның көзендә килгән хат саклана. Журналыбызның бу санын әзерләгәндә кабат искә төшердем әле мин аны. «Синең миңа бүләк итеп җибәргән (бүләгең һәм игътибарың өчен зур рәхмәт!) китабыңны (*«Ике урман арасы» исемле китап турында сүз бара.* – Л. М.) ике шагыйрә – Дилә Булгакова, Халисә Мөдәррисова – миңа хастаханәдә чагымда китереп бирделәр. Хатны шуннан язам», – ди шагыйрь.

Бер-береңне якын итүләр әнә шундый гап-гади адымнардан тора бит ул...

«Дилә апа, табадан гына төшкән берәр яңа хикәягезне көтәбез!» (*Уфада яшәүче шагыйрә, язучы Дилә Булгакова белән сөйләшүдән.*)

«Зәлия, синең ярдәмең кирәк...» (*«Татар кызы» проектының Башкортстандагы җитәкчесе, «Роксана» радиосы дикторы, редколлегиябез әгъзасы Зәлия Ахунова белән шулай башланып киткән сөйләшүебез нинди генә үтенеч белән тәмамланмый?! Һәм әле аның берсен дә кире какканы юк! Сүз уңаеннан, бу санда «Без һәм алар» рубрикасында сорауларыбызга аның ире Руслан җавап бирә.*)


«Халисә апа, хәерле иртә. Сездә көн инде... Җибәргән «Балан» җыры тарихыгыз журналыбызда чыгып килә». (*Башкортстанда яшәүче шагыйрә Халисә Мөдәррисовага шалтыратудан.*)

Мондый мисалларны әле озак дәвам итәргә булыр иде.

Мин үзем – «Күрше хакы – Тәңре хакы», дип яшәүчеләрдән. Әлеге мәсьәләдә фикердәшләрем бихисап дип беләм. Якын итү – очрашулар, күрешүләр, тәмле һәм гамьле әңгәмәләр аша ныгый. Бу санны тоташ «Сөембикә – сәяхәттә» дигән рубрикабыз белән исемләргә була. Сәфәребез – Башкортстанга, күрше республикада гомер итүче милләттәшләребез янына...

Яратып,
Лариса МАЛИКОВА.

Безнең тышлыкта





10

«2012 елда «Ел укытучысы» бәйгесендә катнаша һәм җиңүчеләр исемлегенә керә. Шул елны аңа «Башкортстанның атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем дә бирелә. Сер түгел, бу дәрәҗәгә укытучылар укучыларының уңышлары аша килә.»


Кылган
Гөлнур Сафиуллина

Заман һәм без

6 Мин – чайлдфри яки Бала кирәкми миңа!
Чулпан Галиәхмәтова



14 Әдәби марафончы
Гөлнур Хәсәншина



16 «Тормыш хәзер фейерверк...»
Чулпан Галиәхмәтова

ЭЧТӘЛЕК

Татар дөньясы



18 Көндәлек
Гөлнур Сафиуллина



22 Җырланасы җырлар бетмәгән...
Эльмира Закирова

Мәдәни тормыш




28 Күлмәк
Дилбәр Булатова



34 «Нур»: кабатланмас һәм бердәнбер
Алсу Шакирова

Яшәеш



40 «Яратудан туган бала түгел мин...»
Чулпан Галиәхмәтова



48 Зөһрәкәй
Люция Камаева-Гафури

Хуҗабикә

57 Җәйге макияж
Чулпан Юнысова

58 Чират – балконга
Алсу Шакирова



60 «Сөтлекәй» торты

МИН – ЧАЙЛДФРИ ЯКИ БАЛА КИРӘКМИ МИНӘ!



Моңа кадәр сабый һәм ана җәмгыятьнең культы иде. Әмма вакыт барган саен, карашлар да, кыйммәтләр дә үзгәрә. Бүген алдынгы карашлы, белемле яшьләр бала тәрбияләүдән аңлы рәвештә баш тарта. «Минем ирекле булып яшисем килә», – ди алар. Баладан ирекле булып... Җәмгыять – тере организм, һәрвакыт хәрәкәттә. Тарих спираль буенча кабатлана, дибез. Әмма ул яңа төсмерләр белән баетыла да әле. Яңа кыйммәтләр барлыкка килә, яңа геройлар, яңа күренешләр, яңа хәрәкәтләр... Чайлдфри хәрәкәте дә – шундыйлардан.



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Үземне генә яратам

Инглиз теленнән «баладан ирекле булу» дип тәрҗемә ителә ул. Бу хәрәкәт 1970 нче елларда АКШта барлыкка килә. 1990 нчы елларда әлеге идеягә теләктәшлек белдергән кешеләр, берләшеп, шул хәрәкәтне тудыра. Сүз – репродуктив функциясе яхшы эшләсә дә, аңлы рәвештә бала тапмаган хатын-кызлар турында. Россиягә ул 2000 нче еллар башында килеп кереп, яшьләр арасында тарала. Моңа интернет, социаль челтәрләр сәбәпче. Әлеге хәрәкәткә кушылучылар саны бермә-бер арта башлады. Дәүләтнеке булмаган тикшеренүләр оешмасы халык арасында сораштырулар үткәргән. 45 яшьтән яшьрәк хатын-кызлар һәм ирләрдән ничә бала табарга теләүләре турында белешкәннәр. Нәтиҗәләр буенча, уртача сан 1,8 процент тәшкил иткән. Россиялеләрнең 9 проценты бөтенләй бала табарга җыенмавын әйткән. Дөрес, башка илләр белән чагыштырганда аз кебек тоела бу. Мәсәлән, АКШта 40–44 яшьлек хатын-кызларның – 15 проценты, ә Австрия, Испания, Бөекбританиядә 20 проценты баласыз. Әмма Россиядә бала табучыларга өстенлекләр бирелгән, җәмгыятьтә күпбалалык тренды киредән кайтарылган чорда 9 процент сизелерлек сан. Уйланырга җирлек бар. Белгечләр әйтүенчә, аңлы рәвештә баладан баш тарту, нигездә, алга киткән илләргә хас. Бу күренеш икътисадый яктан яхшы тормыш алып барган, белемле халык арасында күбрәк икән. Моны да аңлатып була: укымышлы кешеләр – алдынгы карашлы, җәмгыятьтәге стереотиплардан азат катлам. Ә калыплашу – җәмгыятькә хас күренеш.

Кеше тугач ук кысаларга кертелә. Исегезгә төшерегез әле, кечкенә чакта өстәл почмагына уты-

рырга курка идегезме? Курыкмасагыз да, өлкәннәрнең анда утыртырга теләмәгәнен хәтерлисездер. Урының өстәл почмагына туры килә икән, димәк, кияүгә чыга йә өйләнә алмыйсың. Кеше тормышында бу иң зур җәза дип кабул ителә иде. «Токмач кисә белмәсәң, кияүгә алмаслар» дигәннәрне безнең буын кызлары ишетми калмагандыр. Ашарга пешерә белмәгән хатын кемгә кирәк?! Кияүгә чыга алмый калудан да хурлыклырак хәл – җилдән бала табу гына иде. Шуңа күрә дә булачак иребезгә ярарга тырышып, бармакларны кисә-кисә токмач кисәргә өйрәндек. Бөтен аңлы гомеребездә хатын һәм ана булырга әзерләндек. Бәхетең иреңнән һәм балаларыңнан булсын дигән теләкне бер мин генә ишетеп үсмәгәнмендер дип уйлыйм. Без тугач ук кем өчендер яшәргә кирәк дип белдек. Ә хәзерге яшьләрнең үзенеке үзәктә – «үзем өчен яшим» дигән принцип белән үсәләр. Һәм моны ата-аналар да, психологлар да даими рәвештә тукып тора. Үзе өчен яшәгән кеше нигә әле башкалар турында кайгыртып җәфалансын соң. Психология фәннәре магистры, психолог Чулпан Нигъмәтҗанова бүгенге көндә чайлдфри хәрәкәтенең популярлашуын да шуннан күрә.

– Хәзер гаилә институты үзгәреш кичерә. Элек традицион җәмгыятьтә гаилә диюгә әти, әни һәм, һичшиксез, бала күз алдына килеп баса иде. Ирнең – үз, хатынның үз функциясе. Әти – гаилә башлыгы. Ул ашатучы, акча табучы, гомумән, бик абруйлы кеше. Әни исә гаилә учагын саклаучы, бала тәрбияләүче. Бала – нәсел дәвамчысы, картлык көнендә ярдәмче. Хәзерге көндә әлеге күзаллау башкача. Күп гаиләләрдә тормыш дилбегәсе – хатын-кыз кулында. Шушыннан чайлдфри агымы популярлашуның икенче сәбәбе килеп чыга – хатын-кызлар эмансипациясе, ягъни төрле социаль бәйлелектән азат булырга тырышу, тигез хокук даулау. Хатын-кызның ир күләгәсендә, бала чүпрәкләренә күмелеп яшисе килми хәзер. Алар карьера ясарга, финанс яктан үз-үзен тәэмин итәргә омтыла. Шул рәвешле, җәмгыятьтә производствода катнашуда хатын-кызның роле арта. Ул үз бизнесын ача, үз өстенә күп җаваплылык ала. Максатларга ирешкәндә балалар киртә булачак дип уйлый. Өченче сәбәп – традицион кыйммәтләр үзгәрү. Элек яшь кызлар кияүгә чыгу турында хыялланып яшәгән. Иртәрәк кияүгә чыксаң, күп һәм сәламәт балалар табу мөмкинлеге зуррак дип санаганнар. Алар 18–20 яшьтә бала тапсалар, хәзер, статистика күрсәткәнчә, хатын-кызларда, нигездә, 30 яшьтән соң гына ана булу теләге туа. Аннан соң җәмгыятьтәге икътисадый вазгыять тә тәэсир итми калмый. Иртәгәсе көнгә ышанычы булмаганнар арта.



Психология фәннәре магистры, психолог, арт-терапевт Чулпан НИГЪМӘТҖАНОВА: «Иртәме-соңмы кешедә ялгызлык хисе уяна: гаилә төзү, бала табу теләге туа. Күп кенә чайлдфриларның билгеле бер яшькә җиткәч, фикере үзгәрми калмый».

Фото: www.pixabay.com

Психолог сүзләрен хуплап шуны әйтәсе килә, хәзерге яшьләр бала табуга үтә зур җаваплылык белән карарга тырыша. Табу гына түгел, аны үстереп кеше итәсе дә бар бит әле! Элек бала табу нәсел дәвам итү инстинкты буенча барган. Ата-ана да иң элек баланың сәламәтлеген кайгырткан, ягъни авырмасын да, тамагы тук булсын. Хәзер тәрбия моделе башкачарак: сабыйның психологик халәте, аны үстерү, укыту өчен шактый чыгымнар кирәген уйлап борчылабыз. Аннан соң гына нәсел дәвам итү инстинкты искә төшә. Элек сексуальлек һәм бала табу функциясе бергә үрелеп барса, хәзер алар аерылды. Яратышу – бала тудыру өчен түгел, ә иң элек ләззәт алу өчен, һәм хәзерге заманда моңа табу юк. Шуңа да замана хатын-кызлары бала табарга ашыкмый. Гаилә коруга да, бала табуга да фикерләр төрле булырга мөмкин. Яше кырыкка авышкан танышым бар. Без бер-беребезне җәллибез бугай. Тормышым балалар мәшәкатеннән торган өчен ул мине кызгана, ә мин аның сабый сөя алмавына борчылам. «Бала табу теләге бөтенләй юк. Теләк булса, таба алмас дип уйлыйсыңмы? – ди ул. – Үзең күрәсең, бер түгел, ике бала үстерерлек мөмкинлегем бар. Әмма ана перспективасы бер дә сөендерми. Бала һәрвакыт үзенә игътибар сорый, артыннан җыярга кирәк. Өйдә бөтен нәрсәнең асты-өскә киләчәк. Ә мин чисталык, пөхтәлек яратам. Минем өйдә кухня – ашау урыны, зал – ял итү өчен. Балалары булган гаиләләрдә күрәм: бөтен җирдә – ризык валчыгы, обойлар – «иҗат дивары», зал уртасында – чүлмәк. Кечкенәсе елый, үзе зурысы белән дәрес әзерли. Миңа калса, бала тапкач, башның ял итү дигән функциясе бөтенләй эшләми башлый бугай. Кирәкме ул миңа? Әлегә ялгызым да бик рәхәт. Иптәш кирәк була башлагач, бәлки, кияүгә чыгармын. Әмма бала тапмаячакмын. Картлык көнендә кем карар, балалар – тормыш бизәге дигән сентименталь фикерләр турында уйлаганым да юк. Карап үстергән балаң киләчәктә синең ярдәмчең булырмы? Беркем гарантия бирми. Җитмәсә, хәзер балаларны үзебез өчен тапмыйбыз дигән төшенчә киң массага тарала. Еракта балам яши дигән уй картлыкта җиңеллек бирер дип уйлыйсыңмы әллә?» Кызганыч, аның сүзләрендә хаклык бар, һәм ул фикер көннән-көн ныгый. Иң элек үзеңне уйла, үзең өчен генә яшә, син беркемгә бернәрсә дә тиеш түгел дип лаф орып, марафон, тренинглар үткәргән псевдопсихологлар саны



Миңнур ӘХМӘТОВА, нейропсихолог, коуч, трансформацион тренер, психолог. Мәскәү шәһәре.

Статистикага күз салсак, Россиядә ел саен 11 мең яңа туган баладан баш тарталар. Бу – ата-ана баланы инстинктив рәвештә генә тудырган дигән сүз. Ә баланы шул рәвешле дөньяга китерү – мәгънәсезлек. Яшь кеше аңлы рәвештә җаваплылык хисен аңлап, үзенең моңа әзер булмавын анализлап, ата-ана булуны кичектереп тора икән, моны үзаңы үсү дип аңлыйм һәм сөенәм. Хатын-кыз бала табарга тиеш дигән җәмгыятьтә стереотиплар таләп иткәннән генә тудыралар икән, мәхәббәт булмаячак. Балага карата ваемсыз, каты бәгырьле булу – агрессив яшь буын барлыкка килүгә җирлек ул. Мине кыйнап үстерделәр, мин дә шулай үстерәм, дип, сабый тәрбияләү дөрес түгел. Балачагында эчкечелек, мыскыллау, көчләү үткән кеше, бүген үз баласына матурлык, җылылык бирә алмавын аңлап, мин әлегә бала табарга әзер түгел ди икән, бу бик акыллы адым дип саныйм. Чайлдфри хәрәкәте кешелекне бетерәчәк дип чаң сугарга да кирәкми. Теләсә кайсы хәрәкәт, секта, дәүләт теләктәшлек күрсәтмәсә йә каршы чыкмаса, әкренләп популярлыгын югалта башлый. Чайлдфри белән дә шулай булачагына шикләнмим. Ә менә бала тәрбияләүнең максатчан, системалы, аңлы процесс икәнен аңлап, яшьләр баланы соңрак таба икән, бу начар күренеш түгел.

көннән-көн арта. Монысы инде гаилә кыйммәтләрен юкка чыгаруны күздә тоткан мәкерле сәясәт. Аңсыз психологлар исә әлеге фикерне алга сөрә. Психолог Чулпан Нигъмәтҗанова да җәмгыятьтә шундый пропаганда алып барылганын таный. «Кеше шәхес булырга тиеш, иң элек үз мәнфәгатьләреңне кайгырт, дип күп сөйлиләр хәзер. Исегезгә төшерегез, элекке традицион җәмгыятьтә андый төшенчәләр бөтенләй юк иде. Ул вакытта гаиләңне яратырга, гаиләңне уйлап яшәргә кирәк, диделәр. Кешенең бөтен байлыгы гаилә дип аңлатылды. Ә хәзер, әйткәнемчә, башкача сукалыйлар. Билгеле, көнетөне бу хакта ишетеп торгач, хатынкызлар үз-үзен үстерү турында уйлана башлыйлар, гаилә артык булып чыга, шуңа да чайлдфри агымы көчәя», – ди психолог.

Инфантильлек – чайлдфрига китерә дигән фикер дә дөрес. Безнең әбиләр заманында 25 яшьлек хатынкыз зур гаиләсе, тормыш тәҗрибәсе булган кеше итеп кабул ителсә, хәзер исә күп очракта ул яшьтәге кызлар – ата-ана җилкәсендә утыручылар. Үз артыннан да җыеп йөри алмаган хатын-кыз ничек итеп бала табып тәрбияли алсын?! Аның инде иркә баласы бар: ул – үзе!

Ярату җитмәгән балалар

Чайлдфри барлыкка килүгә иң элек гаилә сәбәпче. Парадокс кебек, әмма чынбарлык. Үзләрен бу хәрәкәттә санаучылар, нигездә, кечкенә чакта яратудан мәхрүм балалар. «Гаиләдә стресс кичергән йомшак холыклы бала потенциаль чайлдфри була ала. Әни белән әти арасындагы авыр мөнәсәбәт, үзенә карата атаанадан даими агрессия аның күңелендә эз калдыра. Үскәч, ул гаилә корырга йә курка («ирем дә эчкече булса», «мин дә әни кебек корбан булып яшәсәм», «балаларга назым җитмәсә»!), йә теләми, чөнки аның күзаллавында – гаиләнең негатив моделе генә. Тагын да аянычлысы: ана назын күрми үскәннәрнең күңелендә балага карата мәхәббәт дигән төшенчә юк, ул аны күрсәтә белми. Сабыйлар яратмыйм, миңа бала кирәкми дигән установка белән яшиләр», – дип аңлата психолог.

Ачыктан-ачык сөйләшер өчен чайлдфриларны озак эзләргә туры килде. Үзен әлеге хәрәкәткә кертүчеләр бик күп, аларның социаль челтәрләрдә махсус төркемнәре бар. Әмма бу хакта матбугатта кычкырып сөйләргә теләмиләр, бигрәк тә татар хатыннары һәм ирләре. Җәмгыятьнең алар фикерен адекват кабул итәргә әзер түгеллеген аңлыйлар. Ә кемнең күрәләтә тәнкыйть амбразурасына капланасы килсен?! Тимәсеннәр генә, ә фикерләренә карата хөрмәт даулап йөрергә аларның теләге юк.

– Башка чайлдфрилар белән чагыштырганда, мин ачык кеше. Фикеремне әйтергә дә курыкмыйм. Сөйләгән сүзләремне бөтенләй үзгәртеп язсагыз да, исем китми, чөнки үз дөреслегем бар, калганы сезнең намуста, – дип башлады сүзен Анастасия.

Ул минем белән видеошалтырату аша «очрашырга» риза булды. Стильле итеп киселгән җирән кыска чәч, маникюрлы яшел лак сөртелгән тырнаклар. Каш янында кечкенә генә пирсинг. Макияжсыз киң йөз. Бит чалымы шадрарак. Анастасиянең кем булып эшләве белән кызыксынам.

– Һөнәрләрем күптөрле: дрессировщик, бармен, кинолог, автомеханик, тимер коючы... (Бер хатын-кыз һөнәрен дә искә алмагач, нәтиҗә чыгарам: йә традицион карашлы хатынкыз түгел, йә трансгендерлы кеше, сөйләшү тагын барып чыкмый.) Ирем көлә инде тагын нинди ир-ат һөнәре калды әле син өйрәнмәгән, ди. (Эчемә җылы йөгерә, әмма шикләнәм.) Бу тормышта үз урынымны табар өчен теләсә нинди эшкә алынырга риза идем. (Хәлне аңларга тырышып, балачагы турында сорыйм.) Төрмәдә туган бала мин. Әни вак җинаять кылып, төрмәгә эләгә. Авырлы хатын-кызларны вакытыннан алда чыгаруларын белеп, авырга уза, әмма аны чыгармыйлар. Мине Балалар йортына җибәрәләр. Бер елдан соң ул мине килеп ала. Тик ник кенә килеп алгандыр?! Безнең әни кадәр кансыз хатын-кызны шушы яшемә җитеп күргәнем юк. Апа бераз үскәч, җирле үзидарәгә барып, Балалар йортына җибәрүләрен үзе сорады. Ул анда китте, әнине ана хоку-

кыннан мәхрүм иттеләр. Безнең әти нык әйбәт кеше иде. Совхозда аның кадәр мировой ир булмагандыр. Т-150 тракторын йөртте. Мин аның янында үстем. Шуңа да кыз-малайга әйләнгәнмендер. Тракторны сүтеп җыярга әти өйрәтте. Кечкенә булсам да, руль артына утырып йөри идем. Үз әтием булмаса да, үз кызы кебек якын күрде, мин дә бик яраттым. Инде күптән үлде, әмма ата мәхәббәте күңелемдә яши. Әти үлгәннән соң тормышым җәһәннәмгә әйләнде. Әни авырлы булып калган иде. Энемне тапты да депрессиягә бирелде, тормышка, безгә битараф иде, бик озак психоневрологик хастаханәләрдә ятты. Миңа ул вакытта 11 яшь. Өч ел буе энемне үзем генә үстердем. Әллә мин дә Балалар йортына китим микән дигән чакларым күп булды, әмма кечкенә энемне җәлләдем. Аның бит бер гаебе юк. Ә мин бала карый белмим. Күршедән-күршегә кереп, даруханәләргә барып сораша-сораша, аны юындырырга, ашатырга өйрәндем. Аның әнисе кебек идем. Тәпигә басуын да, беренче тешләрен дә мин күрдем. «Гомеремдә бала тапмыйм», дип, үз-үземә сүз биргәндә миңа 14 яшь иде. Әлегә кадәр ул фикерем үзгәрмәде. Хәзер энемә 14 яшь. Аның белән аралашабыз, әмма әни белән сөйләшмим. Юк, аңа үпкәм юк. Әмма сөйләшерлек сәбәп тә тапмыйм. Кем ул миңа?

– Сине дөньяга тудырган ана, – дим.

– Ә мин тудырырга сорамадым. Ул үз мәнфәгатьләрен кайгыртып бала тапкан. Мине яратканы булмады да. Тәрбияләмәде, кайгыртмады. Ә ник аңа әни дигән изге сүзне әйтергә тиеш әле?! Бүгенге тормышымнан зарланмыйм. Мин – ирекле. Телим икән парашюттан сикерәм, телим икән ипподромга барып атта чабам, телим икән сәяхәткә чыгып китәм. Үсмер чагымда кичергән газапларым исемә төшсә, дертләп китәм. Тагын шул газаплар аша үтәргә теләмим. Ирем белән өйләнешкәнгә дүрт ел. Алдан ук бала тапмаячакмын, дип әйттем. Аңа кадәр очрашкан егетләр бу сүзне ишетүгә югалалар иде, ә ул янымда калды. Бала тели башлый икән, мин аны тотмыйм, дүрт ягы кыйбла. Әй, курчагым минем, син нишләп берүзең генә чыктың, матурым, – подъезд төбендә эскәмиядә сөйләшеп утырган Анастасиягә бер кызчык килеп сыенды. Алар берара кочаклашып сөйләшеп торды. – Күрше кызы, – дип аңлатты ул. – Күрше балалары шулай йөгереп килеп, кочаклап алып, исәнләшеп китәләр. Балаларны бик яратам.

– Балалар яраткач, тапмый калмассыз әле. Алда бит картлык та бар.

– Юк, тапмыйм. Өемдә бала тавышы беркайчан да ишетелмәячәк. Тынычлык һәм иректән рәхәт нәрсә юк. Кайнанам да, ничек инде өегездә бала булмаячак, картлык көнендә бер стакан су кем китерер, дип аптыратып бетерде. Кинолог курсларын тәмамладым да овчарка сатып алдым. Миңа су алып килеп бирергә, кибеттән азык-төлек алып кайтырга өйрәттем. Исемлек язылган кәгазьне, акчаны сумкага салам да кибеткә җибәрәм. Хәзер кайнанам да онык дип авыз ачмый. Балага гомеремне багышларга һич теләгем юк! Үземне бик нык яратам. Эгоист кеше башкаларны ярата алмый ул. Ә яратмагач нигә бала табарга? Җәмгыятьнең авызын ябу өчен генәме?! Кеше фикере мөһим түгел, үзем өчен яшим.

Чайлдфрилар, нигездә, 20–30 яшьлек кешеләр. Ә 40 яшьләргә җиткәндә фикер сөреше үзгәрә. Бәлки, ялгыз калу куркыта башлыйдыр. Психолог та үзен чайлдфри дип йөрткән бер клиентының нәә шул яшьләрдә бала табуы турында сөйләде. Барлык максатларына ирешкәч, бала сөясе килү теләге туган аның, чөнки ялгызлыгын тойган, картлыгы турында уйлана башлаган. Үзенә әни дип эндәшүләрен ишетәсе килгән. Ана инстинкты уянган. Табигатьтән салынган әлеге инстинкт кайчан да булса баш калкытмый калмый, күрәсең. Улыгыз йә кызыгыз көннәрдән бер көнне «мин – чайлдфри» дип кайтып керә икән, баштагы чәчне йолкыйсы түгел, бу хәбәрне тыныч кына кабул итәсе. Биргән тәрбиягезне анализлап, төзәтеп җибәрәседер, бәлки. Баланы ныклы рухлы итеп үстерү генә, хәзерге җәмгыятьнең катаклизмнарыннан саклап каладыр. Бу хәрәкәтнең хәзер модада икәнен дә онытмагыз, ә мода ул гел үзгәрештә...



Гөлнара НУРМӨХӘММӘТОВА,
өч бала әнисе,
бизнес-леди

Чайлдфри хәрәкәтендә булучылар минем өчен башка планета кешеләре кебек. Аларны аңларга да, акларга да теләмим, үзләре турында уйлаучы эгоистлар итеп кабул итәм. Балалар безгә кирәкми дип фикер йөртүчеләр үзләренә каршы килә. Уйлап карыйлар микән: бу дөньяда ничек барлыкка килгән соң алар? Табигатькә каршы бару бу! Андый каршылыклар булганда дисбаланс килеп чыга. Күпме генә бәхетле булулары турында сөйләсәләр дә, күңелләренең бер почмагы белән бәхетсезләр. Балалар бит ул зур тәҗрибә мәктәбе. Балаларсыз үземне күз алдына да китерә алмыйм. Өченче кызыбыз тугач, улларым: «Әни, син безне дә шулай карадыңмы?» – дип сорыйлар. Минем ана ролемне читтән күзәтеп, шулкадәр сокланалар. «Һәрберегезне шулай назлап үстердем», – дим. Аларда мәрхәмәтлелек хисе уяна бит. Безнең җәмгыятьтә көнбатыш психологиясен популярлаштыручы, әбиләребез кебек, кешеләрдә миһербанлылык тәрбияләсәләр, бу дөньяда бәхетлеләр күбрәк булыр иде. Мәрхәмәтле хисе йөрәккә үтеп керсә, бернинди психологиянең керәге калмый, чайлдфри кебек агымнар да булмаячак.

КЫЛГАН

– Кечкенә чакта гел: «Кылган!» – диләр иде. Чәчем шундый төсле булганга әйткәннәрдер инде. Безнең нәселдә бөтен хатын-кызлар да бертөсле: аксыл чәчле, зәп-зәңгәр күзле... Чынлыкта, кылган инде мин, кылган!.. Мин дә шулай дим! Җилдә тирбәлеп утырган кылган читтән генә йомшак күренә. Тик юри генә өзеп кара син аны! Җилләр иркенә кушылып йөгергән кебек тоелса да, беркайчан да аларга иярми ул. Иринаның холкындагы ныклыкка да шаккатарсың! Туры сүзле, үз фикерен өздереп әйтә белә: чәүкәләр арасында ала карга булып күренүдән курыкмый. Бер эшне дә ахырына кадәр җиткермичә туктамый. Дөресрәге, «иң яхшысы» дигән сүзне ишетмичә туктамый. Башкортстанның атказанган укытучысы Ирина ЕРГИЗОВА күрше республиканың Бүздәк районы Әмир авылы мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта. Туган телебезнең бүгенгесе, киләчәге белән бәйле һәр сүз иң элек аның да җанына, йөрәгенә кагыла.

– «Кызыгызны татарча гына сөйләштерсәгез, ул гел башта татарча уйлаячак, аннан соң гына шуны русчага тәрҗемә итеп әйтәчәк», – ди. Русчага күчәргә куша...

Алар без килгәч кенә район үзәгеннән – Бүздәктән кайтып төштеләр. Әле алты яшь кенә тулган кечкенә кызларын быел беренче сыйныфка укырга бирергә җыеналар икән – белгечләргә күренгәннәр. Аларның берсе исә әнә шундый киңәш биргән.

Иринаның күңеле тәмам урыныннан купкан иде: ярый ла аның да, иренең дә бу мәсьәләдә үз фикерләре бар. Ә бу «киңәш» башка җирлеккә эләксә?

– Гомерем буе татарча сөйләшеп яшәдем! Бөтен ишекләрне дә миңа туган телем ачты!

Юлларның беркайчан җиңелен сайламаган Ирина.

«Чын укытучы буласың килсә, Бәләбәй педучилищесына бар», дигәннәрен ишетеп, мәктәпне тәмамлагач, шушы уку йортына чыгып китә ул. «Йөрергә җайлырак булыр, өйгә якынрагын сайла», – дип әйтүләреннән куркып, кая барганын өйдәгеләргә белгертеп тә тормый. Үзенең киләчәктә балалар укытачагын исә беренче класска керүгә хәл итә: Сәкинә Фарукшовна кебек булачак! Әниләре ул чакта: «Яхшы укытучыга эләксен», – дип, юкка гына Иринаны мәктәпкә алты яшьтән бирмәгән шул.

Белемгә, белем бирүгә тартылу – аның канында: һөнәр сайлаганда анысы да зур роль уйнагандыр. Бу төбәктәге иң укымышлы затлар, якын-тирәдәге барлык мәктәп-мәдрәсәләрне оештырган Ямгетдин һәм Миргасыйм картлар оныгы ул. Иринаның Миргасыйм картәте китап укырга яраткан, көндәлек алып барган, ул көндәлеккә кайсы китапны һәм ни өчен укырга тәкъдим итүен дә язып барган. Әлеге дәфтәрләрдә: «Бүген Диләрәнең беренче кызы туды», – дигән юллар да сакланган. Монысы Ирина турында була инде... Казаннан журналлар яздырып ала торган була картәтәе. Аларның берсен дә ташламыйча җыеп барып, елын-елга теркәп, китап итеп теккән. Мулла бабасы яратып укыган журналлар арасында Ирина бик хәтерләп калган «Азат хатын» да була. Ә картәтәенең этисе Ямгетдин Владимир Ульянов белән бергә укыган, диләр! Аларның бергә төшкән фотосурәтләре дә булган. «Миргасыйм абзый ул фотоны мәктәпкә безнең белән очрашуга алып килгән иде, парталар буйлап йөртеп карадык», – диючеләр авылда бүген дә бар. Кызганыч, фото үзе генә югалган. Әмма заманында нәкъ менә шул рәсем Ямгетдин мулланың гомерен саклап кала. Авылның указлы мулласын зират артына атарга алып чыккан булалар инде...

Ирина да: «Укырга яратам. Миңа көн саен һичьюгы бер бит булса да китап укырга кирәк», – ди. Белемгә омтылу, телгә мәхәббәт аны педагогика училищесыннан соң Башкортстан дәүләт университетының филология факультетына алып килә. Аны читтән торып укып тәмамлый.

Университетка укырга кергән елны ук үзләренең күрше Әмир авылында татар теле һәм әдәбияты укыта башлый. 1997 ел була бу. Үзе әйткәндәй, эшкә чума, йөзә, эштә яши! 2012 елда «Ел укытучысы» бәйгесендә катнаша һәм җиңүчеләр исемлегенә керә. Шул елны аңа «Башкортстанның атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем дә бирелә. Сер түгел, бу дәрәҗәгә укытучылар укучыларының уңышлары аша килә. Балалар татар телен яратсын, аның белән кызыксынсын, татарча сөйләшсен өчен Ирина Фларит кызы ниләр эшләгән? Моңа нинди юллар белән ирешкән? Үзе генә белгән серләре бармы?

– Мин бөтен нәрсәне дә гел чагыштырып аңлатам. Грамматиканы да. Башта татарча әйтәм, русча, аннан немецча. Әйтик, аергыч: аның соравы шул ук, шулай ук сызыла, бер үк нәрсәне аңлата, исемгә ияреп килә... Укучы боларның берсен исендә калдырса, икенчесен дә хәтерләргә тиеш.

Ә нигә немецчамы? Җавабы бик гади: Ирина ханым соңгы елларда мәктәп балаларына алман телен дә өйрәтә. Үзләрендә генә түгел, күрше Килем авылында да. Монысы – замана таләбе. Мәктәп программасына өченче тел килеп кергәч, аңа кабат парта артына утырырга, мәктәптә, югары уку йортында алган белемнәрен яңартырга, баетырга туры килә. Кайчандыр мәктәптә немец телен аңа Алжирларда эшләп кайткан Светлана Әмировна укыткан. Бу телгә мәхәббәтне дә шушы укытучы уяткан. «Без башта аның үзенә гашыйк булдык. Киеменә, үз-үзен тотышына... Хушбуеның исенә... Аннан – ул укыткан фәнгә», – ди Ирина.

– Фәнне ярату – укытучыга гашыйк булудан башлана. Үзеңә каратып булса да, телне яраттырырга кирәк, – дип саный ул.

Элеккеге укучылары сагынып киләләр дә, гел бер сүзне сөйлиләр: «Ирина Фларитовна, хәтерлисезме, мәктәптә нинди генә чара үткәрсәк тә, сез безгә үз киемнәрегезне кидертә идегез. Матур киенә идегез! Сезнең кебек буласыбыз килә иде!»

– Уртанчы кызым көлеп: «Әни, кайбер кеше туйга да син эшкә җыенган кебек җыенмыйдыр», – ди. Хезмәттәшләремнең: «Син эшкә бәйрәмгә килгән кебек киләсең», – дигәннәре бар. Мин, чынлап та, мәктәпкә бәйрәмгә йөргән кебек йөрим. Шулай йөрергә тырышам! Гомумән, матурлык яратам. Башкортстанда елга ике тапкыр «Милли кием көне» билгеләп үтелә. Мин ул көнне мәктәптә калфактан булам. Милли бизәкле сумкаларым да бар. Мастер-класс уздым, үзем дә калфак тегәргә өйрәндем менә...

Китаптан: «Фәлән язучы шул елны шул урында туган», – дигән коры җөмләләрне уку – бер нәрсә, ә ул язучы белән үзең очрашуны


Фото: Эрик Асаев



сөйләү (яки укучыларыңны аның белән очраштыру!) – бөтенләй икенче! Менә ни өчен Уфада узган бер генә очрашуны да, театрлардагы премьераларны, концертларны калдырмаска тырыша ул. Күңелен баетырга, ә аннан ул байлыктан укучыларга өлеш чыгарырга! Яңа китап укуга ук аның турында сөйләүнең дә максаты шул.

Укучыларның төрле бәйгеләрдә катнашуы – шулай ук телне тырышыбрак өйрәнергә бер стимул.

– Хәзер бит конкурсларда Мактау кәгазьләре генә бирмиләр. Безнең өйдә өч-дүрт планшет менә – барысы да татар телен өйрәнү аркасында килгән бүләкләр.

Олы кызы – Илинасы 2017 елда татар теле һәм әдәбияты буенча Казанда узган Халыкара олимпиадада беренче урынны яулаган – Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның үз кулыннан бүләк алган. Ирина өчен укытучы буларак та, әни буларак та зур горурлык бу! Син укыткан фәнне балалар яратсын, хөрмәт итсен өчен менә шундый үрнәкләр дә кирәк. Ә аның өч кызы да татарча чиста сөйләшә. Яшерен-батырын түгел, башка җирләрдәге кебек, Әмирдә дә балалар үзара күбрәк русча аралашуга күчеп бара. «Туган телен онытылмаслык итеп сеңдереп калсын», – дип, кечкенә кызларын – Аврора-Таңчулпанны балалар бакчасына да йөртмәгәннәр Ирина белән Раил. Алар дөрес әйтә: русчаны барыбер өйрәнә бала-чага. Шул ук уеннар, мультфильмнар аша да. Әйткәнемчә, без барган көнне 6 яшьлек Аврораның мәктәпкә әзерме-түгелме икәнен белгечләр тикшергән иде. Әзер дип тапканнар: русча санап та күрсәткән, сорауларына да җавап биргән.

– Әйе, ата-анадан да бик күп тора. Аларның туган телгә мөнәсәбәтеннән. Кызганыч, арада: «Татар теле белән ерак китеп булмый», – дип уйлаучылар да бар. «Бала телен белми икән, халкының гореф-гадәтләрен дә оныта, ә аннан газиз әти-әнисен дә», – дим андыйларга. Тел белү һәрвакыт өстәмә мөмкинлекләр бирә. Туган телен тирәнтен өйрәнү Илинада, мәсәлән, максатчанлык тәрбияләде. Тугызынчы классны тәмамлагач, Туймазы медицина училищесына укырга керде ул. Шул ук елны, лекцияләрдән соң, кичке мәктәпкә йөреп, 10–11 нче класс программасын узды, БДИга әзерләнде. Имтиханнарын уңышлы тапшырып, Уфа медицина университетына укырга керде – 16 яшендә студент булды. Инде менә III курсны тәмамлады, фармацевт булырга әзерләнә. Ел саен «Студент язы» фестивалендә катнаша – татарча шигырьләр укый. Уфада татарча «квартирник»ларга йөри, Тукай бәйрәмнәрен калдырмый... Даринабызның да тел байлыгы бик зур. Апасы кебек, ул да китап укырга ярата – шул булыша дип саныйм. Иншаларны бик теләп яза. Ел саен «Тукай моңнары» республика конкурсында катнашып килде, гел алдынгы урыннарны яулады... Кызларны үземнән калдырган юк – театрконцертларга бергә йөрибез. Сөенәм, яраткан язучым Роберт Миңнуллин белән таныштырырга өлгердем аларны. Инде кечкенәсен дә шулай тәрбиялисе иде...

«Үз балаларымда туган телгә мәхәббәт уятуым гаҗәп түгел, әмма аларның да теләге булу кирәк иде», – ди ул һәм шунда ук Даринаның классташы Артурны искә төшерә. 5 нче класска күчкәч, иң беренче дәрестә үк: «Мин татарча белмим», – ди ул. Башка бөтен фәннәрдә дә «бишле» икән. «Теләгең булса, өйрәнерсең!» – ди укытучысы. «Ә сез миңа өстәмә биремнәр, күнегүләр бирә аласызмы?» – ди Артур. Быел тугызынчыны тәмамлаган, татарча иркен сөйләшә, ватсапка хәбәрләрне татарча гына яза ди...

Юк, башкаларга да ярату бер дәрәҗәдә салынгандыр. Светлана Гыйләҗева дигән укучысы әнә Казан федераль университетының татар теле һәм тарихы бүлеген тәмамлаган. Өч укучысы районда татар теле һәм әдәбияты укыта.

Укучыларың татарча китап укысын дисәң, үзең Ирина кебек янында гел китап йөртергә кирәктер. Кул астында гел шигырь китаплары тотарга. «Бу арада Эльмира Җәлилованы укыйм әле. Шагыйрь булсам, хисләремне аның кебек әйтер идем кебек тоела», – ди. Казанда булганда Нәбирә Гыйматдинова, Шәмсия Җиһангировалар белән очрашуын бәхет саный. Ә өстәл китабы – Мөхәммәт Мәһдиевнең «Бәхилләшү»е. Язучының дөньяга карашы, фәлсәфәсе ошый аңа. Кат-кат Әмирхан Еники әсәрләрен укый.

Туган телләр көне, телләр атналыгы, язучыларның юбилейларына багышланган кичәләр, татар теле һәм әдәбияты буенча 7–11 нче класслар өчен Акмулла исемендәге Башкортстан дәүләт педагогика университеты үткәргән дистанцион олимпиада, Казанда узган Халыкара олимпиада, «Татарча диктант» акциясе... Бу чараларда катнашу Ирина Фларит кызы тарафыннан укучылар туган телләре белән кызыксынсын, күзләрендә очкын кабынсын өчен сайланган.

Уңышка илткән серләрнең барысын да санап чыктык шикелле.

Әмма әле иң мөһимен әйтмәдек. Анысы – Иринаның ире. Раиле!

– Раил булмаса, мин бернәрсәгә ирешмәс идем. Бер тапкыр фатирга түләгәнем юк, газ счетчигының кайда икәнен, аның күрсәткечләрен кая язарга икәнен белмим. Кибеткә бик сирәк керәм... Раил мине мондый бөтен эшләрдән азат итте – тынычлап эшләргә бар мөмкинлекләрне тудырды...

Раил Каран авылы кызы Иринаны беренче тапкыр очратканда, кыз әле бөтенләй бала-чага гына була. Егет алар капкасын күршеләре белән

бутый һәм өйалды идәнен юып йөргән ап-ак чәчле кызчыкны күреп ала. «Бу кыз минеке булачак!» – дигән көтелмәгән уй уза башыннан... Тагын бер очрак бик истә: Иринаның почта мөдире булып эшләүче әнисе Раилдән: «Нигә һаман буйдак булып йөрисең, кайчан өйләнәсең инде?» – дип сорый. Егет: «Сезнең кызлар үсеп җиткәч!» – дип җавап бирә. Ике очракның кайсыдыр фәрештәләрнең «Амин!» дигән чагына туры килә... Иринаның үсеп буй җиткергәнен көтеп җиткезә бит Раил!

– Әтием безгә гел бер сүзне кабатлады: «Капкамнан башка милләт кешесен кертмәгез, тел бозып ятасым юк», – диде. Шөкер, өч кияве дә татар аның. Кечкенә сеңлемнең ире хәрби кеше, кайда гына яшәмәделәр: Киров, Саратов, Екатеринбургта... Әмма улларының өчесе дә саф татарча сөйләшә...

Иринага ирнең аны аңлый торганы насыйп була.

Раилнең төп нигезендә төпләнәләр алар. Яңа йорт җиткезеп керәләр. Әмир авылында ир-атларның күбесе инде шактыйдан вахта белән Себергә китеп эшли. Раил дә, лаеклы ялга чыкканчы, 1982 елдан бирле шул юлда була. «Ул бер айга киткән чакларда без яшәми дә идек кебек. Календарьга карап көн санныйбыз – армиядәге солдатлар сыман... Ансыз бик күңелсез була иде безгә».

Икәүләп Ирининың иң зур хәсрәтен – әнисен югалтуын кичерәләр. Яман чир 50 яшендә үк – күз ачып йомганчы, бер җәй эчендә алып китә аны. «Икенче кызымны – Даринаны көткән чагым иде. Миңа нибары 27 яшь ул вакытта. Сеңелләрем өчен әни урынына калырга туры килде. Әтием тол калганга инде 16 ел менә. Раил белән без дә, сеңелләр һәм кияүләр дә аңа терәк булырга тырышабыз. Узган ел биш операция кичерде. Әле маллар тота иде – велосипед белән сыерын саварга барып йөрдем. Әниемнең юклыгына әлегәчә күңел ышанмый. Почтада эшләде ул – халык белән иң күп аралаша торган җирдә. Указлы мулла кызы бит – догасын да кыла, уразасын да тота иде. Бик уңган иде – иртән эшкә киткәнче чәкчәк пешереп китә ала иде. Сабыр иде, берәүгә дә кычкырып бер сүз әйткәне булмагандыр. Күңелендә кешеләргә начарлык юк иде әниемнең, эчкерсез иде. Яшәмәгән дә кебек тоела...»

Кайгы араларны күпкә якынайта. Ирина тагын шул ук сүзләрне кабатлый: «Мин Раилсез бернигә ирешмәс идем...» «Ел укытучысы» бәйгесендә катнашкан чакларны искә төшерәләр. Ире: «Кирәк!» – дигәнгә генә тәвәккәлли ул чакта Ирина. Күп көч таләп итә торган конкурс бит: финалга җиткәч, ун көн буе Уфада булырга, чыгышлар ясарга, әзерләнергә кирәк... Раил хатыны яныннан бер минутка да китми: Уфага иртән алып бара, кич алып кайта, ул арада башкаларга булышырга да өлгерә әле. «Ә бездә бер укытучының ире, хатыны конкурска килмәсен өчен компьютерын балта белән бәреп ватты», – ди бәйгедәге катнашучыларның берсе...

«Өч ел инде атнага бер тапкыр Килем мәктәбенә барып немец теле укытам», – ди Ирина. Күрше авылга алып баручы да, алып кайтучы да – ире.

Укучылары белән олимпиадаларга чыгып китә – Раил озатып кала, каршы ала.

Уфада премьера: Раил хатыны белән кызларын театрга илтә, күп вакыт үзе кермичә, спектакль беткәнне урамда гына көтә. «Син бәхетле булсаң – мин бәхетле!» – бу аның Иринага иң еш кабатлый торган сүзе.

Кызлары белән су коенырга бара, балыкка йөри. Кышын алар өчен тау ясый. Аларда кызларның өчесе дә – «әти кызлары».

Бүздәккә «Татар үзәге»нә чакыралар – гаилә белән кузгалалар.

– Яныңдагы кешенең ниндилеген кайчак күреп тә бетермисең. Бүздәккә генә барып кайтабыз да, кабат Раилгә шаккатам. Шулкадәр ярдәмчел ул! Бездә хатын-кызга ишек ачып керткән ир-атны очратканым юк – ә ул ача! Кибеттә үзеннән алда чиратта торучыга алган әйберләрен пакетка салыша, багажникка ук күтәрешеп чыгарга да мөмкин әле. Искиткеч җитез! Әниләргә кунакка барганда да ишектән атлап керүгә нидер эшләргә керешә, әнием шуңа бик шатлана иде. Аның белән миңа бик тыныч. Тормыш мәшәкатьләренә бүленмичә – онытылып эшләргә мөмкинлек бирә ул миңа... Хатын-кызның бәхете – ирдән, диләр. Күптән түгел Бөтендөнья татар конгрессы мине «Татар милләтенә күрсәткән олы хезмәтләре өчен» медале белән бүләкләде, яңа гына «Хатын-кыз – милләт анасы» республика конкурсында катнашып, «Мәдәният» номинациясендә җиңү яуладым. Раилнең зур өлеше дә бар аларда... Аңа барыбер түгел. Туган телебезнең киләчәге барыбер түгел. Минем нәрсә өчен җан атканымны аңлый бит ул...

«Балаларыбызның гына түгел, оныкларның да татарча сөйләшүен телибез», – ди алар. Теләкләре чынга ашсын.



Гөлнур САФИУЛЛИНА.
Казан–Бүздәк–Казан.

ӘДӘБИ МАРАФОНЧЫ

– Чираттагы марафон башланачагын Раил безгә ун көн алдан хәбәр итә. «ВКонтакте»да, ватсапта үз төркемебез бар: мин шунда ук кызларның күңел кылларын тартырга керешәм: «Бу юлы нишлисез, теләгегез бармы?» – дип сорыйм. Яз көне бер кызыбыз: «Әлбәттә, катнашам! Гыйнвар аенда узган марафон башланган гына иде әле, әнием үлеп китте... Мин аны сезнең берегезгә дә әйтә алмадым ул чакта. Хәсрәтемне эчкә йоттым... Әмма әнине югалту ачысын кичерергә әдәби марафон бик булышты, ул көннәрдә миңа шулкадәр зур көч бирде», – дип язды. Үзе генә түгел, улы да катнаша әле аның...

«Мин – әдәби марафончы». Кем беләндер танышырга туры килгәндә, Гөлия ханым Җамалиева хәзер үзен һәрвакыт шулай тәкъдим итә. «Лаеклы ялдагы укытучы» диюләр күптән артта калган. Моңа кадәр марафон турында берни ишетмәгән кешене үзләре белән якыннанрак таныштыруга бер форсат та бу: әңгәмәдәшеңнең кызыксынып китүе, сезгә кушылуы да бик мөмкин бит. Максат барысының да гел бер – татар китабын укучыларның санын арттыру!

«Әдәби марафон» онлайн-проектының беренчесен «Белем.ру» оешмасы һәм «Татнетны үстерү фонды» җәмгыяте директоры Раил Гатауллин 2017 елда оештыра. Әңгәмәдәшем әйткәнчә, проект кысаларында әдәби әсәрдән үзең иң кызык дип тапкан өлешне социаль челтәргә куярга кирәк. Әмма бу өзекләр башкаларны да мавыктырырлык, аларга файда китерерлек булсын.

Гөлия ханым әле ул чакта мәктәптә милли мәсьәләләр буенча директор урынбасары булып эшләгән. «Күңелемә бер ял булсын әле, рухи азык та алырмын», – дип кушыла ул әдәби марафонга. Тормышы көтмәгәндә яңа бер сукмакка кереп китүен сизми дә кала шулай.

– Китап укырга кечкенәдән яраттым. Әнидән күчкәндер... Авылда эш күп, әмма укырга ничектер вакыт, җай таба иде. Аның мендәр астында һәрвакыт яңа китап булды. Татар теле һәм әдәбияты укытучыбыз Сәгадәт апа Мифтахова да матур әдәбиятны яраттыра белде.

Беренче марафонның финалына утызга якын кеше барып җитә. Раил аларны Казанга, Татарстан китап нәшриятының ул чакта «Нур-маркет»та урнашкан китап кибетенә җыя. Икенче марафонның җиңүчеләре инде йөзгә тула. Ә аннан бүләкләү тантаналары УНИКС, «Пирамида» мәдәни-күңел ачу үзәге кебек зур залларда уза башлый. Быел исә инде аны Арчада, Сабантуй форматында үтәчәк. Мәйданга ике меңнән артык китап укырга яратучы чакырылачак. Үткән марафонның финалистлары!

– Әдәби марафон 21 көн дәвам итә. Бер көн дә яңа өзек куймыйча калырга ярамый. Бик җитди сәбәбең булса гына... Мин, гадәттә, үзебезнең як язучыларын сайлыйм. Сажидә Сөләйманова, Клара Булатова, Сирень Якупова, Рәзинә Мөхияроваларны... Якташларымны башкалар да белсен, укысын дип тырышам. Әнвәр Хәйрине, Ризаэтдин Фәхретдиннең нәсыйхәтләрен дә куйганым бар.

Гөлия ханымның иң зур куанычы – әдәби марафонга оныкларының да кушылуы. Елга дүрт тапкыр узучы марафонның берсе хәзер балалар өчен оештырыла. (Раил Гатауллин хәтта марафонда катнашкан балалар сайлаган әсәрләргә нигезләнеп, аларга укырга кызыклы 140 китап исемлеген дә төзегән.) Иң кечкенәләр әти-әниләре белән бергә катнаша ала. Гөлия ханымның кечкенә оныгы Амалиянең дә әле үз аккаунты юк, алар дәү әнисе белән икәү Нур Әхмәдиевнең «Аксак төлке»сен укыганнар. «Сезнең белән бергә укып бардык, бигрәк кызык. Марафон тәмамланса да, куеп бетерегез инде, ахырын көтәбез», – дип сораучылар күп була. Оныкларның зурраклары – җиденче сыйныфны тәмамлаучы Әлфинә, инде студент эскәмиясенә күчкән Азалия дәү әниләрен көтеп тормый, билгеле. Аларга инде кызларның әниләре дә кушылган. Шулай итеп, марафонның финал тантаналарына гаилә белән бергә йөриләр. Казанда чын язучылар белән якыннан очрашу оныклар өчен үзе бер вакыйга.

– Соңгы тантанадан «әдәби әйдаман» титулын алып кайттым. Син яшәгән шәһәрдән марафонда илле һәм аннан да күбрәк кеше катнашучы булса бирәләр аны. Иң беренчесендә Әлмәттән берүзем идем, быел менә сиксәннән артык булдык инде. Марафонның кубогы да бар, аны ел да Саба районы ала – алардан марафонда катнашучылар саны инде ике йөзне узды. Язучының үзе өчен – язган әсәрләрен таныту өчен дә менә дигән мөмкинлек бу. Финалга баргач, без, гадәттә, бер-беребезгә китаплар бүләк итешәбез. Марафонда даими катнашучы Гүзәл Галләмова, Гөлсинә Галимуллина, Гөлнур Айзат, Эльвира Сафина, Гөлүсә Шаһбан кебек язучы-шагыйрәләрнең һәр яңа китапларын укып барабыз. Гомумән, марафон гади бер проект кысаларыннан чыгып, хәтта үз гимны булган зур бер хәрәкәткә әйләнде инде. Дөньякүләм хәрәкәткә. Әдәби марафон хэштегы куеп, Россиянең бик күп шәһәрләреннән генә түгел, чит илләрдән дә язалар хәзер. Сүз уңаеннан, без дүрт хэштег куярга тиеш: #әдәбимарафон, #татарстанкитапнәшрияты, #татнетныүстерүфонды, #татарстанязучыларберлеге.

Марафонда катнашуда яшь чикләре юк – интернеттан файдалана беләсең икән, рәхим ит. Әдәби марафон гаджетларда татар хәрефләрен кулланучылар санын да үстерде. Сүзләрнең дөрес язылышына да бик игътибар итәбез: бер-беребезгә ярдәмләшәбез, киңәшләр бирәбез. Марафон һәркайсыбызны дусларга баетты: бер район укучылары икенчеләре белән очрашып тора. Без, мәсәлән, «Әлмәт–Саба» күпере оештырдык. Мин үзем Омск өлкәсендә туганмын. Әти белән әни өйләнешкәч, чирәм җирләрне күтәрергә китәләр. Туу турындагы таныклыгымда язылган авылны барып күргәнем юк, әмма ул яклар барыбер күңелгә якын. Омск өлкәсеннән Фагыйлә апа Чумарова, Сара апа Гаффарова, Әсгать абый Курамшиннар белән марафон аша таныштык, финал тантаналарында инде берничә тапкыр очрашып күрештек. Тагын бер нәрсә бар: бүләкләүләргә без, хатын-кызлар, барыбыз да калфаклардан килә. Марафон, димәк, милли киемгә дә игътибарны арттыра.

Гөлия ханым сөйләгәннәрне: «Бу – минем өчен икән! Китап укырга бик яратам!» – дип тыңлаучыларга: елга дүрт тапкыр оештырылучы марафонның чираттагысы 1 октябрьдә башланачак. Китаплар исемлеген барлый торыгыз.

Гөлнур ХӘСӘНШИНА

– Әдәби марафонның кагыйдәләре бик гади: көн саен социаль челтәрләрнең берсенә үзең укыган нинди дә булса әсәрдән өзек куеп барырга кирәк. Озынмы ул өзек, кыскамы, әллә берничә юллы шигырьме, анысын үзең хәл итәсең. Текстыңны фотолар белән тулыландырырга мөмкин. Әгәр син куйган шигырьне кемдер укый яки аңа көй язылып, җырлыйлар икән, болар белән дә текстны баетырга була. Башта әдәби марафон «ВКонтакте» социаль челтәрендә генә барды. Әмма анда җайсызрак: куйган текстыңа бер тәүлек дәвамында гына төзәтүләр кертергә ярый, соңрак, хата тапсаң да, инде үзгәртә алмыйсың. Бүген исә безнең марафонда катнашучыларны инстаграмда да, Фейсбук битендә дә очрата аласыз.

Фото: Анна Арахамия

«ТОРМЫШ ХӘЗЕР ФЕЙЕРВЕРК...»



Татарстан һәм Башкортстанның атказанган артисты Рөстәм АСАЕВны татарның Магомаевы, диләр. Сирәк очрый торган бас тавышы өстенә, ул әле озын буйлы чибәр ир-ат та. Үтә тыйнаклыгы, затлылыгы, төгәллеге белән аерылып тора. Йөзендә һәрвакыт шаян елмаю, юмор хисле. Егет сүзе бер була дип яшәүчеләрдән ул.

Рөстәм, син Татарстанда иҗат итүче Башкортстан татары...

– Башкорстанда туу-ым, Татарстанда яшәвем белән горурланам. Ике тугандаш республиканың мәшһүр җырчыларын тыңлап үскән кеше бит мин. Әмма Уфа сәнгать училищесына җырчы дип түгел, гармунчы булам дип килдем. Баян белән җырлап утырганымны күреп: «Баянчылар болай да күп, безгә озын буйлы җырчылар кирәк», – дип, вокал бүлегенә керергә киңәш иттеләр. Аннан соң Уфа сәнгать институтына укырга кереп, Башкорт опера һәм балет театрына солист булып урнаштым.

Авыл баласы өчен опера буй җитмәслек сәнгать кебек югыйсә...

– Чынлап та, фортепиано да күргән юк иде. Укытучыларыма рәхмәт. Алар югары сәнгатькә мәхәббәт уятты. Беренче тапкыр опера театрына баргач, шундый зур залда ничек микрофонсыз җырлыйлар икән дип аптыраган идем. Берничә елдан соң үзем дә җырлый башладым.

Уфада – опера, Казанда – эстрада. Ни өчен?

– Казанга килү максатым опера түгел, уку иде. Җитмәсә, Ринат абый (Ринат Закиров Бөтендөнья татар конгрессының элеккеге рәисе. – *Ч. Г.*) чакыруы буенча Казан шәһәр филармониясенә эшкә алдылар. Казанга гашыйк булдым. Бөтенләй икенче дөнья! Казан Казан инде ул! Операны ташлап Казанга килгәнеңә үкенмисеңме дип сорыйсың киләдер инде синең. Бер генә секундка да үкенмим. Алга барырга кирәк. Юл кешене бәхетле итә. Ә ул төрле, әмма уйлап яшәгән кешене бәхеткә алып бара. Уфа–Казан юлы минем өчен әнә шундый юл.

Иҗатыңны күптәннән күзәтеп килә инде. Син эстрадада тормыш алып барыр өчен, ә күңелең опера сорый дигән тәэсир туды. Мин хаклымы?

– (*Бераз уйланып торганнан соң.*) Әйе, син хаклы. Мин Татарстанга килгәндә Казан опера һәм

балет театрының сәясәте башкачарак иде. Кирәк булмадым. Дөрес, хорга чакырганнар иде, әмма солисттан соң хорда җырлап йөрүне кирәк дип тапмадым. Операда урта кул җырчы булу гына җитми, беренче булырга кирәк. Аннан соң эстрада да үзенә тартты. Без бит, ни әйтсәк тә, авыл малайлары. Халкыма хезмәт итәсем килде.

Партияләр җырларга чакырсалар, барыр идеңме?

– Әлбәттә. Мин һаман үз өстемдә эшлим. Арияләр җырлыйм. Операда иҗат итәргә бүген дә соң түгел. Минеке кебек бас тавышлар 45 яшьтән соң ачыла гына әле ул. *(Үтә дә бас тавышы белән әйтә.)* «Борис Годунов»та – Борис, «Князь Игорь»да Кончак партияләрен башкарыр идем. Бас тавышлы артистлар өлешенә, гадәттә, патша, юлбасар, картлар роле төшә. Мәхәббәт геройлары бас тавышлы түгел инде. Шуңа да бит: «Не родись счастливым, а родись тенором», – диләр. (*Көлә.*)

Мин шәхсән сине кумирың Мөслим Магомаев кебек патриотик җырлар башкаручы итеп кабул итәм...

– Әйе шул, патриотик җырлар минеке. Төрле спорт ярышлары алдыннан җырларга чакыралар. Гимн җырлаганда чиксез горурлык хисләре туа. Эчтәге кичерешләрне үзем генә беләм.

Җыр сайлаганда нәрсәгә игътибар итәсең?

– Соңгы арада репертуарны үзгәртәсем килә. Хәзер бит профессиональ яктан камил җырларны табу бик авыр. Шуңа күрә ретро җырларны башкарырга тырышам. Алар – күңелне баета торган җырлар. Заманча җырларның тәмен таба алмыйм, шуңа тамашачыга да җиткереп бетерә алмыймдыр. Андый җырлар башкарганда озын арбалы КамАЗларга бер бидон сөт салып барган кебек кенә хис итәм үземне. Аңлыйсыңмы? Тавыш потенциалын да кулланып бетереп булмый. Әмма хәзер халыкка ике нота арасында адашып йөргән җырлар күбрәк ошый. Тирән җырлар популяр түгел.

Нигә шулай икән ул?

– (*Уйга калып торганнан соң.*) Хәзер тормыш – фейерверк, салютка әйләнде. Ә мин үземне дә, ретро җырларны да багана утына тиңлим. Фейерверк ул бик кыска була. Дөрес, ул вакытта бөтен кешедә бәйрәм рухы, аһ итәләр, ун минутлык эйфория һәм бер-ике сәгатьтән соң ул онытыла да инде. Ә багана уты һәр төнне кирәк. Әмма аңа игътибар аз.

Менә шул фейерверк дөньяда суда балык кебек йөзгән Гөлназ Асаеваның әтисе дә бит әле син. Кызыңның үзеңнән популяр булуын ничек кабул итәсең?

– Ата-ана өчен зур бәхет инде ул! Балалар ата-анасыннан камилрәк булырга тиеш. Дуэтлар җырладык, концертлар оештырдык. Хәзер аның үз тормышы, үз юлы. Гөлназның зәвыгы, үзенә хас тембры, моңы бар, җырны җиткерә белә. «Кызым, син җырларга тиеш!» – дим. Аңа бар җырлар да килешә.

Сәхнәдә затлы, үзен үтә тыйнак тоткан Рөстәм Асаев тормышта нинди?

– Әйе, тыйнак шул. Әрсезлек җитми миңа. Безне шулай калыпларга кертеп тәрбияләгәннәр инде. Артык дөрес кешеләр без. Басып тор шушында дисәләр, кымшанмый да басып торам инде мин. *(Көлә.)* Бу заманда менә шул яшәргә комачаулый. 40–50 ел элек туасы калган. Тормышыбыз матур, бай, әмма рухи хәерчелек көчле. Шайтан туена өстенлек бирелә. Патриотик бәйрәмнәрдә дә сәхнәдә ни кыланганнарын аңламыйлар. Ә бит үзенә бер горурлык хисе, күтәренке кәеф, тантана белән башкара торган патриотик җырларыбыз да бар безнең. Оныттылар! Әдәпәхлак тәрбиясе җитми, романтизм, энтузиазм җитми. Шуңа йөрәк әрни. Зыялылык, тәрбиялелек икенче планда калды. Җырлар да, тамашачы да башка хәзер.

Текст: Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА.
Фото: Анна АРАХАМИЯ. Видео: Фәнис САДЫЙКОВ.
Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.









Гөлнур
САФИУЛЛИНА

КӨНДӘЛЕК

– Безнең әни гаҗәеп төгәл кеше ул. Мин менә аш-су тирәсендә кайнашканда бөтен нәрсәне дә чама белән генә эшлим. Әни андый түгел, ул хәтта өйдәге һәр кәстрүлнең авырлыгына кадәр хәтерли – шуларны әйтеп сөйләшә...



– Мине кечерәк чакта, беләсезме, нәрсә шаккаттыра иде? – дип сүзгә кушыла Миләүшә. – Әби коймак пешергәндә, камырны табага сала иде дә, йөзгә хәтле чутлый иде, аннары икенче ягын әйләндерә. Безнең кебек: «Асты килдеме икән әле?» – дип, әллә ничә тапкыр күтәреп карамый. «Йөзгә кадәр санасаң, таман гына була ул», – дия иде. Тәмле була иде әбинең коймаклары! Матур да!

Мине исә Мөнирә апаның гомер буе язган көндәлекләре шаккаттыра. Бер көн калмыйча! Менә чынлап та кемнән өйрәнергә кирәк төгәллеккә! Хәер, бу көндәлекләр Шәфыйковлар гаиләсенең генә түгел, алар яшәгән бөтен Үчәлле авылының байлыгы. Аларны икенче төрле «Үчәлле тарихы» дип тә атарга буладыр. Көндәлекләргә барысы да теркәлеп барылган: авылда кайсы көнне кайсы нигезгә килен төшкән, кемнәр кайчан бәби бишегә элгән, кемне соңгы юлга озатканнар...

Ул көндәлекләрдә – аның гомер юлы, балаларының балачагы, яшьлеге, шатлыгы-куанычлары, оныклары...

«1953 ел, 5 декабрь. Бүген конституция көнен бәйрәм иттек. Мин бүген Рәфкатьләр йортына килен булып төштем...»

Чынлыкта, көндәлекләр шактый соңрак языла башлаган әле. Монысы – күңелендәгесе. Ярты гына ел очрашып йөреп, Рәфкате белән кушылганда аңа унсигезе яңа тулган була. Икесе дә шушы авылныкы – Үчәлленекеләр алар. Рәфкате – шофер, ул чакта авылның иң дәрәҗәле, хөрмәтле кешесе. Көн туса, аңа берәр үтенеч белән килмәгән кеше юк: берсен дә кире бормый.

– Хәзер менә Миләүшәгә карыйм да, гел үземне уйлыйм. «Әни белән безнең ара 19 ел гына бит», – дип йөри иде олы кызым Гөлзәрия. Яшьли чыгылды шул тормышка... Бианам мине үз баласыдай каршы алды. Балалары унау иде аның. Буйга миннән дә кечерәк иде үзе. Ә күргәннәре... «Башта бардым малайга, аннан бардым бабайга, аннан – самайга», – дип сөйли иде уенын-чынын кушып. Яшьлегендә Азнакайга үзе кебек егеткә кияүгә чыга, әмма тора алмыйлар – аерылышалар. Аннан әтиләре 60 яшьлек картка бирә. Биш балалары туа. Тол калгач, кабат кияүгә чыга, тагын биш бала таба. Минем Рәфкать – шул икенче оядан... Ә аннан әтиләре аларны ташлап чыгып китә. Дөрес, ул хатында да озак тукталмый, читкә китеп югала. Шул китүдән авылга кайтмады ул, оныкларын түгел, үз балаларының да буй җиткәнен күрмәде. Ә әнкәй, көндәш дип тормый, авылдагы теге хатын белән аралаша иде. Рәфкать белән кушылгач, ул апа безне чәйгә дә алды әле...

Яшь идем бит – әнкәй мине бар эшкә дә ипләп үзе өйрәтте. Ипи салырга да. Аңарчы инәй салган ипиләрне мичтән алганым гына бар иде. «Ипиең тәмле иде», – дип хәзергә кадәр әйтәләр...

Кайнанасына бүләккә баш-башлары чигелгән намазлык, сөлгеләр, өйне ямьләргә – тәрәзә челтәрләре... Яшь булса да, бирнә сандыгы башкаларныкыннан ким булмый Мөнирәнең. Бәйләүне аннан соң да гомер буе кулыннан төшерми. Биш бала әнисе моңа ничекләр өлгергән, белмим. Колхоз эшеннән кайтып кермәгән: тавык фермасында, колхоз складында эшләгән.

– Балаларны карашырга бианам булышты. Мин килгәндә аңа алтмыш яшь кенә иде әле – без бергә картайдык... Нәрсә өчендер ачуланышканыбызны хәтерләмим. Матур яшәү өчен сабырлык кирәк. Олы кеше эндәшмәсә, яшь кеше аннан узып дәшми. Әнкәй гел минем яклы иде. Барасы җирләребезгә дә җибәрмичә калмады. Балалар бик кечкенә чакта да. «Елады, күкрәгемне каптырдым», – дигәне дә булды...

«1959 ел, март. Яңа өебезгә күчендек...»

Ире ташлап чыгып киткәч, төп нигездән кайнанасын ун бала белән өчкә дүрт зурлыгындагы иске бер өйгә башка чыгаралар. Бер кышлык иген биреп. Мөнирә әлеге нигезгә килен булып төшә. Шул тормышка риза булып... «Киленеңә сүз әйтмә, ул сезгә бәхет китерде», – диләр Гөлчирә апага туганнары. Яңа йорт җиткезүләрен күз алдында тотып әйткәннәрдер инде.

– Эшләгәндә эшләдек, Аллага шөкер. Егылдык, тордык, йөгердек... Монысы – ир-атныкы, монысы хатын-кызныкы дип бүлеп тору булмады. Рәфкать колхоз эшеннән бушамады. Бакчаны, йорттагы малларны карау балалар белән минем өстә иде. «Барасым, эшлисем килми», – дигән сүз ишетмәдем кызларымнан да, улларымнан да. Колхоз гектар-гектар чөгендер бирә, шуны утыйлар иде. Печән әзерләшергә дә катнаштылар: тырма тартырга көчләре җитә башлауга. Балаларны эш белән үстерергә кирәк...

Яңа салган йортта килендәш белән бергә яшәгән еллары да була әле. Тавыш-тыннары чыкмый – сыялар. Сабыр, акыллы кайнанасы Үчәлленең абыстаена әйләнә: аш-су үткәрергә теләүчеләр иң элек аңа чиратка языла. Бер дистә баласы арасыннан улы Рифкатьне, килене Мөнирәне якынрак күрә ул: «Мин сездән калмыйм, сезнең белән яшим», – ди. Улларына, кызларына да: «Кайтып йөрегез, төп нигезне ташламагыз – Мөнирә сезне һәрвакыт ачык йөз белән каршы алачак», – ди. Хак әйтә.

«1983 ел. 22 ноябрь. Иртәнгә кадәр буран дулады...»

Рәфкатен соңгы юлга озаткан көн бу. Кырык сигез яшендә тол кала ул. Бер-берсенә «карт-карчык» дип әйтерлек озак яшәргә язмаган була аларга... Кечкенә кызы Гөлшатка 10 яшь тулган, Илшаты армиягә киткән ел. Бөтен дөнья мәшәкате берүзенә өелеп калган ел. Аз гына алдарак, шул елның мартында бианасы да мәңгелеккә күчкән ел. Тагын... көндәлек дәфтәргә көн саен яза башлаган ел. Язгач, күңелдәге борчуларның меңнән бер өлешен генә кәгазьгә төшергәч тә – җиңелрәк булып китә.

«1990 ел, 25 август. Илшатым башлы-күзле булды. Ишкәйдән Фәнүзәне алды».

// Миләүшә Шәфыйкова:

– Мин башта Азнакайда лицейда укыдым, әлбәттә, аралашу гел татарча гына иде. Унынчы сыйныфка җиткәч 4 нче мәктәпкә күчәргә туры килде. Анда башка милләт балалары да шактый. Шуңа күрә классташлар белән үзара күбрәк русча гына сөйләштек. Әмма өйдә аралашу татарча гына бездә. Әти-әни белән дә, абыйлар белән дә. Бу – язылмаган закон!



Инде сүзебезгә эштән кайткан Фәнүзә дә кушыла.

– Казан төзелеш институтында югары белем алдым. Колхоз стипендиаты идем, диплом яклагач, өч еллык бурычымны үтим дип авылга экономист булып кайттым. Язмышым исә инде язылып куелган булган икән... Сигез ел бер мәктәптә укысак та, Илшат белән бер-беребезне күрмәгән булганбыз, кайткач өр-яңадан таныштык. Бер елдан соң инде аларга килен булып төштем. Төп йортта яшисемне белеп бардым. Шулай тиеш кебек кабул иттем. Үз әнием дә гомер буе биана белән яшәде. Әйе, төп йортка кайтучы-китүче күп! Бездә дә шулай булды. Туганнарның балалары җәй буе да тордылар. Хәзер дә кайтып йөриләр.

Әнинең «килен» дип мине какканын хәтерләмим. Килен белән кайнана уртак тел тапсалар гына тормыш барадыр ул... Кирәк чакта төпле киңәшен бирә белде, эшне белмәсәм – өйрәтте. Ипи салырга, мәсәлән. Иң беренче ипиемә тоз салырга онытканидем. Тозсыз камыр күперә бит ул, «Бигрәк уңган!» – дип ашадылар...

Туктагыз, тукта, миңа гына нәрсәдер кабатлана кебек тоеламы соң ул, әллә чынлап та шулаймы?!

«1998 ел, 10 июнь. Көн чалт аяз. Йортны, ниһаять, өлгерттек».

«Уразман» – Азнакай районындагы ике миллионер колхозның берсе була. Аягында нык басып торган хәлле хуҗалык. Киләчәге дә матур тоела. Шәфыйковларның кече уллары Илшат шуңа да туган авылында төпләнергә ниятли. «Шәһәргә китү турындагы уй башыма да кермәде, – ди ул. – Югыйсә, андый мөмкинлек булды: Азнакайда да, Чаллыда да эш бар иде». Ике егет атасы булырга өлгергән ир яңа йорт күтәрергә тотына. Туганнары, Фәнүзәсенең якыннары «булышабыз» дип торганда нигә тәвәккәлләмәскә?! Ул елларда күп итеп мал асрыйлар, сыер тоталар, сыр ясыйлар... Төп нигезгә салынган йорт бүген аларны авылга бәйләп тора. Бөтен җирдәге кебек аларда да колхоз таралган, эш урыннары беткән. Иң аянычы – мәктәп ябылган. Бала-чага 12 чакрымдагы Тымытыкка йөреп укый. Аз инде алар, быел әнә Үчәлледә әлегә бер бәби чәе дә узмаган. Илшатлар һәм тагын өч гаилә балаларын Азнакайда укыткан: чиратлашып озатканнар, каршы алганнар. Колхоз яртышар ел хезмәт хакы түли алмагач, үзләре дә Азнакайга чыгып киткәннәр. Илшат «Азнакайнефтемаш»та эшли, Фәнүзә – «Азнакай җылылык челтәре»ндә инженер. Көн саен иртән 22 чакрым узып эшкә баралар, кичен шуның кадәр юл узып кире кайталар.

«2003 ел, 25 август. Илшатларның кызлары туды. Иртәгә бездә сарык көтүе...»

– Бала тудыру йортыннан кайтканда әни безне шундый матур итеп каршы алган иде. Ашлар салып... Кайнана белән яшәүнең рәхәт яклары күп аның. Абыйлары Миләүшәнең тууын бик көттеләр. Елак булды ул. Ринат гармун сузып җибәргәч кенә тына иде... Ринат та, Салават та Азнакайда музыка мәктәбен тәмамладылар. Әтиләрендәге сәләт аларда да бар. Илшатка бу юнәлештә укырга туры килмәгән, шуңа күрә малайларга музыкаль белем бирү өчен бик тырыштык. Мәктәптән соң көн дә Азнакайга кадәр музыка мәктәбенә йөртү бик җиңел булмады инде. 22 чакрым бит ул! «Башка бармыйм, ташлыйм», – дигән чакларында кулларыннан җитәкләп кире илткән вакытлар да булды. Берсендә «попуткага» утыртып озаттым гына, карыйм – сумкалары кулымда калган! Икенче «попутка» белән артларыннан юлга чыгарга туры килде... Бераз үскәч, матай белән йөри башладылар. Уразайга апаларга кадәр баралар да, аннан «попутка»га күчәләр. Икесе дә баян классында укыды, Ринатны ансамбльгә дә алдылар, ул курайда уйнарга да өйрәнде. Салаватның тавышы барлыгын да баянда уйнарга өйрәнгәндә ишетеп алдылар.

Энергияләре ташып торгач, икесен дә спортка да бирдек. Авылда физкультура укытучыбыз Мәҗит абый бик көчле иде – волейбол уйнарга ул өйрәтте малайларны. Ринат Азнакайның җыелма командасына да эләкте. Буе безгә охшаган – кыска аның. «Мин чыгып баскач, көләргә тотындылар, ә уйный башлагач бик тиз туктадылар», – дип сөйләгән иде ул беренче көнне кайткач... Малайлар мәктәптә укыганда гаилә ансамблебез белән нинди генә конкурсларда чыгыш ясамадык?! Казанда «Корстон» сәхнәсенә дә чыкканыбыз булды. Әтисе белән Салават ике тавышка җырлыйлар, Ринат баянда уйный иде... Салават шушы юлдан китте: башта Әлмәттә музыка колледжын тәмамлады, аннары Оренбургта институтта белем алды. Бүген Татарстан дәүләт камера хорында җырлый...

Илшат белән Фәнүзәнең зур хыялы бар: Казанга, Салават катнашкан концертка барып, улларын зур сәхнәдән күрәселәре килә. Нишләтәсең, тиз генә җыенып чыгып китеп булмый – якын ара түгел. Әлегә Салаватның җырларын язмада гына тыңлап сөенәләр.


Фото: Анна Арахамия

Һәр баскан җирен сәхнә итә белүче Миләүшә дә бар бит әле. Азнакай сәнгать мәктәбендә, хореография классында укыган. Коеп куйган биюче! Быел урта мәктәпне тәмамлый. Табиб булырга җыена. «Мине озаграк яшәтергә тели ул!» – дип сөенә Мөнирә әбисе.

Миләүшә – әнисенең иң зур булышчысы. Аш-суга кулы ятып тора. Әтисе белән абыйлары үз куллары белән теплица төзеп куйган әнә, ә алар әниле-кызлы кыяр-помидор үстерәләр. Миләүшә әйткәнчә – яратып!

«2011 ел, 22 март. Кар кичкә кадәр яуды. Нашат үлгән инде...»

Илшатның Чаллыда яшәүче олы абыйсы бу. Биш туганнан дүртәү генә калганнар. Аңа нибары 50 яшь була. Мөнирә апа көндәлекне бу көнне дә кулына ала. Ана кеше өчен иң ачы хәсрәтле көнне дә... «Мин дәфтәрне беркайчан кулдан төшермәдем. Кунакка барганда да үзем белән алып барам, биш-алты юл язып куярга мөмкинлек таба идем... Күзләрем начарланганчы яздым».

«2014 ел, 12 июнь. Иртәнгә көн аязды. Бүген авылда Сабантуй».

Мөнирә апаның авыл Сабан туен калдырганы юк икән әле. Бер елны да! Урам бәйрәмнәрен дә. Илшатын, оныкларын тыңларга чыга, билгеле.

– Бер елны урам бәйрәмендә утырам шулай. Арттагы хатыннар үзара сөйләшәләр. Берсе: «Мин шушы Илшатның җырлаганын тыңлар өчен генә чыгам бәйрәмгә», – ди. Әни кешегә бик рәхәт, күңелле инде бу сүзләрне ишетү. Үземнең әтәем Әхмәдулла матур җырлый иде, Илшат та, аның уллары да аңа охшаган...

Авыл, аннары район сәхнәсенә күтәрелгәнче, башта һәр көнне өйдә концерт әле аларда. Кинәнәләр әтиләрен тыңлап! Репетицияләрне Миләүшә дә яратам ди – Шәфыйковларсыз Үчәлледә бер концерт, бер бәйрәм дә узмый. Һәммәсе беравыздан авыл клубын, аның мөдире Айгөлне мактый: «Эшен оештыра белә – авылыбызны яшәтә! Барыбызны да уятып җибәрә», – диләр. Мәктәпне ябып, бинасын сүткәннән соң, клуб авылдагы бердәнбер мәдәни учак булып калган. Хәер, сүтелмичә калган спортзал бар әле тагын – яшьләр анда да җыела.

«Илшат башкарган кайсы җырны күбрәк яратасың?» – дим Фәнүзәгә. Озак кына уйлап тора да: «Барысын да!» – дип елмая ул. Калган сүзләре күзләрендә – яратуы, якын итүе, соклануы...

«2021 ел, апрель. Ринатның кызы туган. Әтисенең туган көнендә өйгә алып кайтканнар».

Көндәлеккә языласы бу юллар инде Мөнирә апаның күңелендә генә: нишләтәсең, күзләрнең җетелеге киткән. «Без хәзер Фәнүзә белән килен белән кайнана түгел, ике бианай», – ди ул.

– Ринат белән Салават бергәрәк үсте. Мин нигәдер гел кечкенәдән үк алар турында: «Улларым бит булачак әтиләр», – дип уйлый идем. Әтиләренә охшауларын теләдем. Бөтен эшкә курыкмыйча тотына алуларын, эш рәтен белүләрен, үз сүзләрен кистереп әйтә белүләрен... Ринатыбыз башлы-күзле булды менә. Киленебез Лилия – Азнакай кызы. Яңа гына онык белән сөендерделәр. «Миңа әби дип дәшәрсең», – дип колагына пышылдадым инде. Илшат: «Оныкны балдан татлы дип әйтәләр иде, тик моның кадәр үк булыр дип уйламаган идем», – ди... Әйе, мин дә хәзер бианай... Килен белән кайнанага һәрвакыт бер сүздә булу кирәк. Әмма матур яшәү өчен иң элек барында да шундый теләк булуы кирәк... Өйдә олы кеше булу бәхет ул. Йортка, балаларга һәрвакыт күз-колак бар дигән сүз. Кайткан җиребезгә чәй кайнаган, аш пешкән иде. Хәер, 86 га җиттем, ял итим дими, хәзер дә хәленнән килгәнчә булышырга тырыша әле әни. Ашны булса да куя тора...

Утыз беренче ел кайнана белән торуымны белгәч, кайберәүләр: «Сиңа инде орден бирергә кирәк», – диләр. Андый чакта гел көләм: «Миңа түгел, әнигә бирергә кирәк аны, дим: башта 30 ел бианай белән яшәгән, инде менә тагын 30 елдан артык килен белән – минем белән яши...»

Йортлары авылның уртасында, мәчет белән янәшә аларның: көнгә биш тапкыр азан моңына күмелә. Ә капка төбендә эскәмия. Мөнирә апа еш кына шунда чыгып утыра. Авылдагы матур гадәт буенча, урам буйлап узган һәркем тукталып сәлам бирә, хәл белешә. «Бәхетле карчык син. Ул-кызларың әйбәт», – дип китәләр. «Картайгач бәхет күбрәк кирәк, диләр иде, дөрес икән ул сүз. Балаларыма да шуны телим: миннән дә озаграк яшәсеннәр. Минем кебек кадер-хөрмәттә яшәсеннәр...»

Ә күңелдәге көндәлеккә янә бер сөенечле юл өстәлә. Онытканчы!

«Рәшит Ваһапов исемендәге халыкара татар җыры фестиваленең яшь башкаручылар конкурсында Салаватыбыз лауреат булган!»



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Видео: Анна Арахамия.



ҖЫРЛАНАСЫ ҖЫРЛАР БЕТМӘГӘН...





Эльмира ЗАКИРОВА

Җырчы көчле бәрхет тавышы белән җаннарны айкый. Көмеш телле тальяны исә ул җырларга әллә нинди сихри аһәңнәр өсти. Тамакка төер тыгыла, күзләр яшьләнә. Авыл кичләре, җәйләүләр, Тегермән буалары күз алдыннан үтә, ат тоягы тавышларын ишеткәндәй буласың, әрем, шомырт исләренә исерәсең... «Герман көе», «Рамай», «Әрем исе, әрем тәме», «Сарманай», «Сылукай»... Күңелгә якын җырлар рәхәт бер дулкында тибрәтә... Булса да булыр икән моң, булса да булыр икән тавыш!.. Әнә шулай якты сагышка күмеп, күңелнең тирән төпкелләренә үтеп керерлек итеп җырлый ул. Аны яраталар. Президентлар да, җитәкчеләр дә, гади авыл кешеләре дә. Аның иҗатташ дуслары күп. Ә күпме шагыйрь шигъри юлларын аңа багышлаган. Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Роберт Миңнуллин, Әхсән Баян, Рафаэль Сибатлар... Таныгансыздыр – Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты, Шаран районының почетлы гражданины, 70 яшьлек юбилее көннәрендә Салават Юлаев ордены белән бүләкләнгән атаклы җырчы һәм виртуоз тальянчы Фән ВӘЛИӘХМӘТОВ безнең хозурда. Ихлас, гади, шаян, җор телле, тыйнак һәм искиткеч талантлы җырчыбыз яңа яклары белән ачылды бүген.



ТАМЫРЛАР Кендек каным тамган авыл хәзер юк инде. Башкортстанның Шаран районында, 33 кенә йортлы Хафиз авылында туганмын. Никадәр генә матур табигать кочагында утырса да, перспективасыз кече авыллар язмышына дучар булды ул. 80 нче елларда бетерделәр аны. Әткәй ягыннан Вәлиәхмәт бабкай урманчы булган. Улы Фазлыйәхмәт – әткәйнең әтисе – сугышка кадәр колхоз, авыл советын җитәкләгән. Бик таза гәүдәле, көчле кешеләр иде, дип сөйлиләр. Безнең нәселнең Мирзаян, Рәхим абзыйлар Шәкүр каракка ат урлап та илтеп йөргән, шундый заманнар да булган. Хәлле кешеләр капкаларын, абзар ишекләрен тимер йозакка бикләсәләр дә, болар шуларга барып, атларын алып чыгып китә торган булганнар. Иртән торсалар – йозак урынында, ә ат... юк ди! Абзарның түбәсен бүрәнә белән күтәреп, атның ялыннан сөйрәп алып, чабата кидереп, бакча артыннан

алып чыгып китәләр икән. Чабата эзе бар, тояк эзе юк – каян эзләргә дә белмиләр. Әткәй Гавис ягы менә шундый гайрәтле нәсел.

Әнкәйнең әтисе Лотфулла бабкай – Каразиректән, Татарстанның Ютазы районыннан. Гомер буе җир эшкәрткән, игенче булган. Әнкәем Галимә гомер буе комбайнда эшләде. Алар ягыныкылар бик матур җырлый иде. Бабкай да, әнкәй дә, аның апасы Тимербикә түткәй дә... Анысы бигрәк шәп итеп, шыңгырдатып җырлый иде. Шул күчкәндер инде миңа да... Әткәй ягы – гармунчылар, көрәшчеләр: тирә-якта дан тотканнар. Без – Башкортстан татарлары, типтәрләр. Тәрене тип, дигәннән чыккан бу сүз дип ишеткәнем бар. Безнең сөйләшү Минзәлә сөйләшенә керә. Университетта укыганда Ык буе сөйләше дип әйтәләр иде. Әнкәйләр Туймазы, Казан урынына Туймады, Кадан дип сөйләшә.



БАЛАЧАК Әбкәй, бабкай, әнкәй белән үстем мин. Бик шат бала идем. Без кәҗә көтүе көтеп үскән малайлар инде. Гел качып агач башына менеп, еракка карап җырлап утырырга яраттым. Нинди җыр телгә килә – шуны җырлыйм. «Сандугач булдыңмы әллә?» – диләр иде миңа. Агач ботагына эләгеп, киемнәр ертылып бетә... И әнкәй әрли инде! «Колхоз радиосы булдыңмыни, төш!» – ди. Берсендә тәмәке тартып эләктем мин. Әнкәй кулны кысып тотты да сүндерде тәмәкемне. Кул кабарып чыкты. «Тагын тартасыңмы? Тартасыңмы?» – дип кабатлый-кабатлый, тәүбәне әйттерде ул миңа. Әнкәй комбайнда эшләгәч, гел майга батып кайта иде. Ә әткәй – страховой агент, чиста киенә, көрәшче, бик матур почерклы, башлы кеше. Әнкәй минем белән авырлы чакта, әткәй бер укытучы кыз белән буталып алган. Укытучыдан хушбуй исе, әнкәйдән керосин исе килеп тора икән. Әнкәй туры сүзле кеше буларак, әткәй белән арасын кырт өзгән. Ундүрт ел читтә йөргәннән соң гына кире әйләнеп кайтты ул безгә. Алай да әтиләләр янында кимсенеп йөрергә туры килде миңа да. Кич җиттеме, бар да гармун күтәреп чыга иде авылыбызда. Утызлап гармунчы. Сугыштан кайткан абзыйлар. Шулардан күп нәрсәне оттым. Авылда чирәм өстендә ялан тәпи йөгереп йөргән чакларны кире кайтарыр идем. Әнкәйнең кырга алып китеп, печән исе, җиләк исе, болын исе сеңгән ипи кисәген кире алып кайтып, «куян күчтәнәче» дип, безне сыйлаулары әле дә күз алдында... Кечкенә авылда үскән балачак – иң кадерлесе, иң рәхәте. Әбиләрнең карын көрибез, суын алып кайтабыз. Хәзерге кебек акчага эшләү дигән нәрсә башка да килми иде.



УКУ Башлангыч мәктәпне үзебезнең авылда өч бала бетергән идек, берсе – Каразиреккә, икенчесе Туймазыга китте, берүзем җәяү сигез чакрымдагы Зиреклегә йөреп укыдым. Кышкы бураннарда да, язгы-көзге пычракларда да... Җырлап барам, җырлап кайтам, тавыш шунда ныгыгандыр: микрофонсыз да җырлыйм бит. Күрше авыл мәктәбенә барганда куркып калган чаклар да булгалады. Туңган агач шартлап сынып, әллә нинди шомлы тавышлар чыга... Бер-ике тапкыр алдан болан чабып үтте. Болан да курка, мин дә... Куркудан артка утырам, күз аллары караңгылана... Берүзем бит! Көн саен кайтып йөрергә тырыша идем. Кыш көннәрендә генә интернатта торгаладым. Барыбер дә өйгә кайтасы килә. Эш тә бар иде инде. Утынга да барып киләсең, басудан эскертне ачып, салам да алып кайтасың...

Зирекле зур гына авыл, мәктәбе дә көчле. Укытучылар «Зәңгәр шәл»ләргә хәтле куялар иде. Булатларны җырлап йөрергә туры килде. Беренче тапкыр тугызынчыда укып йөргәндә сыер савучылар алдында «Порт-Артур»ны җырладым. Бик каты кул чаптылар. Чын җырчы килгән диярсең! Гармунны 9–10 нчы классларда кулга алдым. Кызларга ошыйсы килә бит. Ә берчак Шаранда – апаларда иртән радиодан «Кайтыгыз, торналар!» җырын ишеттем. Габдулла Рәхимкуловның шул җыры мине тәмам сихерләде. Аны чыгарылыш кичәсендә дә җырлап, бөтенесен елаттым. Классташлар, торналар... Нииндидер тирән мәгънә салынган иде аңа! Уку белән бик мактана алмыйм. «Өчле» – көчле!» – диләр бит! Уку шул «өчле», «дүртле» тирәсендә инде. «Бишле»се дә эләгә, койрыклылары да була кайчак. Яраткан фәнем татар теле булды. Сәгъдәнә апа укытты аннан. Үзе дә матур җырлый иде. Шул җыр да якынайткандыр аңа.

Мәктәптән соң авылда – киномеханик, Туймазыда заводта – фрезеровщик... Станоклар төрле тавышлар чыгара, мин аларга кушылып җырлап йөрим. Тыңлап торган абыйлар: «Мәкамең матур, энекәш, син Уфага кит әле, җырчы бул», – диләр. Үземдә дә теләк булгандыр инде, авыл хуҗалыгы институтында укучы ике туган абыйга ияреп Уфага киттем. Җырлатып карадылар, ошаттылар. Уфа дәүләт сәнгать училищесының вокал бүлегендә дүрт ел укыдым. Башкорт дәүләт филармониясендә эшли башладым. Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе бүлегенә читтән торып укырга да кердем әле. Аны, шаяртып, филармония факультеты дип тә йөртәләр иде. Чөнки филармониядәге күп кенә артистлар шунда укыды. Югары белемең булса, акчаны 8-9 сум итеп бирә башлыйлар дигән сүзләр чыккан иде бит. Укып чыктык, диплом бар, хезмәт хакларын гына арттырмадылар: 6 сум 50 тиенгә, 7 сум 50 тиенгә эшләп йөрдек. Гел әйбәт укытучыларга эләктем. Камил абый Дәүләтшин: «Син үзеңне нинди студент дип йөрисең?» – дип сорый бервакыт. Заочник, дим. Читтән торып укучы, ягъни мәсәлән. Юк, син – укудан читтә торып укучы, дип көлгән иде. Шул елларда Ибраһим Салахов белән күп йөрергә туры килде миңа. Шаһинур Мостафин таныштырды безне. Университетта укыганда аның биографик әсәрләре буенча дәрес бара. Ә мин торып бастым да Ибраһим абый белән ничек йөрүләребез турында сөйләп киттем. Мөхәммәт Мәһдиев, Аяз Гыйләҗевлар белән бергә Ибраһим Салаховның 80 яшьлек юбилеен уздырырга аның туган җиренә – Күкчәтауга баруларыбызны, Кызыл Яр авылында төнлә гармун тартып урам әйләнүләребезне... Укытучының күзе шар булды! Ишетеп кенә беләләр бит, күргәннәре юк. «Моң һәм нур илчесенә» дип язып, «Колыма хикәяләре» китабын бүләк иткән иде миңа язучы. Гел юк өчен утыртып куйганнар инде аны! Галимҗан Ибраһимовка хат илтеп биргәне өчен генә!«Биш вакыт намазны ташламадым. Шул гына алып калды: акылдан язмадым», – дип сөйләде ул. Зифа Басыйрованың да ире шунда булган. Тобольскида рупордан Зифа Басыйрованың җырын тапшыралар, ә мон-

Фото: Анна Арахамия

да ире акылдан язып ята, ди... Андый истәлекләре күп иде Ибраһим абыйның. Таңга чаклы сөйләшеп утырган чаклар булды. Җырларымны елый-елый тыңлый иде...



УҢЫШ 1979 елда Башкорт дәүләт филармониясенә эшкә килгән көнне үк шундый бәхет елмайды: мине Фәридә Кудашева белән Бәхти Гайсин бригадасына алдылар! Күрәм: Бәхти абый филармония фойесында аппаратуралар белән мәш килә. «Син җырчымы әле?» – дип сорый. «Әйе, исәп бар иде», – дим. «Мәле, тавышыңны микрофонга биреп кара, тембрыңны тикшерәм, аппаратны сынап карарга кирәк. «Кара урман»-ны беләсеңме?» – ди. Илһам абый Шакировчарак итеп җырлыйм. «Иртәгә 11 гә репетициягә килерсең, Фәридә апаң авырыбрак тора, аны алыштырырсың», – димәсенме! Ул аппаратны түгел, мине сынаган икән! Кош тоткандай очып кайттым! Фәридә апа, Бәхти абый бригадасына эшкә алсыннар әле! Икесенә дә рәхмәтем зур! «Йөрәктән чыкса гына йөрәккә барып керә. Менә бу җырың йөрәктән чыкмады әле», – дигән чаклары да була иде Фәридә апаның. Ул инде килү белән иги башлый, әрләп тә ташлый. «Тавышың да бар, моңың да... Ләкин җырның эченә керә алмагансың, йөрәкне кушып җырларга кирәк!» – ди. Тавыш көчле чыксын дип кычкырам бит инде. Ә Фәридә апа: «Ишәктә дә тавыш бар, җырлый гына белми. Ул синнән дә ныграк кычкыра», – ди. Менә шулай төрттереп, оялтып әйтә сүзен. «Бәләкәй тавыш белән генә пышылдап әйт, ничек йөрәккә барып җитә... Менә шул була инде йөрәкнең иң нечкә кылларын тибрәтү», – ди... Бик күп сабак, мәгълүмат алдым аңардан. Җыр буенча югары уку йорты бетермәсәм дә, Фәридә апаның академиясен бетердем инде! Берничә елдан концертыма чакырдым. «Синең өчен җаным тыныч. Мин әйткәннәрне истә тоткансың», – диде ул.

1985 елда тальян гармунда уйнап җырлый башладым. Бөек Җиһүнең 40 еллыгына Уфада «Тальян гармун» бәйрәме үткәрделәр. Менә шунда инде «Герман көе»н башкардым. Мин ул җырның куплетларын халыктан үзем җыеп йөргән идем... Сценарий буенча, сугышка җырлап китәбез, апалар, әниләр кульяулык болгап, елап озатып калалар... Шундый сәхнә күренеше иде. Бу җырны күтәреп алдылар. Ветераннар сәхнә артына кереп: «Әллә, улым, син алдан туып, ничек киткәнебезне карап тордыңмы соң? Шулхәтле безнеңчә чыга бит!» – диләр. Күз яшьләре белән елыйлар... Ул минем мәңгелек җыр!

1988 елда мәдәният министры рөхсәте белән татар бригадасы оештырдык. «Моңнарыма кайтам» программасы кайда да уңыш белән барды. Уфаның үзендә генә дә 22 концерт куйдым. Тальянда – 14 җыр, баянда 14 җыр башкарам. Икешәр-өчәр концерт куйган чаклар да булды: 5 тә, 7 дә, 9 да. Биш-алты сәгать эчендә 80–90 җыр дигән сүз бу! Бик күп халык килә иде ул концертларга! Яңалык иде ул! Биш мең урынлы цирк бинасында биш концерт куйдым. Шыгрым тулы тамаша залы! Концертны 25 мең кеше карау – зур әйбер инде! Атлы милиция саклап тора иде хәтта! Уңышның сере дә – халык күңеленә керә алырлык сүзләргә язылган моңлы җырларны җиткерә белү осталыгында инде. Халыкның яраткан җырчысы булып йөрүнең сере шундадыр. Фәридә апа, Илһам абый, Әлфия апалар белән эшләү бәхете дә тиде миңа! «Уфадан килгән дустым Фән Вәлиәхмәтов. Чын безнеңчә җырлый ул! Мин дә яратам аның җырларын!» – дип, Илһам абый Шакировның тамашачыларны минем белән таныштыруын үзе бер дәрәҗә саныйм. Илһам абый концертлары кайда гына булса да, барырга, калдырмаска тырыштым. Шаһинур Мостафин минем иҗатка багышлап китап чыгарганда да сүз башын Илһам абый язды!



МӘХӘББӘТ Матур кызларга күз төшеп: «Их, шушы хатыным булса иде!» – дип йөргән чаклар да бар иде инде. Берсе дә миңа насыйп булмады: үз парларын таптылар. Кайчагында беренче мәхәббәт турында сорыйлар да, мин инде көлдерәм. «Минем беренчесе, икенчесе булып тормады, шундук өченчедән башладым, менә хәзер шуның белән яшим инде», – дим. Светлана белән студентлар ашханәсендә таныштык. Күрәм: берничә өстәл аркылы гына ике кыз утыра. Көлешәләр, пышылдашалар. Мин поднос илткәндә, кызларның берсе шулай ук подносын күтәреп килде. Подносларыбыз бәрелеште. Шунда язмышлар да бәрелешкән икән! Сүз арты сүз чыгып, сөйләшеп киттек. Очраша башладык. Үзе Борай кызы икән, Хәмдүнәнең якташы. Опера театрында костюмер булып эшли иде. Опера тыңлый, җырларга ярата, тавышы да матур. Ярар, мин әйтәм, җырлап йөрмәссең инде, минем хатын гына булырсың, дим... Менә шулай яшәп киттек. Инде 47 ел бергә без! Өч малай үстердек, хәзер оныклар сөябез. Светлана гомере буе балалар бакчасында эшләде, тәмле ашлар пешерде. Малайлар да әниләренә охшап аш-суга осталар. Светлана гадел усал ул. Минем әнкәй шундый иде. «Күзем чәчрәп чыкса да, әйтәсе сүземне әйтмәй калмаем», – ди торган иде. Ул да шундый. Килен – кайнана туфрагыннан дигән дию дөрес инде. Әнкәй кебек турыдан бәрә: үпкәләтермен дип тормый. Шундук онытa да: ачу саклап йөрми.



ДУСЛАР Фәнир Галимов күптәнге дустым. Очраклы гына таныштык. Туймазыда машинам ватылган иде берчак. Ә ул бер оешмада механик. Машина ремонтлауны бик тиз җайлады. Үзе дә көйләр яза, баянда уйнап җырлый торган егет икән. Хәзер иллеләп җырын башкарам. Шул машина ватылганнан бирле бергә инде без. Мөфтәдин Гыйләҗев, Венер Мөхәммәдиев, Зифа Нагаева белән дә иҗади дуслык дәвам итә. Ә миңа Казанны, Татарстанны ачкан, һәрчак колач җәеп каршы алган кеше Шаһинур Мостафин булды. Вагыйз Минһаҗев белән дуслыгыбыз Арча районы Сабан туеннан соң башланды. Вагыйз бүген дә иң ышанычлы терәгем. Заманында мине Арча Сабан туена тальянда уйнап җырларга чакырган иде. Мөхәммәт Мәһдиев – бер яктан, Гариф Ахунов икенче ягымнан кочаклап, тальян тартып, «Арча» көенә җырлап, мәйдан әйләндек. Вагыйз: «Фән туган, ал минем «Волга»ны, ә тальян гармуныңны миңа калдыр», – ди. Ризалашмадым. Кыңгыраулы мондый тальянны атаклы остадан үзем ясатып бүләк итәрмен, дидем. Берничә айдан барыбер шул ук гармунны Вагыйзга бүләк итәргә туры килде... Җандай якын күргән тальянымны стадионда узган кичке Сабантуйда урлап киттеләр бит! Казан гөж килде, га-

зеталар язып чыкты, Вагыйз бөтен милицияне аякка бастырды – тәки табылды тальян! Анысын Вагыйзга бүләк итеп, үземә яңаны ясаттым. Тальян гармун ясау остасы удмурт егете, Тәтешледә туган Җидеяр Мухаяров эшләп бирде аны. Җидеяр дус белән Чаллыда бер йортта, күрше фатирларда яшәү дә насыйп булды әле. Аның да үз тарихы... Чаллыга безне халык җырларын, тальян моңнарын яраткан Минтимер Шәрипович чакырды, фатир да бирделәр.



АКЧА Акча җитми дип, байлар, акчалы кешеләр белән сөйләшеп утырган бар инде. Аларга да җитми икән. Әрдәнәләр өйгән, вагон бушаткан чаклар булды, диләр. Бер акыл иясеннән сораганнар бит: гел рәхәт кенә булса, бу дөнья нишләп бетәр иде, дип. Әллә кайчан көле күккә очар иде, дигән акыл иясе. Күп акчалы кешеләр дә әллә ниләр күреп туктыйлар. Шул җитәр-җитмәс яшәүгә ни җитә дип кенә яшисе инде. 5 сум 50 тиенгә, 6 сум 50 тиенгә алты ел эшләп йөрдем. Аннан 7 сум 50 тиен түли башладылар. 17 ел эшләп чыгып киттем шулай. Ә инде популяр булгач, бераз акча эшләп, фатир, машина, мебельләр алып, очына чак эләгеп алдым җитеш тормышның. Башта гел филармониягә акча ташыдым. Биш бригада алып кайткан акчаны берүзем алып кайта идем.

Акча «умыра» торган җырчыларның сөйләшкәнен тыңласаң, исең китәрлек. Тайланд, Америка сөйлиләр. Ни кыланырга белмиләр. Чөнки акча сикертә! Айга менәрләр иде әллә! Сикерә-сикерә җырлап булмый ул. Йә сикерергә, йә җырларга гына кирәк. Сәхнәдә кызурак йөрсәң дә тынга каплана әле. Күпләр фонограмма куя да сәхнәгә чыгып физзарядка ясый. Андый концертны карар өчен билетны да ксерокстан чыгарылган акчага сатарга кирәк. Халыкны алдап йөрүләренә эчем поша минем. Кеше акча түләп килә бит инде, чын сәнгатьне ишетергә, чын тавыш тыңларга дип... Ә трафарет җыр тыңлап кайтып китә.



МАВЫГУ Кешедән калмыйм дип, умарта да асрап карадым. Анда инде бөтен җаныңтәнең белән берничә ай буе үзеңне умартага гына багышларга кирәк. Шулай булмаса, бу эшкә тотынасы юк. Күршем, башына киеп, өрдерә торган күреген тотып: «Әйдә, вакыт җитте», – дип, умарта карарга чакыра торган иде. Күршем бакыйлыкка күчкәч, аның кортлары да, минеке дә үлеп бетте. Аны сабый баланы караган кебек хасиятләргә кирәк шул, умарта тотып, корт рәнҗешен алырга ярамый.

Төзелеш белән мавыгып киттем. Һаман тукталган юк. Җәлил хәзрәт бервакыт радиодан сөйли. 60 ка хәтле куып тоталмаган дөньяңны 60 тан соң азапланып куарга ярамый, ди. Хәзер 70 кә җиттек инде, әле дә дөнья куабыз. Төпчек малай белән автосервис ачарга хыялланабыз.

Балык тотуны яратмыйм. Кайнешләр, җизни берчак мине балыкка кыстыйлар. Мин балык тотмыйм, балык ашамыйм, яр буенда гармун уйнап утырсам гына инде, дим. «Бөтен балыкны куркытып, качырып бетерерсең», – дип, көлеп чыгып киттеләр. Ауга чыгу, балык тотуларны кабул итә алмыйм, җан кыясым килми. Мавыгуым – җыр дөньясы, дуслар белән ял итү. Мин анекдотлар остасы да әле.

Кая барсам да, бөтен артистлар минем янга җыела. Салаваты да, Фирзәре дә, Раил Садриев та килеп җитә. Берәр яңа анекдот сорыйлар. Булган хәл, булмаган хәлләрне бераз арттырып та сөйлисең бит инде... Ха-ха да хи-хи... Җәвит Шакиров миннән ишеткәннәргә үзеннән дә өстәп, сәхнәләрдән дә төрле мәзәкләр сөйләп йөри. Шулай халыкны көлдерәләр. Хатын да башта көлә иде, хәзер көлми инде. Әзрәк җитди сүзләр дә сөйлә инде, ди.



БАЛАЛАР Өч улыбыз бар. Бәләкәйдән үк татарча сөйләшеп үстеләр. Руслан белән Раушан башлы-күзле булды инде, икешәр балалары бар: Рузана һәм Вилдан, Вагыйз һәм Азалия. Икесе дә юридик белемлеләр. Ләкин ул юлдан китмәделәр. Кеше язмышы белән булашасы, кеше рәнҗеше аласы килми, диделәр. Икесе дә нечкә күңеллеләр. Ә Румзаныбызның барысы да алда әле. Десант гаскәрләрендә хезмәт итеп кайтып, МЧСта эшли. Машиналар төзәтә, җырларымны туплау белән шөгыльләнә.



КУРКУ Балачакта урманда поши, боланнар күреп курка идек. Хәзер инде ул курку башкачарак. Күпләр менә үлемнән куркабыз, диләр. Ләкин аннан качып котылып булмый бит. Йөгереп тә кача алмыйсың – арттан куып тота. Иң курыкканым – картлык көндә ялгыз калу. Апалар үлеп китте дә, җизниләр ялгыз калды. Тегеләр баласына да, монысына да сыймыйча, каңгырып йөри-йөри, рәнҗеп бакыйлыкка күчтеләр. Берүк хатыныңның кадерен бел, сакла, диләр иде.

Афәтләр, сугышлар куркыта. Без күрәсен күрдек инде. Балалар, оныклар бар бит. Алар язмышы өчен борчыласың.



ҮЗЕМ ТУРЫНДА Яхшы якларымны да, начарларын да үземнән дә күп белгән кеше юк. Тегесен арткарак куеп, бусын алгарак чыгарып, баланс ясап, 50 гә 50 дип йөрисең инде. Һәр кеше шулайдыр.

Район үзәге Шаранда җир алып, йорт салдым. Мал-туар асрап, чәчәкләр үстереп, мунча себеркеләре бәйләп, үзебезчә яшәп ятабыз. Ничек бар – шулай инде мин. Әнкәйгә охшап, гомергә туры сүзле булдым. Әнкәй дә шундый иде. Берзаман кайттым да: «Әнкәй, суверенлык алдык, хәзер безнең байлык үзебезгә кала», – дим. «Улым, ул шул ук ыштан булыр, төймәсе генә тыштан булыр», – дип әйтеп куймасынмы! «Дөнья киң дип йөрибез дә без, кигән галош гел аякны кысып тора бит!» – дип, тирән мәгънә салып әйткәннәрен искә төшердем дә, әнкәйнең зирәк акылына шаккаттым.

Ә тормыш дәвам итә. Җырланасы җырым бетмәгән дип йөрим әле. Онытылган җырларыбызны халкыбызга кайтарасым, үзебезнең татар халкын сөендерәсем килә. Татар булып туып, башка милләт вәкиле булып үлеп булмый. Фәрештәләрнең сорау алуын үтәсе бар. Иң элек милләтең кем дип сорарлар ди анда. Татар булып тудым, башка милләттә үлдем, диярбезме? Тәүбә, тәүбә! Ходай күрсәтмәсен беркемгә дә! Кайчак менә шундый уйларга батып йөргән чаклар да була.



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Видео: Фәгыйлә Шакирова

PRESSA

Ул – Наҗар Нәҗми якташы: Башкортстанның Дүртөйле районы Наҗытамак авылында туа. Мәктәп елларында ук шигырьләр язган кызны Казан, ак колонналы университет, Тукай, Такташ эзләре гел ымсындырып тора. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә уку еллары исә аны шагыйрә, укытучы, журналист итеп әзерли. Уфада «Кызыл таң» газетасында әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире, Башкортстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары, татар әдипләре берләшмәсе җитәкчесе булып эшли. Укучыларга «Таң кызы», «Күңелем җимешләре» шигырьләр җыентыклары, «Язмышлар ярында» исемле публицистик язмалар китабы белән таныш. Мәҗит Гафури, Наҗар Нәҗми исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Башкортстанның атказанган матбугат һәм массакүләм мәгълүмат хезмәткәре.



Фәния ГАБИДУЛЛИНА-СӘЕТГӘРӘЕВА

САГЫНУЛАРЫМ БУЛЫП КАЙТАСЫҢМЫ?

Әнкәй хаты

Язмаларым арасыннан
Төште бер хат.
Хәрефләре шундый таныш, –
Алдым бик сак.

Чит-читләре бөгәрләнгән,
Уңган кәгазь, –
Гүя кулдан-кулга йөргән
Изге вәгазь.

Күзләр түгел, хәтер чаба...
Хат юлыннан.
Бер абына... Бер сикерә
Шатлыгыннан.

Хаталарым әйтмәсәм дә,
Сизгән әнкәй.
Юлларыма йомшак сүзләр
Тезгән әнкәй.

Вәгазь кебек укылган ул
Шуңа кат-кат.
Әнкәй сагышларын йотып
Саргайган хат.

Сагышларга салыр хәлләр
Ай, булды шул...
Юлларымнан бик еш кына
Тайпылдым шул...

Яратканнар, җан атканнар
Утлар салды...
Шул чакларда гел коткарды
Әнкәй хаты.

Тормышта үз сукмагыңны
Салу өчен,
Дусларыңның ихтирамын
Алу өчен,

Никадәр көч кирәклеген
Соң аңлыйсың...
Бары әнкәй мәхәббәтен
Юк яулыйсы...

Соңлаган очрашу

Әллә юлың,
Әллә төшеп уең –
Ишегемне кактың...
Әллә кайдан,
Булды бугай айдан:
Йортка үтте якты...

Син тоймадың,
Ә бәлки тыймадың:
Тамды ике яшең.
Уттай телде
Алар боз күңелне,
Әйтерсең лә – яшен.

Их, ул яшен
(Белми безнең яшьне)
Ник көзләргә калган?!
«Килде сөю
Картлыкта да», дию –
Күрәләтә ялган.

Җәйге күлмәк
Көзен булсаң кимәк,
Килешерме икән?

Синең яшең –
Ул адашкан яшен:
Көтмә яңгыр, иркәм.
Җәйләр инде үткән...

* * *

Икебезнең язмышларны
Җырга салдың.
Җырың килеп ирешкәч тә
Танып алдым.

Тик бу моңсу җырны тыңлап
Уйга калдым.
Димәк, син дә нидер көтеп
Каңгырасың...

Наз көтәм...

Яз да түгел, көз дә түгел,
Салкын кышның уртасы:
Бер туңдыра, бер эретә,
Һәм юлларда су ташый.

Кыеклардан тамчы тама,
Сулкылдый җирдә ак кар...
Кышның уртасында тамган
Тамчыда нинди наз бар?!

Өйрәнеп беткәндә генә
Җелеккә үткән җилгә,
Ымсындырып бу күңелне,
Тамчым, тамасың нигә?

Боз өстендә тамчы бии:
Һәр мизгелнең үз назы.
Күпме генә алдансам да,
Тамчыдан килмәс язым...

Туган якта

Таныш тугаемда басып торам,
Җил тарткалый хыял җепләрен.
Ялгыз Ай да мине күзли кебек,
Ачып-ябып болыт-челтәрен.

Уйларымның тышауларын чиштем:
Дуласыннар әле иректә.
Кылганнарның көмеш кылларында
Чикерткәләр әнә моң чиртә.

Җилләр... җилләр.
Тынгы белми бер дә:
Ялгыз талның тарта чәчләрен.
Шул тал кызын җәлләп куйдым әле, –
Бигрәк авыр ялгыз кичләрен...

Уйлар, уйлар... Әле таугa басып,
Әле суга чумып сер түгә.
Буш кесәле җилләр генә йөри...
Ә аларга синең сер нигә?

Басып торам таныш тугаемда...
Туган якның эчәм җилләрен.
Зәңгәр күкнең йолдызлы шәленнән
Эреп китә талган иңнәрем.

Туган яклар сагындыралар шул:
Тауга ятып елый болыт та.
Монда җилләр хәтта дога укый, –
Тоталмадым уйны калыпта...

Эңгер төште әнә җилкән булып,
Җилкәнгә җигелде уйларым.
Ваемсыз бер бала булыйм әле:
Йөгерсен уйларым – тыймадым.

* * *

Күрегезче, тал уянган, –
Ачкан күз кабакларын:
Бөреләре, нота кебек,
Сырыган сабакларын.

Җил-дирижер гына тисен, –
Җанлана нота-бөре.
Шушы тәүге симфония
Көенә тамчы биер.

Төшләремнән генә югалма

Сагынуларым булып кайтасыңмы, –
Көн дә сине төшләремдә күрәм.
Ник әйттем соң юксынырлык булгач:
«Сине түгел, башка берне сөям...»

Томан арасыннан елмаясың,
Күзләреңдә сөю уты һаман.
Йөгереп барып кочаклыйсы иде,
Тик арада ята куе томан.

Үкенүләрем булып керәсеңме
Төшләремә минем кабат-кабат?
Күңелемнең бер ярсу чагында
Үзем әйттем: «Башка берне ярат!»

Хәзер менә сагынып көтеп алам,
Төшләремдә елмай кабаттан.
Күкрәгеңә ятып елар идем...
Ни кызганыч, инде таң аткан.

Җырың кайта

Еракларда калдың, йөрәкләрдә
Очрашуны көтеп яши өмет.
Төшләремдә кочагыңда эрим,
Ә чынында дөрлим учак кебек.

Язларымда язган хатларымның
Битләрендә елый җилләр генә.
Синең иреңдәге минем тәмне
Оныттырды икән кемнәр генә?

Сөюемнең кайтавазы булып,
Саргаймасын диптер сагышлардан,
Җырың гына кайта хәбәр булып,
Җырың кайта миңа багышланган.

Җырларыңны тыңлыйм, уйларыңны
Бик беләсем килә, бүлешәсем.
Синең кебек мин дә көтәм көн дә
Яшьлегемә кабат юл төшәсен.

Сагыныр кешем булган өчен яшим,
Югалтуым көчле табышлардан.
Сөюемнең кайтавазы булып
Җырың кайта миңа багышланган.

Көтеп алалмыйм

Болыт күрсәм, яңгыр көтәм:
Яумады инде күптән.
Җир-сылуның иреннәре
Чатнап ярылып беткән.

Килмә, болыт, буштан тулып,
Юмаганга җир битен.
Сусаганда сиңа карап
Ымсынулар бик читен.

Сулыш җиңеләер иде,
Яңгырлы җилләр иссә.
Бу җилләр кайда йөри соң?
Куырды тынны эссе.

Яшен булып атылырдай
Булам үзем күкләргә!
Болытларны уятырга,
Күкрәү булып күкрәргә!

Түгелепләр явар идем,
Коткарыр идем җирне.
Тик һаман көтеп алалмыйм
Мине кузгатыр җилне.

Тыңлый белсәң...

Авылыма кайттым.
Тып-тын монда.
Җанны басмый шәһәр һавасы.
Карлары да ап-ак мамык мендәр, –
Йоклыйм дисәң – шунда авасы...

Озын булып төтен чыкмый инде
Торбасыннан авыл миченең.
Ә шулай да тәме, исе башка
Туган якның кышкы киченең.

Елгалар да калын бозын ярып,
Тәмле һава чыккан суларга...
Тын алалар ап-ак парлар бөркеп,
Авыл исе тансык суга да.

Тып-тын монда. Хәтта мамык карның
Ишетелә җиргә кунганы.
Тыңлый белсәң, тынлыклар да сөйли:
Туган якны шулай тыңладым.

* * *

Туган якларыма кайтсам,
Җилләренә битем куям, –
Таң җилендә әнкәемнең
Кулларының җылысын тоям.



Дилбәр (Сөләйманова) Булатова – Чакмагыш районы Кашкар авылы кызы. Башкорт дәүләт университетының татар-рус бүлеген кызыл диплом белән тәмамлый. Филология фәннәре кандидаты. Башкортстанда яшәп, татар телендә иҗат итүче язучы, публицист. «Тулпар» журналында әдәбият бүлеге мөхәррире. «Туй», «Көлдән яралган гөл», «Соң түгел» китаплары авторы. Хикәяләре җылылыгы, чисталыгы, ихласлыгы, матур теле белән җәлеп итә. Илдар Юзеев исемендәге премия лауреаты. Башкортстанның атказанган матбугат һәм массакүләм мәгълүмат хезмәткәре.



Дилбәр БУЛАТОВА

КҮЛМӘК

(Хикәя)

Июнь башлары иде. Кояш – бу биниһая зур ут шары – Җир гомерендә миллионмы, миллиардмы – ничәнчедер тапкыр көнбатыш тарафка юл алды. Офыкларга әле шәфәкъ алсулыгы иңмәгән, шулай да көн кызуы инде сынган; дисбе тарткан карчыклардай, яфракларын шыбырдатып сабыр гына нидер көткән агачлар, озынайган күләгәләр, каяндыр исеп-исеп куйган салкынча дымлы җил, көндез ямь-яшел булып, хәзер каракучкылланыбрак күренгән үләннәр – бар нәрсә озакламый кич җитәчәгенә ишарәле кебек.

Тирә-ягында күгелҗем урманнар, көньягында җәйрәп зур буа яткан авылда да шул ук гомум халәт, ул да фанилыкның илаһи симфониясенә кушылып, үз көен, үз моңын көйли сыман. Әнә яшькелт йомшак йомгаклар – атналык каз бибиләре – көн буена йөри-йөри тәмам алҗып, әнкәләренең канат асларына сыенганнар; әнә китмәннәрен иңбашларына салган чөгендер утаучылар кичке тынга эшкә киттеләр, әнә ялкау көтүчеләр, мәңге туймас сыерларны сүгә-сүгә, көтүне туплаудан алып чыктылар...

Биш-алты йөз йортлы Чыршыбаш исемле бу авыл инешнең калкурак уң як ярына утырган. Түбәнрәк, яшелрәк сул ярда да ике дистәләп өй күренә. Бу кечкенә урамның, әйтсәм ышанмассыз, өч исеме бар. Беренчесе, монда килгән хатларның тышына языла торганы, «Яшьләр» урамы булыр. Икенчесе – «Нахальный». Болай дип аръяклар әйтә. Көнләшеп, кызыгып, төрттереп әйтәләр. Бу яклар бердәй уңган, дөнья көтәргә хирыс халык, шуңа эчләре поша аларның. Урам хуҗалары үзләре инде: «Без – Котылдыклар!» – дип эре чирттереп сөйләшәләр. Нихәл итәсең, өч исем дә җисеменә бик туры килә. Гел яшьләр яши монда, алар төп нигездән, әти-әни, кайната-кайнана йортыннан аерылып чыкканнар, ягъни дә «котылганнар» (кем кемнән котылгандыр, анысын Ходай белә).

Өйләрен алар теге, иркенрәк заманнарда, законын белеп, кирәк-яракларын колхоздан ярты хакка килешеп алып төзеделәр. Тырышлыклары да бар: бакча тутырып яшелчә-җимеш үстерәләр, мал асрыйлар, умарта тоталар. Берчак шулай стенка, дивандыр модага керде. Хаклар ару гына, колхозда ел буе эшләгән акчаң да җитмәле түгел. Нишләделәр, дисезме? Йөз гектарлык басуны үзара бүлешеп алмасыннармы?! Бишәр-алтышар гектар җир утасалар утадылар, ике-өч елда җиһазлы булдылар. Япон телевизорлары инде – икешәр бакча бәрәңге утыртып, аны утап, күмеп, көзен казып, җыеп, Уфа базарына илтеп бидрәләп-килолап «өф» итеп сатудан килгән акча җимеше. Дөньялар үзгәргәнгә артык уфтанмый, хак менгәнгә дә артык пошынмый көн күреп яталар шулай. Нишлисең, патшалар килә тора, китә тора, ә хакыйкать һаман бер: крестьянны ике кулы һәм күкрәк көче туйдыра, ул бары үз-үзенә таяна да, Ходаена сыена. Маңгай тирен түгеп тапкан хәләл икмәге диңгез артының җәннәти деликатесларыннан тәмлерәк аңа.

Менә шушы Яшьләр–Нахальный–Котылдыкның күпер як очында, көн кичкә авыша башлаган бер мәлдә «КамАЗ» машинасы пәйда булды. Ул яман гөрелдәп-дөбердәп, тузаннар куптарып, каз-үрдәкләрне пырхылдатып тузгытып, урам буйлап килде-килде дә урта тирәдәге бер йортның капкасына борты белән терәлә язып туктап калды.

Юан бүрәнәләрдән биек итеп салынган йортның урам як тәрәзәсеннән ак яулыклы баш үрелеп карады, ишек ачылганы, «Рузилә, этиеңә капка ач!» – дип кычкырган тавыш ишетелде. Ул арада хуҗа үзе – уртачадан озынрак чандыр гәүдәле, йөзенең каракучкыллыгы, борынының кәкрелеге, зур кара күзләре белән азрак кавказ кешесенә дә охшап торган ир – бәләкәй капкадан килеп керде.

– Ачма, кызым, – диде ул 10 яшьләр тирәсендәге аксыл чәчле ягымлы йөзле кызга. – Бүген машинаны гаражга илтәм.

«Әттә!» – дип каршысына йөгереп чыккан үзе кебек кап-кара бәләкәй малайны: «Һа, улым!» – дип, күтәреп алды. Соляркалы бармагы белән аның борынына «пи-ип» дип баскан иде, малайның йөзе бозылды, ул, гарьләнеп, авызын бәлшәйтеп елап җибәрде.

– Менә инде, кайтып кермәс борын сабыйны елата! – Йомры гәүдәле, түгәрәк ачык йөзле хатыны Рәйсә, җитез генә күтәрмәдән төшеп, улына үрелде. – Кил, бәбкәем, кил, «өф» итәбез. Авырттырдымы әттәң? И-и шуны!..

– Яклашма! – диде Рәшит. – Егет кеше елап торамыни. Әнә, бетте дә!

– Аш пеште, токмач кына кабартып аласым калды, – диде хатын. – Әйдә! Рузилә, түтәлдән суган белән укроп алып кер, яме, кызым!

– Башта анауны бушатыйк әле, көрәкләр алып чык, – диде Рәшит.

Рәйсә тиз генә көрәкләр алып килде. Арба төбендә биш-алты чиләк чамасы асфальт калган икән, шуны бәләкәй капка астына ком-таш өстенә бушатып, бүкән белән тәгәрәтеп, тигезләп куйдылар.

– Яңгыр яуса, чокыраеп, су җыелып торадырые, шәп булды, – дип сөенде Рәйсә.

Рузилә өйдән җылы су алып чыгып бакчадагы юынгычка салды. Әтисе бил тиңентен чишенеп ташлап, юына башлады.

– Юл салдыгызмыни? – дип сорады Рәйсә иреннән.

– Иртәгә Сабантуй бит. Кибәрме... Чит илдән кунаклар килә, ди. Тырышалар инде. Акча бирделәр азрак.

– Әйбәт булган, балаларның аягына карарбыз иртәгә. Мин чөгендергә мендем. Шыр чүп, ул ике гектарның очына җиткәнче күзләр чыгар инде.

– Ярар, ярар, кыш буе тик ятасың, маең кимер азрак. – Ир хатынын шулай шаяртып алды.

– Әй монауны! – диде тегесе. – Эш бармыни? Булса, рәхәтләнеп кеше арасында эшләп кайтыр идем, йөзем якты булыр иде. Тик ята дип инде, ул абзар тулы малны кем карыйдыр?! Әнә, Нәҗипнең хатыны...

– Нәҗип кайтканмыни? – диде Рәшит, аны бүлдереп.

– Кайткан шул. Зур машина белән кайткан, артында кибет. Әллә нәрсәләр төягән, Сабантуйда акча сугаргадыр исәбе. Парашугы кибетнекеннән очсызрак түгелме икән дип барганыем. Сине сорашты. Әйтергә дә онытып торам менә. «Килеп китсен әле», – ди. «Быел тагын туры баганага менәме, барамы Сабантуйга?» – ди.

– Алай икән... – Хатыны сузган тастымалга Рәшит бит-кулын сөртте. – Нәрсә диден соң?

– Кырыкны куган башы белән колгага үрмәләп йөрмәс инде, – дидем. Былтыр да менеп җитә алмадың, тынычлангансыңдыр, шәт...

– Былтыр салган баштан бит ул. Быел менеп җитәм, Аллаһ боерса!

– Һәй-й, бала-чагалыгың һаман чыгып бетми, – дип сукранды Рәйсә. – Әйдә, керик, аш суынадыр...

Ашап чыккач, Рәшит Нәҗипләргә китте. Рәйсәсенең туган көне якынлаша, шәһәрдән күлмәк-фәлән алып кайтырга кушып, үткән юлы биш йөз сум акча биреп җибәргән иде. Чакырган бит әнә, мөгаен, алып кайткандыр.

Классташлар алар. Рәшитләр сигездән соң СПТУ бетерделәр дә авылда калдылар, ә Нәҗип унны тәмамлады, аннан Уфага чыгып китте, техникумда укып йөрде, ниндидер складтамы, базадамы эшләде, ә хәзер инде алыпсатарга әйләнде. Әти-әнисе вафат булдылар. Котылдыктагы бертуган энекәшенә кайтып йөри ул. Кайткан саен машинасын тутырып кирәк-ярак тауар алып кайта. Алалар, кибетнекеннән очсызрак, юк нәрсәсе юк. «Уфада әллә ничә киоскым бар», – дип сөйли үзе. Бардыр. Укып йөргәндә чебеш кебек кенә нәрсә иде, хәзер битләре өреп кабарткандай шома, алсу; корсак, чалбар каешын менә өзәм, менә өзәм дигәндәй, күпереп тора; кыяфәт шәп, кием күннән дә тиредән; машина яхшы, чит илнеке... «Череп баеса да, эреләнми, авылны онытмый, туганнарын ташламый», – дип ихтирам итә аны Рәшит. Очрашканда күрешеп, хәл-әхвәл белешеп, сөйләшеп йөриләр.

Нәҗип урамда су колонкасы янында машина юа иде. Әллә нинди чуар төстәге, попугайлар төшкән футболка белән шорты киеп алган. Өр-яңа «ГАЗель»ен шундый мөкиббән китеп, тәмләп юа, тәрәзәләрен, көзгеләрен шундый яратып сөртә, гүя машина түгел, кадерле бер җан иясе. Тирә-юньдә һичбер гаме юк – Рәшитнең сәламен дә ишетмәде. Кабат эндәшкәч, кырын эштә тотылган кешедәй, сискәнеп китте.

– Ә-ә, сабакташ! Синмени?.. – дип, кулларын чиста чүпрәккә сөртте һәм уң кулын сузды. – Сәлам, нихәлләр?

– Тәгәри, – диде Рәшит. – Үзең ничек?

– Менә, – Нәҗип машинага ымлады, – монавы кыр кәҗәсен кырыштырам. Ничек, ошыймы?

– Шә-әп! – диде Рәшит фирүзә төсле өр-яңа «ГАЗель»-гә сокланып. Үзенең гаражындагы егерме еллык «Москвич»ын күз алдына китереп, ирексездән көрсенеп куйды.

– Әйдә әле, керик, сабакташ, – диде Нәҗип, – сиңа сүз барые.

Җимеш бакчасына энекәше өстәл ясап куйган икән, утырырга иске тимер карават та чыгарганнар. «Безгә дә шулай эшләргә кирәк әле», – дип хәтеренә бикләде Рәшит. Нәҗип машинадан бер ярты, ике сыра алып килде, өйдән тозлы кыяр, пешкән ит, телемләп туралган суган алып чыкты.



– Миңа салма. Ташладым! – Рәшит стаканын каплады.

– Кара син аны! Чынлапмы? – дип гаҗәпләнде дусты. – Молодец, молодец! – Стаканны авызына каплап, бер тында эчеп бетерде дә кетердәтеп кыяр чәйни башлады. – Ә мин капкалыйм сирәк-мирәк. Эш авыр: нервылар, стресс... Ял юк, йокы юк, малай... Ә син менә сыра йот алайса... Ә-ә, онытып торам, синең заказны үтәдек бит! – Нәҗип кабат машинасына таба китте. Рәшит аның кызыллы-яшелле футболкасына, шорты балагыннан тырпаеп торган йонлач кәкре сыйракларына карап: «Иллә килештерә соң бу шәһәрләр», – дип баш чайкады.

– Мондый күлмәк Чыршыбаш хатыннарының төшенә дә кермидер, – Нәҗип күксел төстәге күлмәкне таратып җибәрде. – Кара, материалы нинди яхшы, фасоны да Рәйсә өчен үтергән. Хатын толчоктан ярты көн буе эзләп, сайлап йөргән.

– Ни хак соң? – диде Рәшит, түземсезләнеп.

– Үз бәясе инде, сиңа арттырып сатмыйм, мең тәңкә!

– Мең тәңкә... Биш йөзен биргән идем, тагын биш йөз кирәк, димәк... – Рәшит түш кесәсеннән кульяулык чыгарды, авыр эштән тупасланган юан бармаклары белән аны ипсез генә сүтеп, бүген хисапчы биргән биш йөзлекне алып Нәҗипкә сузды.

Сабакташы акчаны алмады.

– Куеп тор әле, – диде ул, Рәшитне үтәли күрергә теләгәндәй сөзеп карап. – Мин сине чүпрәк күрсәтергә генә чакырмадым. Эш чыгып тора. Ярдәм итә аласыңмы?

– Нинди эш?

– Иртәгә Туймазыга тауар кайта, шуны Уфага илтергә кирәк. Председатель белән сөйләшенгән, ягулык миннән, накладнойларны бухгалтер әзерли. Акчаңны кире тыгып куй, артык түгелдер. Анда веранда да башлагансың бугай. – Күлмәкне пөхтәләп төреп, чыштырдавык капчыгына салып, Рәшиткә сузды. – Өстәп миннән берәр литр «Бәләбәй», берәр дистә «Прима». Көн эчендә әйләнәсең, туган, кичкә кайтып та җитәсең. Бер көндә җиде йөз чамасы керә, начармыни?

– Иртәгә Сабантуй бит әле...

– Булса ни! Ел да инде ул. Яренгә барырсың...

Рәшит аптырады, башыннан йөз төрле уй үтте. «Елына бер генә бит әле ул Сабантуй... Баганага менәм дип, шоферлар белән бәхәсләшеп тә беткән иде. Биш йөз сум... Әле тагын кайчан акча бирәләр... Бер дистә «Прима»... Яртыларына бензин алсам... Верандага пыяла кирәк...»

Нәҗип аның эндәшми торуын азсынудан дип уйлады, ахры:

– Ярар, тагын бер дистә тәмәке өстим, рәхәтләнерсең тартып, – диде.

Рәшит йодрыгы белән тезенә сукты:

– Ачуланма, яшьти, булмый, баралмыйм!

Нәҗипнең йөзе үзгәреп китте. Рәшит баш тартыр дип һич көтмәгән иде, күрәсең. Юка иреннәре кысылды, авыз тирәсенә тирән җыерчыклар буйланды.

– Нигә? – диде ул тонык тавыш белән.

– Сабантуйга бармыйча булмый бит... Безнең карап торган бер бәйрәм бит ул... – диде Рәшит һәм учына йомарлаган биш йөзлекне Нәҗипкә сузды. – Алып кайткансың, рәхмәт. Үпкәләмә, яшьти, башка вакытта тыңлармын.

Нәҗип акчаны алып тигезләп икегә бөкләде, күнегелгән хәрәкәтләр белән шортигының арткы кесәсенә салды.

– Ярар инде, мин үзеңә дә файда булыр дигән идем...

Рәшитне ул озата чыгып тормады.

Чагылтау итәгендәге киң, иркен яланда яшел яшь үләннәрнең чыгы да кибеп бетмәгән иде, аларны изеп, таптап, йөзләгән, меңләгән аяклар үтте. Халык район Сабан туе үтәчәк мәйданга агылды. Стадион тирәсендәге буяулары кибәргә дә өлгермәгән эскәмияләрдә, бер читтәге кибетләр рәтендә аклы-зәңгәрле, кызыллы-яшелле чуар дулкыннар чайкалды. Шашлыкчылар учак тергезделәр, урман һавасына әчкелтем төтен, кыздырган ит исе кушылып, җил белән тирә-юньгә таралды. Динамиклардан дәртле бию көе яңгырый башлады.

Чүпрәк сумкаларын күтәргән түтиләр кирәк әйберләрен алырга ашыгып, бер машинадан икенчесенә чапты; агай-эне агачлар арасынарак кереп, гәзит җәеп, табын ясап кәеф-сафа корды; Сабантуйга дип атап кайтучылар, төшләренә кереп йөдәткән балачак дусларын, танышларын очратырга, кемнедер таныргa өметләнеп, әрле-бирле йөрде; көяз яшь кызлар, мыек чыга башлаган малайлар бер-берсен күзләде. Кайдадыр эсседән, кеше күплектән көйсезләнеп яшь бала елады, бәйгене көтеп түземсезләнгән атларның кешнәве ишетелде.

Доклад, парад ише рәсми өлешләр бетүгә, мәйданга чабыш атларын чыгардылар. Балалары, Рәйсәсе белән ат ярышын карап утырган Рәшитнең куанычы эченә сыймады, үз колхозларының чаптарлары, аннан юртаклары өчен җан атты, малай-шалай сыман һайтлап-сызгырып, хатынын ачуландырып бетерде. Нишләсен соң инде, ярата бит ул шушы Сабантуйларны, шушы ат ярышларын. Күкрәк кагып чапкан атларның ярсуы, ярыш дәрте аңа да йога, йөрәге еш-еш тибә, күзләре очкынлана – юаш, басынкы Рәшит тә димәссең.

Халык ат бәйгесеннән соң бушап калган мәйданга сибелде. Билгеләнгән җаваплы кешеләр төрле-төрле уеннар, ярышлар оештырып җибәрде. Рәшитләр капчык сугышын, көянтә белән су ташучыларны, башлары белән чумып катыктан тәңкә эзләүчеләрне, капчык киеп йөгерүчеләрне, күз бәйләп чүлмәк ватучыларны карап йөрделәр. Ап-ак озын киемнәр кигән, әллә нинди ак япма ябынган озын таза гәүдәле, кара-кучкыл тәнле, әкәмәт зур күзле чит ил кешеләрен күреп тамаша кылдылар. «Күрәсезме? – дип эченнән генә кәпрәйде Рәшит. – Сезнең мондый тантананы гомердә дә күргәнегез юктыр. Шулкадәр халык җыелган, шундый күңелле бәйрәм бездә генәдер ул. Безнең, үзебезнең бәйрәм шул бу!»

Аннан Рәшитнең баядан бирле карый-карый муеннары кыйгайган якка юнәлделәр. Туры багана кырына хәтсез кеше җыелган. Бик вакытлы килгәннәр, бала-чаганың менәсе менеп төшкән, чират өлкәннәргә җиткән иде. Бераз карап тордылар. Юк, әй, очына чаклы беркем дә менеп җиталми. Бер-ике метрлап калды, инде менеп җитте дигәндә, бәрәңге сабагыннан тәгәрәгән колорадо коңгызлары сыман, кире шуалар да төшәләр.

– Сабынлаганнар... – ди күзәтүчеләрнең берсе.

– Һе, ансыз буламыни, – ди икенче берәү. – Кичә үзем күрдем, ярты тартма сабын ышкыдылар.

– Уф Аллам! – дип Рәйсә уфтана.– Әллә маташмыйсың гынамы, сиңа әйтәм. Менәлмиләр бит әнә. – Әмма иренең трико балакларын сызгана башлавын күреп тынып кала.

Рәшит күлмәген хатынының кулына тоттырды да, кешеләрне ерып, багана төбенә үтте. Өч кешедән соң аңа да чират җитте. Ул кулларын төкрекләп бер-берсенә ышкыды, тирән итеп сулап, шома салкынча баганага тотынды. «Үзең көч-дәрман бир, Ходаем!» – дип, эченнән генә теләк тели-тели, җәһәт кенә югарыга үрмәли башлады. Күрер күзгә бик тиз генә ярты араны узды. Ләкин өскә таба багана да нәзегәйде, аяк-куллары да талды. Шома, бик шома иде багана. Баштарак әрнешеп, уттай янган беләкләре, ботлары берни тоймас булды, чүкеч белән дөп-дөп суккандай, чигәсендә кан тамыры сулкылдады. Рәшит бар җегәрен туплады, үҗәтләнеп, тискәреләнеп: «Менәм, барыбер менәм!» – дип пышылдады.

Җир аска тарта, теләк-максат өскә, югарыга өнди – шул ике көч арасында бер җан иясе – кеше тартыша. Биеклеккә өндәүче, чакыручы нинди көч бу? Югарыга үрләгән саен авыр... Гәүдә-бәдән күлмәк түгел шул – салып ташлап торып булмый... Балчыктан ясалган ул...

– Әйдә инде, әйдә! – Астан шундый тавыш ишетелде. «Инде егылып кына төшә күрмәсен!» – дип теләп торган җиреннән, үзе дә сизми, кешеләрдән дә тартынмыйча, шулай дип кычкырды Рәйсә. Ул иренең һәр хәрәкәтен керфек тә какмый күзәтә, каерылган саен һәр мускулы, һәр сөяге беленеп киткән ялангач аркага, шушы кадерле һәм газиз гәүдәгә үз тыннарын бирердәй булып тора иде. Әниләрен җитәкләгән балалар да авызларын ачып әтиләренә карыйлар, аның менеп җитүен телиләр иде.

Таныш тавыш Рәшиткә көч иңдергәндәй булды, аның икенче сулышы ачылды, әүвәлге җаен алып, үрмәләвен дәвам итте. Бер, ике, өч! Булды! Җинде!!! Иң очка кагылган аркылы таякка уң кулы белән тотынды да аска карады. Кечерәеп күренгән кешеләрне, аларның үзенә сокланып карауларын аерды, халык диңгезе чайкалган мәйданны күздән кичерде, көрәш мәйданында алышкан ике баһадирны чалымлады. Аннан еракка-еракка җәелгән яшелләнә башлаган басуларга, еландай боргаланып офык читенә карап, күкрәк тутырып бер тын алды да, аска шуып төшә башлады.

– Һай, маладис!

– Булдырдың! Егет икәнсең!

– Иң беренче бу менде, – диештеләр карап торучылар.

– Нәрсә бирерләр икән? – дип, хатыннар сөйләнде. Бу ярыш өчен җаваплы кеше Рәшитне бүләкләр салынган тартма янына чакырды.

– Кирәкми, – дип кул селтәде Рәшит.

– Бар, бар, сайла, – диделәр аңа, аркасыннан кагып, истәлеккә калыр.

– Менеп җиткәнгә әйбәтрәк әйбер кирәк, ату биш метр менсә дә яулык, менеп җитә язса да яулык, – диде тартма кырына җыелган кешеләрнең берсе.

– Ике әйберне сайлап алыгыз, – диде район кешесе Рәшиткә. – Балаларыгыз бармы? Менә әйбәт кенә сандалилар...

Күктән җиргә төшкән Рәшит Рузиләгә аяк киеме кирәклеген хәтерләде. Гади генә, арзанлы гына сары сандалиларны, ак ситсы яулыкны алды да, үзенә төбәлгән карашлардан кыенсынгандай, бөрешеп, түгәрәктән чыкты.

Кайтып китәр алдыннан кибетләрне караштырып чыктылар. Арада Нәҗипнең машинасы да бар иде. Нәҗипнең авызы ерык, кәефе шәп. Нәрсә кирәклеген чамалап, белеп алып кайткан, газлы суларын, тәм-томнарын сыпыртып алып бетергәннәр. Балаларга печенье алырга туктаган Рәйсәгә, киң күңелләнеп, бушка матур тышлы ике сагыз да өстәп бирде әле ул.

Сабантуйлар үтте дә китте, бераздан тагын бәйрәм – Рәйсәнең туган көне җитте. Рәйсә йомры беләкләрен сызганып куйган, чәчләрен яшереп ак яулык бәйләгән, чак кына кыскарак бармаклы кабарынкы кулларына күз иярми – җәһәт-җәһәт ит, бәрәңге, суган турый, тозборыч, әнис сибеп болгата. Каплап өлгерткән камырны алып, ике җәймә җәя. Зурысын майланган табага җәеп, эчлекне бушата. Кечерәк җәймәне бәлеш өстенә каплап, астагы җәймәне күтәреп, чит-читләрен оста итеп бөреп чыга. Табаны, читеннән табагач белән эләктереп, мичкә тыга. Күмерләрне кисәүгач белән этәреп, йөзлек куя, морҗаны яба да сәгатьне искә ала. Маңгаена типкән бөрчек-бөрчек тир тамчыларын кул сырты белән сыпырып ташлап, салатлар ясарга тотына, алары бетүгә татлы камыры көтә. Үзенең йөзендә кояш балкый, дөньядан разыйлык, канәгатьлек ташып тора.

«Бәхетлемен, – дип уйлый ул еш кына, – тырыш, уңган ирем, сәламәт балаларым, үз дөньям бар, Аллага шөкер, күзләр тимәсен...» Яратылган һәм үзе дә яраткан хатыннар гына шулай бәхетле буладыр. Ә ире ярата Рәйсәне, яратмаса, туган көненә бүләк алып мәшәкатьләнер идемени! Авыл җирендә туган көн-фәлән дип бик туарылмыйлар, кая анда кунак җыеп зурлап үткәрүләр. Ә Рәшит онытмаган. Ел да шулай инде ул, бүләксез калдырмас.

Бүген иртән көтү куып керүгә, өстәлдә ялтыравык әйбер ята. Рәшит үзе юк, эшкә киткән. Янчыкны ачып, эчендәге күлмәкне алып караса, аһ итте. Яңарак, районга баргач, базарга сугылды, анда нәкъ шушындый күлмәккә күзе төшкән иде бит! Кызыгып киеп тә карады, инде таман, инде матур иде! Алырлык акчасы булса да, тыелган иде Рәйсә, төзи башлаган веранданы, балаларына кием аласы барлыкны уйлап тыелган иде. Тиз генә халатын салып атып, күлмәкне киеп, көзге алдына килде. Шул, үзе! Каян сайлап ала белгән Рәшите – ул төсе, ул таманлыгы!

Кешегә күп кирәкмени инде, рәхәтләнеп шул күлмәк турында, аны киеп кайларга барачагын уйлый-уйлый, Рәйсә бәйрәм өстәле әзерли. Тәрәзәдән иренең кайтып килүен күреп, каршы чыкты:

– Сиңа әйтәм, тап-таман булган, рәхмәт инде!

– Ярар, – диде Рәшит. Үзе яннарында уралган Рузиләгә карап алды.

«Ояла бит әле ул», – дип уйлады Рәйсә, аның уңайсызлануын сизеп.



– Бәлеш тыктым, тагын берәр сәгатьләп торасы бар. Иртә кайттың бүген...

– Икенче рейска җибәрмәделәр. Алайса мин тактага тотынам, Рузиләгә чәй биреп чыгарырсың әле, – дип, Рәшит мунча алдындагы станокка таба китте.

Башлаган эш беткән эш – верандасының эше азаеп килә инде. Эштән соң, кайнише белән икәү маташтылар. Кирәк-ярагын алдан, ике-өч ел буе җыя килгән иде, җайлы булды. Идәнен җәясе дә, тәрәзә рамнарын ясыйсы бар.

Бер озынлыкта киселгән калын авыр биш-алты тактаны берәм-берәм станок янына ташыды, берсен станокның шома өстәленә салып, моторны кабызды. Түгәрәк пычкының очлы тешләре колак яргыч ачы тавыш белән агачка батып керде, аның кайрылы, ботаклы читен тип-тигез итеп ярып үтте. Читләрен алып чыккач, такталарны шомартырга тотынды. Чәчләренә, ачык беләкләренә, киеменә пычкы оны очты, танавын тәмле агач исе кытыклады. Чәй чыгарган Рәйсә соңгы ике тактаны шомартып бетерергә ярдәм итте. Станокны сүндереп торып, идәнлекләрне әзер такталар өеменә кушып өйделәр.

– Тагын дүрт-бишне шомартсам, җитәр дә, – дип, Рәшит чәй йотты. – Кайниш кайтса, кагуы бер көнлек эш инде аның...

– Син әллә экстрасенсмы? – диде хатыны.

– Нигә?!

– Бәй шул күлмәкне теге атнада районда күреп, күзем төшеп кайтканыем бит. Шулчаклы аласым килгәние, акча жәлләдем. Биш йөз сум шуткы түгел, мәшәкатьле елыбыз.

– Биш йөз сум дисеңме? – дип кабатлап сорады ире.

– Алты йөзне сорап торадырые, алсаң, биш йөзгә бирәм диеп әйткәние инде. Рәхмәт, Рәшит, бигрәк зур бүләк алгансың, – дип ихлас елмайды Рәйсә. Ирен «әп» итеп алды да өйгә кереп китте, ә Рәшитнең ике кулы салынып төште, «лып» итеп каен бүкәнгә утырды.

«Мин бит ул күлмәкне мең сумга алдым!» – дип шаккатып уйлады Рәшит. Нәҗип белән сөйләшүләрен һәр сүзенә кадәр хәтерләде. Җитмәсә, Сабантуй көнне эшкә дә ялламакчы иде бит әле! Хәер, аңа Сабан туең ни дә, үзең ни! Ярый инде, алыпсатар да булдың, ди, бергә алып, икегә сатып баедың да, ди, тик нигә аны, Рәшитне шулай алдарга? Классташың, әйтергә яраса, дустың! Юк, Рәшит алай итә алмас иде. Күңел тынычлыгын, намусыңны йөз, мең тәңкәгә алыштырырсыңмы... Классташ бит әле ул, классташ...

Рәшит сикереп дигәндәй торды да бүкәнгә чабып куелган балтаны алды. Әллә кайчаннан бирле кул тими яткан, утынга дип киселгән агачларны ярырга тотынды. Киерелеп, селтәнеп җибәрә, юан түмәрләр чырылдап икегә аерылып оча... Күз алдында һаман саннар биешә үзенең. Мең... «ыһ»... «чырык!» – биш йөз, биш йөз. Гүя дә түмәрләр түгел, меңлекләр йөзлекләргә ярыла!

Үткер балтаның йөзе батып барган кояшның алтын нурларында ялтлап-ялтлап китә. Шәфәкъ алдыннан гына була торган моңсу тынлыкны бозып тавыш яңгырый: чырык-чырык, чырык-чырык...

Ә кояш, аңа нәрсә, ул битараф, ул чиксезлектән чиксезлеккә сәфәреннән мизгелгә дә туктамыйча әйләнә дә әйләнә. Кояш әйләнә, Ай, Йолдызлар, Җир, Чыршыбаш, Котылдык әйләнә... Без дә үз кучәребез тирәсендә әйләнәбез бугай. Кемнәрнеңдер кучәре – акча, кемнекедер – бала, ир, хатын, эш, уку, тамак. Безнең дә туктарга, уйланып: «Кая? Нигә?» – дип торырга вакытыбыз юк, ашыгабыз – алдарга, алданырга, яшәп калырга, кучәрләребез тирәли әйләнеп калырга...



Рәсем: Наталья Васильева

«МИН» КЕШЕЛӘРГӘ ЫШАНАМ»



Гөлзадә САФИУЛЛИНА,
Татарстанның халык артисты, Кырым Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Муса Җәлил премиясе лауреаты.

Бу дөньяда иң авыры – үзеңне табу. Аны яшь чакта, бала чакта уйламыйсың әле. Гомер үтә-үтә нииндидер уңышларга ирешкәннән соң, шушы сорауга килеп чыгасың. Хәер, нәрсәгәдер ирешмәсәң дә... Гомумән, кеше гел тыпырчына, гел нидер эзләнә. Нәрсә эзлибез, кая ашыгабыз, соңгы юлыбыз кайда безнең? Адәм баласы һәрвакыт шулай үзен табарга тырышып яши. Үзен тапмыйча бу дөньядан китүчеләр дә бик күп. Мин, Аллага шөкер, үземне тапкан кеше. Кем буласымны кечкенәдән үк белә идем. «Җырчы булам! Җырчы булмасам да, зур кеше булам», – дия идем үз-үземә.

Җырчы өчен йомшаклык, нечкәлек кирәк, ә инде тормыштагы авырлыкларны җиңеп чыгу өчен барыбер ихтыяр көче, тырышлык сорала. Менә болар барысы да миңа әти-әниемнән күчкән. Әнием бик йомшак холыклы, нечкә күңелле иде. Эчтән генә гел җырлый иде ул. Өйдә, нидер эшләгән вакытта, аш-су тирәсендә кайнашканда... Тавышы шулкадәр моңлы! Ә әти көчле холыклы кеше – әнинең киресе. Әллә ничә төрле гармунда уйный: тальянда, хромкада, Саратский гармунда. Әмма елына бер тапкыр капка төбенә чыгып утырып кына уйный. Сабантуй көнне! Моны бөтен авыл кешесе белә: «Әнә Гомәр өздерә!» – диләр... Әтинең гармунга тотынуы бүген безгә кичке уенга барырга рөхсәт дигәнне дә аңлата. Башка чакта бу хакта авыз да ача алмыйбыз. Дөрес, киноларга кача-поса гына бара идек. И-и, киноны ярата идем инде. Әнигә: «Бир инде биш тиен акча! Бөтен эшне эшлим, клубка гына җибәр», – дип ялына идем. Кайчак бирә, кайчак юк... Билетка акча булмаганда, эскәмия астына кереп качып, шуннан карый идем. Киномеханик ерак туганыбыз Харис абый иде. Киносыз яши алмаганымны үземнән дә яхшырак белә... Ул вакыттагы киноларның ниндилеген хәтерләүчеләр бардыр әле – барысы да сугыш һәм мәхәббәт турында. Чып-чын тормыш турында. Һәммәсе дә ихлас, хыялый... Мәхәббәт дигәннән. Безнең әти фин сугышында да, Бөек Ватан сугышында да катнашкан. Ул озын фронт юллары узып, авылга исән-сау әйләнеп кайткач, 1946 елда мин туганмын. Беренче бала. Чын мәхәббәттән туган бала! Ничә елларга сузылган сагынулардан соң мәхәббәт вулкан булып атылгандыр инде... Әйе, мәхәббәт баласы мин! Шуңа күрә үзем дә бөтен дөньяны, кешеләрне яратам. Ул мәхәббәт, ул ярату чиксез миндә!

Ышануым да зур. Бөтен кешегә дә ышанам. Хәтта хәзер дә, тормыштан йөз түгел, мең кат сабаклар алгач та. Ышанып алданган чакларым бихисап булды. Алдасыннар – кичерәм. Кичерәм дә, алга таба атлап китәм... Булды, байлыкның ни икәнен татыган вакытларым да булды. Шундый мөмкинчелекләр бирде Аллаһы Тәгалә. Шул вакытта да бер кулым белән алдым, икенчесе белән аны башкаларга суздым – сорап килгән берәүне дә кире борып чыгармадым. Бурычлы булып калган кешеләр дә бар. Онытканга түгел, мөмкинлекләре булмаганга. Инде ул чаклардан соң әллә никадәр вакыт узгач та, килеп әйтәләр: «Мин сезгә бурычлы, кайтарырмын», – диләр. «Ходай насыйп итсә кайтарырсың», – дим. Рәнҗемим дә, көтмим дә. Әйе, ул елларда бик күп кешеләргә ярдәм итәргә туры килде. Тик моны бит мин эшләмәдем, минем кулым белән аларга Аллаһы Тәгалә үзе ярдәмен җибәрде. Шундый изге эштә арадашчы булуыма бүгенгәчә бәхетлемен.

Ә үземнең берәү каршына да нидер сорап барганым юк. Минем өчен дөньядагы иң авыр эш бу... Бөтенләй чарасыз калган чакларда да, кешеләрдән түгел, Аллаһы Тәгаләнең үзеннән генә сорыйм. Аның гозеремне ишетмичә, бирмичә калганы юк әле. Дөньяда иң зур таянычым Аллаһы Тәгалә һәм үземнең балаларым. Кызым, өч оныгым...

Бер кешедән берни сорамыйм дидем дә... Соңгы сулышта, мөгаен, су сорармын.

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

Тәртип радиосы

«Тәртип» радиосында баручы «Чакырылган кунак» тапшыруының җырчы Гөлзадә Сафиуллина катнашкан чыгарылышын (2015) тыңлау өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.





«НУР»: КАБАТЛАНМАС ҺӘМ БЕРДӘНБЕР

«Мәхмүт дус!
Без училищега заявка бирдек. Синең урының, язмышың «Нур» театры белән бәйле булырга, аның нигез ташларын салучы кешеләрнең берсе син булырга тиешсең дип уйлыйбыз. Минем дә, коллективның да фикере шундый. Туган илеңдә туган халкыңа хезмәт итә алу – зур бәхет. Бу – матур сүзләр генә түгел. Эш хакы бездә начар булмас. Кайтып урнашу белән семейное общежитие тырыштырырбыз. Киләсе елга 7–8 квартира алырбыз дип өметләнәбез. Үзеңә ияртеп, ким дигәндә 1–2 кызны да димлә. Шушы көннәрдә бик өметле режиссер килергә тиеш. Сорауларың булса, адрес: Уфа, улица Ульяновых, 50, Татар «Нур» театры, телефон 42-64-59. Күп язып тормыйм, син мине аңларсың дип уйлыйм. Күп сәламнәр белән, Мәҗит абыең. 10 декабрь, 1990 ел». Театр шулай башлана...

Алтын бөртекләп җыела

1912 елда Уфада 19 яшьлек Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская оештырган Татар «Нур» театры гражданнар сугышы елларында таркала. Әмма нәкъ 70 елдан студия буларак яңадан эшли башлый. Бу эшне башлап йөрүчеләрнең берсе, соңрак театрның беренче директоры Мәҗит Мөдәрисов Казан театр училищесында укучы студент Мәхмүт Фатыйховка җибәргән кебек, хатны тагын ничә кешегә юллаган булгандыр, билгесез. Хатлар язып, студиядән чын татар театры оештыру өчен бөртекләп профессиональ артистлар җыйган вакытта «Туган илеңдә, туган халкыңа иҗат итү» дигән сүзләр яшь артистларның тормыш девизына әйләнәсен күз алдына китерде микән Мәҗит әфәнде?

Алда хыяллар балкып торса да, бүгенгесе бик авыр – «өметле» дип кенә кем килсен театр студиясенә. «Без артистларны студияләр өчен үстермибез!» – дип, Мәхмүт Фатыйховны да училищедан Уфага түгел, Оренбург теат-







Фотолар: «Нур» театры архивыннан.

рына җибәрәләр. Ләкин өч ай вакыт узуга, күңел түрендә сакланган хат яшь артистны барыбер «Нур»га алып кайта.

Ике ел эшләгәннән соң студиягә «Уфа «Нур» Татар дәүләт театры» статусы бирелүгә ирешәләр. «Нур»га шул вакытта башка театрлардан артистлар да килә башлый: Рәшидә Гандалипова, Резидә Фәхруллина, Рәсимә Гайфуллина, Идрис Кәлимуллин, Альберт Шәйхетдинов тотрыклы эшләрен әлегә бернәрсәсе булмаган театрга алыштыралар. Театр дигән сүзе генә була шул. Бинасы турында сүз дә юк, сәхнәне РТИ (Резина-техник изделияләр оешмасы) мәдәният сараенда арендага алалар, репетицияләр бөтенләй шартлары булмаган җирләрдә үтә.

– Чорма-подваллар да калмады инде, арендага нинди урын таптык, шунда уйнадык. Урамда эскәмиягә утырып репетиция ясаган чаклар да булды хәтта. Шулкадәр энтузиазм белән эшли идек, өмет, ышаныч, хыяллар чигенергә ирек бирмәгәндер. Ярышып эшләдек: барыбызның да сәхнәгә чыгасы, үсәсе килә иде! – дип искә алалар.

Башкортстанда Татар дәүләт театры – мөмкин хәлмени?! Беркем ышанмаган. Көлеп: «Халык театры бит алар, күчмә театр», – дип караучылар да күп булган. Репертуар өстендә бер ел буе эшли «нур»лылар. Дүрт спектакль туплаганнан соң, РТИ мәдәният сараенда беренче сезоннарын ачып җибәрәләр. 800 кешелек тамаша залына билетлар тиз сатылып бетә. Халык агылып килә!


Тотынган эшләрен җитди итеп, җиренә җиткереп башкаралар «Нур»да. Һәр адымнары киләчәктә тарих битләреннән бөртекләп җыелачагын аңламаганнардыр да, бәлки. Моңарчы беркем тарафынан куелмаган әсәрләргә алынып, көчле спектакльләр иҗат итәләр. Фатыйх Сәйфи-Казанлының «Ямьсез тормыш», Мирхәйдәр Фәйзинең «Адашкан күңел» драмалары куела. Бары тик опера театрлары сәхнәсендә генә яңгыраган, башкорт драматургы Хәбибулла Ибраһимовның популяр «Башмагым» комедиясе нигезендә Таҗи Гыйззәт белән Җәүдәт Фәйзи иҗат иткән «Башмагым» музыкаль комедиясенә тотыналар хәтта. Талантлы җырчы артистлар тупланган театр гына җөрьәт итә ала моңа!

Уфа Татар дәүләт театрының уңышлары хакында Казанда да белеп торалар. Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры милләттәшләрен колач җәеп каршы ала. Театрның директоры Шамил Закиров, режиссеры Марсель Сәлимҗанов Казан тамашачысына «Нур»ны күрсәтү теләге белән беренче гастрольләрен оештыруда зур ярдәм итә. Туфан Миңнуллин, Нәҗибә Ихсанова, сабый балаларны җитәкләп йөрткән кебек кайгыртып, һәрьяклап теләктәшлек күрсәтеп йөриләр. «Нур»лыларның «Башмагым» өчен тегелгән сәхнә киемнәрен күреп: «Театр өчен дә мондый костюмнар тегәләрмени?» – дип таң калалар Камал театрында. Артистларны әйләндереп, киемнәрен тоткалап карыйлар хәтта. Һәр юнәлештә сыйфат



Фирзәт ГАБИДУЛЛИН, директор

– «Нур» – бүген тулаем формалашкан, профессиональ яктан өлгергән театр. Башкортстанда эшләүче театрлар арасында үз дәрәҗәле урыныбыз, кабатланмас йөзебез, «почеркыбыз» бар. Бүгенге көнгә нәтиҗә ясап әйткәндә, шөкер, тамашачыны катарсис кичерергә, көчле эмоцияләр шаукымына бирелергә этәрүче спектакльләр иҗат итә алдык. Хәзерге вакытта театр юбилей сезонына әзерлек белән мәшгуль. Яңа сезонны Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» пьесасы белән ачып җибәрәчәкбез. Тарихта беренче тапкыр Мәскәүгә гастрольләр оештырылачак. Гомумән, бу юнәлештә географияне шактый киңәйтергә омтылабыз.



Азат ҖИҺАНШИН, баш режиссер, Башкортстанның халык артисты

– Новаторлык эзләп, яңалык кертәбез дип, Көнбатыш модасына иярү, әллә кая омтылу күзәтелә хәзер театрларда. Ләкин безнең байлыгыбыз – тамырларда. Халкыбызга хас романтизм геннар буенча буыннан-буынга күчеп бара. Театрга килүчеләргә чит ил мәдәниятен «тагарга» тырышсак та, 40 яшенә җитү белән алар күңеле барыбер «Галиябану»ны эзләп киләчәк. Әлбәттә, дөньяви драматургия хакында да онытырга ярамый, андый әсәрләр артистка үсәргә, осталыгын арттырырга булыша. Ләкин хәзерге вакытта мине кеше, шәхес кызыксындыра. Сәхнәдә авырлыкларның чигенә җиткән шәхес психологиясен, аның хис-кичерешләрен күрергә телим.

өчен эшләүче «Нур» костюмнарга беркайчан да акча кызганмый.

Тәүге гастрольләр һәм... Казанда аншлаг! Спектакльләргә билетлар калмый, тамашачылар ябылу тантанасында залны гына түгел, ярты сәхнәне тутырып Уфа артистларын чәчәкләргә күмә. Яшь-яшь театр үзенең кабатланмас йөзен ача, иң таләпчән Казан тамашачысы тарафыннан бәяләнә.

Бар кыенлыкларны җиңә барып, «Нур» үзен танытуын дәвам итә. Ләкин... «Әлеге көндә дә театр коллективы авыр шартларда көн күрә. Аның әле һаман да үз бинасы юк. Шуңа да карамастан, театр коллективы киләчәккә өмет белән яши, эзләнә, иҗат итә», – дип язып чыгалар матбугатта. «Бәлки, бүген...» дигән өмет белән башланган көннәре шулай айлар, елларга сузыла.

Һәм менә, ниһаять! Кинотеатр буларак төзелеп килүче бинаны «Нур»га бирәләр икән, дигән сүзләр ишетелә башлый. Бинаны мөмкин кадәр театрга яраклаштырып, үзгәртеп төзиләр. Кече зал ачылу да коллектив өчен чиксез шатлык алып килә. Туфан Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар» драмасы белән үз йортларында яңа театр тормышын башлап җибәрәләр.

– Кече зал ачылгач, үзебезне чын башкала артистлары итеп тоя башладык. Һәр көн аншлаг белән үтә. Болай да тулы залларга өстәмә урыннар куя идек. Кассаларга чират! Спектакльне уйнап чыгуга, безне кызлар, егетләр көтеп тора, чәчәкләргә күмәләр, – дип искә ала Башкортстанның һәм Татарстанның атказанган артисты Мәхмүт Фатыйхов. Берникадәр вакыттан соң зур залны да ачык дип белдерәләр, сәхнәне Хәбибулла Ибраһимовның «Җизнәкәй» спектакле белән «котлыйлар».

Уңышлар таҗында

Уфаның йөзек кашы булган театр бүген тамашачыны кабатланмас уникаль биләмәләрендә каршы ала. Башкортстанның атказанган рәссамы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Вәкил Шәйхетдинов иҗат иткән «Ләйлә» исемле флоренция мозаикасын кулланып, ярымкыйммәтле ташлар белән бизәлгән дивар – тамашачыларның яраткан урыны. Янәшәсенә басып, фотога төшәләр.
Бу композиция Вәкил Шәйхетдиновның иң уңышлы эшләреннән берсе, юкка гына кызы Ләйләнең исеме белән атамаган ул аны. Флоренция мозаикасы сәнгате белән кызыксынучылар чит илләрдән «Ләйлә»не күрергә дип театрга махсус килә.

Театрда бүген 45 артист эшли. Репертуарда 27 спектакль, ел саен биш яңа постановка өстәлеп тора. Озак еллар сәхнәдән төшми барган, популярлыгын, актуальлеген югалтмаган әсәрләр – театрның горурлыгы. «Монысы – «Авыл эте Акбай», бу – «Гөргери кияүләре», менә «Фатыйма», – дип, спектакльгә хезмәт күрсәтү бүлеге мөдире Зәйтүн Заһидуллин декорацияләр белән таныштыра. – Монысы «атказанган» спектакль инде, «Хатын түгел, Аждаһа». Декорацияләр дә сәхнәгә чыгып тезеләсе көннәрен көтеп торалар сыман». Сәхнә арты – үзе бер тормыш, туктаусыз механизм кебек эшли. «Җизнәкәй» спектакленең быел 15 нче сезонына Башкортстанның атказанган артис-

ты Марат Исхаковны лаеклы ялдан чакыртып, тамашачыга бүләк ясаганнар. Россиянең атказанган, Башкортстанның һәм Татарстанның халык артисты, театрның бренды – Сәвия Сираевага 87 яшь. «Уфаның почетлы гражданины» исеменә лаек булган артистка әле бүгенгәчә спектакльләрдә уйный. Ул сәхнәдә күренүгә үк халык дәррәү кул чаба башлый.

Ленария Хаҗиева җитәкчелегендә эшләп килүче балалар студиясе – театрның аерым горурлыгы. Анда җитмештән артык бала шөгыльләнә. Санкт-Петербургта Европа илләре арасында узган конкурста «Золотой ключик» балалар спектакле белән онлайн катнашып, беренче урынга лаек булганнар. Театр артисты Марат Хәсәнов режиссерлыгында куелган «Питер Пэн» спектаклендә исә студиядә шөгыльләнүче барлык нәни артистлар, шул исәптән, мөмкинлекләре чикләнгән балалар да катнаша.

– Үз артистларыбыз арасыннан режиссерлар үсүе – бик сөенечле күренеш. Бу яктан да театрыбызның перспективалары зур. Эшнең асылын белүче, барлык нечкәлекләрен аңлап иҗат итүче яшь буын өметләндерә безне, – ди театрның директоры Фирзәт Габидуллин. – Быел З. Исмәгыйлев исемендәге Уфа дәүләт сәнгать институтында «Нур» театры өчен махсус курс җыела. Яшь артистлар укуның теоретик өлешен институтта, ә гамәли яктан белемнәрен безнең сәхнәдә сынап караячак. Баш режиссерыбыз Азат Җиһаншин курсның сәнгать җитәкчесе булачак.

29 нчы сезонны «Фатыйма» спектакле белән тәмамлаганнар. Тамашачыны магниттай театрга тартырлык постановка туган. Хатын-кыз сабырлыгына, көченә, сынмас рухына мәдхия булып яңгыраган спектакль матур язмышлы булырга охшаган.

«Нур» театры юбилей сезонына аяк баса. 30 ел дәвамында төрле авырлыклар да, зур уңышлар да кичергән ул. Фестиваль лаврлары алган, театр тәнкыйтьчеләре тарафыннан югары бәяләнгән, тамашачы мәхәббәтен яулаган, артистларны сәнгатьнең яңа үрләренә күтәргән иҗат җимешләре бихисап. «30 ел эчендә иң көчле сезон кайсы иде?» – дип кызыксынам. «Алда әле!» – дигән җавап ишетәм. Әйе, «Нур» театрының иҗади мөмкинлекләре зур. Башкортстанның иң җырлый торган театры, диләр алар турында. Республикада узучы концертларда, юбилейларда чыгыш ясарга еш чакыралар артистларны. Халыкара «Татар кызы» бәйгесенә милләт кызларын әзерләү «цехы» да әле ул «Нур» театры. Профессиональ артистлар ярдәмендә сәнгати яктан баеп, әдәби сөйләмнәрен үстереп, тавышларын ачып, бәйгегә юллама алып чыга кызлар.

Чал тарихын гасыр битләренә салып, дәрманы белән яшьлек утында дөрләп януы театр ул «Нур». Кабатланмас. Бердәнбер. Диварлары бүген дә милләтебезнең горур кызы – данлыклы Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская рухын саклый кебек. Аның чалымнары дан казанган артистлар язмышында, тәүге тапкыр театр бусагасын атлап кергән яшь буын күңелендә, тугры тамашачы йөрәгендә, буыннан-буынга күчеп килүче мирасга дәвам итә. Туган илендә, туган халкына хезмәт итүе белән бәхетле «Нур» театры. Юк, бу – матур сүзләр генә түгел!

Алсу ШАКИРОВА



Резида ФӘХРУЛЛИНА, Башкортстанның һәм Татарстанның халык артисты

– 1991 ел иде ул, күңел төшебрәк торган вакытлар, башка һөнәр сайлыйм дип йөргән көннәрем. Укытучыларым очрап, «Нур» театры төзеләчәген хәбәр иттеләр. Башкорт академия театрыннан китеп, әле каккан кадагы да булмаган яңа театрга килдем. Берникадәр яшьлек максимализмы булгандыр бәлки... Театрның киләчәге, куелачак спектакльләр өметләндерде, илһам бирде. Һич үкенмим! Һәр салынган кирпечен күзәтеп, күз алдында үстердек без «Нур»ны. Бик күп рольләр башкардым, арасында иҗатымны яңа баскычка күтәргәннәре, яңа үрләр ачканнары шактый. Иҗатыма гашыйк булып, мөкиббән киткән тамашачымны да шушында таптым. Җитәкчеләр хезмәтебезне бәяли белә. Артист өчен бу бик зур әйбер.



Чулпан РАЯНОВА, артистка

– Бу сезон Фатыйма образы аша үзенә күрә бер үсеш баскычы булды минем өчен. Коллегаларым, театрыбызның күренекле артисткалары: «Чулпан, мондый рольләр гомергә бер тапкыр гына эләгә», – диделәр. Беренчесе генә булсын иде әле, дип телим. Премьерага килгән кунакларыбыз: депутатлар, җитәкчеләр, блогерлар, театр тәнкыйтьчеләре хезмәтемне югары бәяләде, театр сәхнәсендә «яңа йөз» дип атады. Бу сүзләр һәр иҗат кешесен канатландыра, әлбәттә. Минем өчен дә алар бәһасез. Труппабыз зур үсеш юлында бүген, коллективка бик талантлы, акыллы яшьләр килә. Театр – алар белән бер дулкында. Әйе, без чынлап та, күтәрелеш чоры кичерәбез хәзер!

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Мәскәү каналларының берсендә йөрәгемә тиярлек тема күтәрделәр. Тапшыруга килгән рус хатыны киңәш сорый: «Минем ирем татар. Кечкенә балабыз русча начар белә. Иремнең әнисе балам белән гел татарча сөйләшә», – ди. Беләсезме, алып баручы нинди киңәш бирде? «Балагыз русча гына сөйләшсен. Бу хакта логопед белән киңәшләшегез, ул ярдәм итәр», – диде. Телевидение аша башка милләтләрнең дәрәҗәсен төшерү, кимсетү була түгелме соң бу?

Катнаш никахлар элек тә булган, хәзер дә бар. 1917 елгы инкыйлабка кадәр Аллаһка ышанган татар кешесе мөселман кавеменнән генә үзенә пар сайлаган. Һәр милләтнең үз гореф-гадәтләре бит. Балалар шуны сеңдереп, олыларны хөрмәт итеп, эш сөючән, ата-анага итагатьле булып үскәннәр. Шуңа күрә безнең милләттә гаилә таркалу очраклары булмаган да диярлек.

Кызганыч, хәзер катнаш гаиләләрдә татар баласы үсми диярлек. Башкорт, үзбәк, казакъ, кыргызлар белән гаилә корганда да каршы як милләт өстенрәк була хәтта. Татарларда милли горурлык хисе түбән дәрәҗәдә. Бу темага карата рәсми мәгълүмат белән дә танышып чыктым. Татар кызларыбызның – 45 проценты, егетләребезнең 43 проценты катнаш гаилә төзеп, ятларга бала үстерә икән.

«Ливадия» шифаханәсендә ял иткәндә бер профессор башыннан кичкәннәрен сөйләп утырды. Юбилее белән котларга дип, Түбән Новгород шәһәреннән абыйсы кайткан. Ул да профессор икән. Олыгаеп килгән көнендә абыйсы язмышыннан зарланган: «Яшь чагымда рус кызына өйләнеп бик зур хата ясадым. Хәзер улым да, кызым да башка милләт кешеләре – руслар. Нәсел җебе өзелде, милләтемә гафу итмәслек хата ясадым», – дигән.

Әңгәмәдәшемнең тагын бер абыйсы да (ул да профессор) катнаш никах нәтиҗәсендә гыйбрәтле язмышка дучар булган. Бервакыт Воронеж шәһәреннән кунакка кайткач, милли җанлы абыйсы, татар җырлары тыңларга дип, бик күп кассеталар сатып алган. Воронежга алып китеп, шунда тыңларга булган исәбе. Китәр вакытлары җиткәч, күрше бүлмәдә хатыны белән кызы чемодан тутырганда сөйләшкәннәре ишетелгән. «Калдырыйк бу кассеталарны», – ди икән рус булган хатыны. «Әни, туганнарыннан яхшы түгел, алыйк та, кайткач ташларбыз», – дип пышылдаган кызы. Абыйсына карата шундый мөнәсәбәтне күреп, бик тә кызганган аны танышым.

Кайвакыт катнаш гаилә корган балалары хакында бик канәгать булып сөйләүчеләрне ишетәм. Имеш, бик әйбәт яшиләр, дини бәйрәмнәрне дә бергә билгеләп үтәләр.

Бу сүзләр белән һич кенә дә килешәсе килми. Дин ул тышкы атрибут кына түгел. Канга сеңгән, җанга үтеп кергән яшәү рәвеше. Кеше олыгайгач булса да, үз асылына кайта, шул вакытта гаиләдә каршылыклар да туа. Гаиләдәге тотрыклылык татар кешесенең түзем, сабыр булуы нәтиҗәсендә генә саклана. Тату яшибез, дигәннәре дә, ихластан сөйләшкән вакытта үзләрен гаиләдә санга сукмаулары, әледән-әле мыскыл сүзләре ишетеп торулары хакында әйтә...

Шушы язганнарны укып, татар кызларыбыз, татар егетләребез гаилә корыр алдыннан тирәннән уйланып, әлеге җитди мәсьәләгә битараф булмасыннар иде. Милләтебезнең сафлыгын сакларга тырышсыннар иде.

Сәгъдулла ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ.
Казан шәһәре.

Нәсел чыганагы, гаилә бизәге – әбиләрдә. Без ул яктан бик бәхетле булдык. Уен-көлкеле, акыллы әбиле булып үстек.

Саимә әбиебез – гаиләбезнең чын бизәге. Бер татар хатынында никадәр осталык, булганлык

Фото: Анна Арахамия



тупланган, дип сокланабыз аңа карап.

54 яшендә ялгыз калып, тормышны берүзе алып барырга туры килә аңа. Бервакытта да төшенкелеккә бирелми ул, һәрвакыт шаяртып, уен-көлке белән сөйләшә. Аның сүзләрен канатлы сүзләр итеп кулланабыз үзебез дә. «Йорттан чыксаң – бабай эше, йортка керсәң – әби эше», «Эшләгән эшең үзеңә ошасын», «Туганлык җепләрен өзәргә ярамый», – дип әйтергә ярата әби.

Җәйге каникулларга җиде онык җыелып кайта идек. Әбиебез безнең белән тауга менә, урманнарга алып барып кура җиләге, җир җиләге җыйдыра. Бакчада эшләп, печән чабып, чөгендер басуында чүп утап үскәннәребез матур хатирә булып күңелгә кереп калган. Безне эш сөеп үсәргә өйрәтте, мәрхәмәтле булырга, тырышып укырга куша иде.

Әбинең үзендә абзар тулы малтуар: сыер, сарыклар, үгез, кәҗә, казлар, үрдәкләр – барысы да бар. Балаларга, оныкларга кызык булсын, эш белеп үссеннәр дип, ат та асрап карады хәтта. Менә шушы чуплэп бетермәслек мәшәкать өстенә кул эшләренә дә оста ул. Тегү машинасында тегә, сарык йоныннан юрганнар, матраслар сыра, мамык мендәрләр тутыра, оекбашлар бәйләп, һәр баласына, һәр оныгына бүләк итә. Пешеренергә дә оста. Сыер, кәҗә сөтеннән каймак, катык, корт, май ясап, барыбызны сыйлый. Һәрвакыт өстәле әзер, мунчасы яккан, тәрәзә төбе саен гөлләр үсә. Балаларының туган көне җитсә, зур подноска бавырсак пешереп куя, бүләккә каз яки үрдәк җибәрә.

Шулай бертуктаусыз эшләп тә оныкларга тәрбия бирергә өлгерә ул. Әбинең теләкләре дә мәгънәле, акыллы хатын-кыз сүзләре. Аның янында күңелле, рәхәт безгә. Без кайтып кергәндә бию көйләре куеп та каршылый кайчак. Аның белән утырып, тәмләп чәй эчүгә, сөйләшеп утыруга берни җитми.

Мулдан исәнлек-саулык насыйп итсен иде Ходай Саимә әбигә. Әби булганда без көчле, бердәм, күңелле яшибез.

Зөлфия ШӘЙМӘРДАНОВА.
Чаллы шәһәре.

Журналның 2 нче санында чыккан «Хатлар яздым утырып...» язмасы балачак елларына алып кайтты. Хатирәләрне барлап, хат язарга утырдым. Элек хатларны бик тәфсилләп, тәмләп яза идек. Һәрбер хат үзенчәлекле, кабатланмас була торган иде. Җырлар, шигырьләр белән бизәп, күңел җылысын җибәрә идек адресатка.

Ерак туганыбыз Маһирәттәй урамның теге башында ялгызы гына яши иде (Бондюг районы Песәй авылы). Иптәш булсыннар дип, еш кына сеңлем белән икебезне әни аның янына кунарга җибәрә. Махирәттәйнең улы Рифкать абый Армия сафларында хезмәт итә иде. Бөтен авыл хәлләрен җыеп, Махирәттәй үзе сөйләп тора, бездән улына хат яздыра. Шул хатларның кайберсе әле дә истә саклана.

«Ерактан үк күренеп тора
Агыйделнең ак ташы.
Чын йөрәктән кайнап чыккан
Сагынычлы хат башы.

Бисмилләһир-рахмәәнир-рахиим. Улым, синең хатыңны алып укыдык, бик зур рәхмәт! Минем өчен тыныч бул, әйбәт хезмәт итәргә тырыш, өстеңә җылырак киенеп йөр. Рәсимә апаң кебек (урыны оҗмахта булсын) туңа күрмә инде. Минем белән кунарга Илгизәр белән Илсөяр килә. Алар белән догалар укыйбыз, сөйләшеп утырабыз, чәйләр эчәбез. Кайсы көнне кич утырырга дип җизниләргә менәм. Аларда күңелле: өйләре җылы, мич артында аралыкта бозау, өй тутырып сарык бәрәне чабып йөри, караватастында бәбкә чыгарырга казлары утыра. Авыл хәлләрен сөйләшәбез. Кнәзнекеләрнең сыеры ике бозау китергән, Габдрахман абзыйны район хастаханәсенә салганнар, Шияпның малае армиядән кайткан... Таһир абый малае Можгадан кыз алып кайткан, никахны Шәйхеләхмәт абый укыган. Бик матур туй уздырганнар. Быел ашлыклар бик күп булды. Хәзер тракторчылар район үзәгендә тракторларын ремонтлыйлар, кыр эшләренә әзерләнәләр.

Яратам мин елның яз айларын,
Хәтта сәер җепшек буранын.
Ул буранны игенченең:
«Быел иген уңар!» – диеп юравын.

Әмин! Әмин! Авылда тыныч, хәвеф-хәтәр юк бу араларда. Менә синнән хат көтәм, улым. Шигырь юллары белән язылганнарын ятлап сөйләп йөрим.

Әнкәй, саумы... Минем кайтуымны
Көтәсеңдер һәр көн сагынып.
Язлар җитсен инде,
җирләр кипсен әйдә,
Кайтырмын мин сине сагынып!


Аллаһы боерса, кайтуыңа күп калмый инде, сабыр бул. Асия дә сине көтә.

Исәнлектә күрешергә язсын, сине сагынып көтәбез. Озакламый бәрәңге утыртырбыз. Боерган булса, туганнар булышыр әле. Менә, язасы сүзләр шушы иде. Иптәш егетләреңә миннән сәлам әйтерсең. Аллаһы Тәгаләм сезне тазалыктан, тәүфыйктан аермасын! Хатлар языгыз, көннәр аяз булсын. Кояш җылыта башлады инде. Күп сәламнәр белән, әниең. Март, 1963 ел.»

Илгизәр ТИМЕРГАЛИЕВА.
Менделеевск.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан,
Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru





Әти-әнисе, нәсел-нәсәбе булганнар гына җирдә нык басып яши, чөнки таяныр кешеләре бар. «Тамырлары нык бит аның», – дип, сокланып та, көнләшеп тә әйтәләр андыйлар турында. Гаилә кыйммәтләре югалып барган заманда, нәселнең никадәр зур әһәмияткә ия булуы турында, гомеренә бер тапкыр да «әти» дип эндәшә алмаган Татарстанның халык артисты, Россиянең атказанган артисты, Г. Кариев исемендәге Казан яшь тамашачы театры актеры Нуриәхмәт САФИН белән ачыктан-ачык сөйләшәбез.

«ЯРАТУДАН ТУГАН БАЛА ТҮГЕЛ МИН...»

Әнинең ире Бөек Ватан сугышында хәбәрсез югала. Килен булып төшкән Алексеевский районы Кыр Шонталасы авылында әни бер кызы белән ялгызы гына кала. Биш бала тапкан була ул, әмма ул сабыйлар озак яшәмәгән. Мин туганда апага 12 яшь булган. Үземне белгәннән бирле, аның әнигә төрттереп, Вәлиәхмәт исеме белән бәйләп, гел нинди дә булса берәр сүз әйтүен ишетеп үстем. Әмма безнең өйдә бу хакта беркайчан да утырып сөйләшү булмады. Ир-атсыз гаилә – кечкенә генә бер кимчелеге булган гаилә. Шуңа күрә дә өстенә килгән бөтен казаны, күңелеңне ачып сөйләшү булмаган инде ул бездә. Апа әнинең ирсез бала табуын кичерә алмаган, күрәсең. Миңа да читләтеп булса да эләгә иде. Югыйсә мин гаеплеме? Әллә әни гаеплеме? Алданган ул. Меңләгән бәхетсез хатыннарның берсе. Сугыш вакытында көчсез хатыннарны ирләр файдаланып калган инде шулай. Апаның әледән-әле җанга тигән сүзләрен ишеткәнгәдер: «Мин начар кеше булып туганмын, ахры. Берүзем генә шундый», – дип кимсенә идем. Әмма үсә төшкәч аңладым: авылда миндәйләр күп икән. Бер мин генә җилдән тумаган. Ә ул сүзне күп ишеттем. Урамда уйнап йөргәндә дә байтак әйттеләр. Чит кешенекен колак аша үткәреп җибәрәсең әле ул, ә апаныкы нигәдер җанга тия иде. Алай дисәң, ул мине бик яратты. Сөннәткә утыртучы да апа булган. Ул вакытта миңа яшь тә тулмаган, ә әни авырып урын өстендә яткан. Апа авылга килгән «бабачы»ны өйгә алып кереп, мине сөннәткә утырттырып, бабайны бәхилләтеп чыгарып җибәргән. Иртә олыгайган инде ул минем. Моңа да шул әтисезлек гаепле булгандыр. Бу да – сугыш фаҗигасе! Әмма апа белән бер-беребез өчен тау булдык. Әле дә хәтерлим, иптәш малаем Идрискә әтисе каешлы көрән форма алып кайткан иде. Аңа карап: «Әтием булса, мин дә шундый форма кигән булыр идем», – дип уйлаганым истә. Кидем мин ул форманы. Апам алып бирде. Берсендә «уньчечне хезмәт хакы» биргәч, миңа «парочка костюм» алган. «Бик матур ситсыга күзем төшкән иде. Үземә алыйм микән дип карап тордым да, кире борылып киттем», – дип сөйләде. Мин алтынчымы, җиденчеме сыйныфта укыйм бу вакыт. Үзенә алмый калуы бәгъремә тиде. Шул ситсыны апага алып кайтыр өчен гомеремдә бармаган, бездән 25 чакрым ераклыкта булган Чистайга чыгып киттем. Алып кайттым. Аның акчасына, билгеле. Бик нәфис күлмәклек иде ул.

Урамда ишеткән җәберләүләрнең һәммәсен йотып кына бардым. Кайтып әнидән нидер сорашу, әтине таптыру кебек әйберләр бөтенләй булмады. Бу хакта сөйләшергә кирәкмәгәнен туганда ук аңлап туганмындыр. Әмма әти тиешле кешенең кем икәнен белеп үстем. «Менә бу синең әтиең», – дип төртеп күрсәтүче булмаса да. Аны әйтергә дә кирәкми. Йөрәк үзе сизә икән ул. Җитмәсә, өйдә Вәлиәхмәт дигән исем апа авызыннан еш булмаса да, барыбер ишетелә иде. Ишетмәмешкә салышсаң да, барысы да йөрәктә кала бит. Авыл советы рәисе иде ул, Алла урынына йөри торган кеше. Аның өчен чикләр дә, каршылыклар да булмагандыр инде. Бер авылда яшәсәк тә, ул кеше минем өчен юк иде. Аның да туктатып эндәшкәне булмады. Хәер, бер тапкыр эндәште шулай да... Берсендә көтү каршыларга барам. Авыл советы элек мулла өе булган таш йортта иде, күрәм – киң болдырына чыгып басып карап тора. Миңа шул вакыт: «Малай, кил әле монда», – диде. Димәк, үзенең баласы икәнемне белгән ул. Кая янына бару, борылдым да кирегә чаптым. Артымнан тузаннар күтәрелеп калды. Аннан курку түгел, аны кабул итә алмау иде.

Алар өендә минем турында сүз булгандырмы, белмим. Әмма кечкенә чакта, әле укырга да кермәгән идем, аның өч кызы: «Әти безнеке, әти безнеке», – дип, яңа төзелә башлаган клуб буенда кыйнадылар үземне. Бер сүз эндәшмәдем. «Мин бит сездән әти сорамыйм! Миңа кирәкми ул», – дип уйлаганым гына исемдә. Бу – балачакта. Аннан бер кызы белән бер сыйныфта укыдык, дус идек. Икенче бер кызы апа янына безгә килеп йөрде. Хатыны Әминә апа кибеттә сатучы иде. Ул чакта бер шешә тапсак та, тапшырырга кибеткә йөгерә идек. Әминә апа шешәне алып калып, прәннек биреп чыгара иде. Бервакытта да миңа сүз тидергәне булмады. Ире бер минем әни янына гына бармаганын белеп яшәгәндер инде ул. Бик күп хатыннар башына җитүе сер түгел иде бит. Авылда миңа охшаган тагын бер малай бар иде. Аныкы, дип, тәгаен әйтүче булмады булуын. Үзем күңелемнән генә: «Бу минем энекәш, ахрысы», – дип йөрдем.

Әти тиешле ул кеше белән гомерем буена бер кәлимә сүз алышканым булмады. Тартылу да юк иде. Сөйләшәсем дә килмәде. Хәтта: «Исәнмесез», – дип тә әйтмәдем. Яныннан башымны иеп узып кына китә идем. Каникулга кайткач, кырга эшкә чыктым берсендә. Тракторга җигелгән лобогрейка борчак чаба, без сәнәк белән җыеп торабыз. Аның белән рәттән торып

Фото: Рамис Нәҗмиев

50 яшькә җиткәч кенә әти тиешле кешенең исемен паспортка яздырттым.



■ Нуриәхмәт Сафин әнисе Гыйззәтбану белән.

эшләдек. Әбәткә туктап, ашарга утырдык. Авыл мужиклары бит инде – безгә төрттерә башладылар. Шунда ул: «Ярарыгыз инде, егетләр, җитәрегез», – диде. Минем өчен юк исәбендә булса да, ул уйламый гына йөрмәгәндер, күрәсең. Бездән алты гына чакрым ераклыкта булган Чистай районы Яуширмә авылында исерек килеш: «Минем малай артист!» – дип сөйләнеп йөргәнен җиткерделәр. Соңыннан алар Пермьгә күченеп киттеләр.

Туу турындагы таныклыгымда атамның исеме юк. Үзе авыл советы башлыгы булгач, яздыртмагандыр, күрәсең. Сызык тора иде... Исеме язылса, әни бирәр нәрсә таләп итәр дип курыктымы икән? Исемен генә түгел, ул вакытта бала тапкан хатыннарга тиешле ярдәмне дә бирдертмәгән. Әллә биш тәңкә акчамы, биш метр ситсымы бирә торган булганнар. Документларда: «Сафина Гыйззәтбануга ирсез бала үстергән өчен ярдәм бирелгән», – дип язылган, әмма әни сөйләүләре буенча, беләм – бернинди ярдәм булмаган. Тиешле ярдәмне ала алмаганга әни кимсенгәндерме, белмим, ә менә мин атамның исеме дә булмаганга аз еламадым. Совет заманы бит. Башта октябрятка алдылар, аннан – пионерга. Ярый ул хакта сорамадылар. Комсомолга керергә дип районга бардык. Райкомда атамның исеме булмау белән һич килешергә теләмәделәр. «Как нет?! Человек без отца не бывает» – дип, җаныма тиделәр комиссиядә утырган руслар. «Нет у меня отчества», – дип, чын мәгънәсендә күз яшьләрем белән еладым. Училищега кергәндә андый сорау биреп аптыратмадылар. Студент билетыма «Сафин Нуриәхмәт Вәлиәхмәтович» дип үзем яздырдым. Училище, институт дипломымда атамның исеме бар, ә хәрби билет һәм паспортта сызык кына тора. 50 яшькә җиткәч кенә аның исемен паспортка яздырттым. Анысын да вакытыннан алда пенсиягә чыкканда проблемалар булмасын дип кенә тырыштым.

Ә нигә авылдан китәргә булдыммы? Хәерчелектән качасым килде. Аннан соң авылда ялгызың яшәп булмый да! Шуны аңлагач, читкә чыгып китәргә хәл иттем дә. Әни Юеш Көрнәледән иде. Аны кияүгә биргәннәр дә, туганнары барысы да Мәскәү өлкәсенә күченгәннәр. Шуннан әбиләрем кунакка кайтып йөри иде. Әни мине тапканга каһәрләделәр микән, беренче иренең туганнары безне якын итмәде. Апаны да якын итмәделәр. Булышырлык кешеләребез булмагач, тормышның бар авырлыгы әни белән апа җилкәсендә иде. Хәерчелек апаны 12 яшьтән плугарь итте. Колхозда ирләр эше эшләде. Аннан гомере буе фермада сыер сауды. Әни көнлекче булып, кеше идәнен юып, базыннан бәрәңгесен чыгарышып йөрде. Эш көне өчен колхозда таяк кына куялар, ә болай көнлек ашау, ипи кайта! Ипи дигәннән. Ул вакытта колхоз эшчеләренә ипи пешереп ашата иде. Апа үз өлешен миңа алып кайта. Ул колхоз ипие шуның кадәр тәмле була торган иде. Тәмен әле дә оныта алмыйм... Шул хәерчелегебез аркасында апа бәхетле дә була алмады, мәрхүмкәем. Каршыбызда гына яшәгән Муса дигән егет белән бик яратыштылар. Ул армиягә киткәндә, апаның чиккән кульяулыгын тиз генә барып учына төрткәнемне онытасым юк. Өч ел буе апа аны армиядән көтеп алды, бирнәләр чикте, әмма әти-әнисе хәерче дип апаны алдыртмады. Муса абый башка кызга өйләнде. Капкаларыннан хатыны белән бергә чыгып ашка-мазар киткәнен, йә мунчадан кайтканнарын апа тәрәзәдән качып карап кала, аннан үкереп-үкереп елый иде. Мусасы да гел капка төбенә чыгып утырып, безнең якка карап тәмәке тартты. Төнлә дә тәмәке уты гел күренде. Апа утызы тулгач кына кияүгә чыкты. Җизни начар кеше түгел иде, әмма апа ярата алмады аны. Балалары да булмады. Тормышларының мәгънәсе юк иде. Иза чигеп гомер итте апа. Бу да шул сугыш фаҗигасе. Әтисе исән-сау әйләнеп кайтса, апаның тормышы бөтенләй башкача булган булыр иде. Хәерчелек ачысы миңа да кагылды. Ул заманда кызлар: «Хәерче, атасы юк», – дип борын чөйделәр.

Минем өчен авыл тормышы чит иде. Авыл кешесе зур эшләрен туган-тумачалары белән бергә башкара. Бергә бәрәңгесен утырта, бергә утынын тәяп алып кайта. Ә без өч бөртек. Уфалла арбасы белән урманнан корыган чыбык-чабык, кышлыкка печән ташыйбыз. Кыш өй җылытырга тирестән кирпеч сугабыз. Шул чакта ук авылда калсам, таяныр кеше булмаячак дип уйлый идем. Нинди генә эшкә тотынсаң да, туганың килеп кушылса, күңелләр күтәрелеп китә бит ул. Авылны яратмавымның бер сәбәбе шулдыр – бездә күмәкләшеп эшләү булмады. Ә авылда туганнарсыз яшәп булмый. Нәсел кешегә җирдә нык басып торырга ярдәм итә. Нәселле кеше – көчле кеше. «Энекәш йә абый, ярдәм кирәк», – дип барсаң, юньле тәрбия алган

туган карындашын авырлыкта ташламый инде ул. Кан туганың соңгысын да бирә. Үзеңне кеше итеп тояр өчен тамырлар кирәк!

Йорт эшләренә хирыслыгым юк иде, гел мәктәптә булдым. Куян карап, «Артек» пионер лагерена ял итәргә бардым хәтта. Артист булып китүемә дә укытучылар коллективына рәхмәтлемен. Мәктәптә узган бар чарада катнаштым. Сәхнәдә биергә кирәк, күлмәгем юк. Шахтада эшләп кайткан берәүләрдән әни гел күлмәк алып тора иде. Берничә тапкыр шулай алып торгач: «Бану апа, сатып ал инде бу күлмәкне, һаман сорыйсың да сорыйсың», – дигәннәр. Әни каяндыр акча табып, 15 тәңкәгә сатып алды аны. Ул күлмәкне киеп күп биедем мәктәптә, училищега барып, шуның белән имтихан да тапшырдым. Әле беренче курста да кидем. Әни алган, миннән артист ясаган ул күлмәкне һаман да саклыйм.

Әнинең миңа сукканын белмим. Аның итәгенә ятып йоклаганым хәтеремдә. Ул эшкә чыгып киткәч, салкын тәрәзә төбендә, тыным белән пыялага каткан бозны эретеп: «Әни кайт, әни кайт», – дип утыруым хәтеремдә. Әнисез калудан бик нык курка идем. Әнинең үлүеннән куркып яшәдем. Ул үлгәнче аның үлмәвен теләдем. Гомерендә аның миңа бер авыр сүз әйткәне булмады. Казанга театр училищесына укырга киткәндә генә: «Берүзем калам бит!» – диде. Ул төнне уянып китсәм, әни мышык-мышык елый. (Нуриәхмәт абый үзе дә елый – *Ч. Г.*)

Өйләнгәч әнине Казанга алып килдем. Әле үз почмагыбыз да юк иде. Өч бүлмәле фатирда берничә гаилә торабыз. Бер бүлмәдә без яшибез. Бала туарга тора. Күрше бүлмәдә кызлар яши. Ничек кирәк шулай йокладык ул көнне. Икенче көнне әни кызлар бүлмәсендәге буш караватка чыгып ятты. Аннан ул фатир үзебезгә генә калды. Утыз елдан артык янымда яшәде әнием. Яшьлегендә күрмәгән рәхәтне картлыгында күрсәтергә тырыштым. Җимешкә күмдем мин аны, ниндиен генә алып кайтмый идем: сарысы кирәкме, карасымы, әфлисунмы, лимонмы... Барысын да алдым. Барыбер хөрмәтләп бетереп булмады кебек.

Әнигә ялгыш та үпкәм юк. Ул кешене яраткандыр дип уйламыйм. Озакка сузылган мөнәсәбәтләр дә булмагандыр. Яратудан туган бала түгелмендер мин. Әмма әни – мине, мин әнине бик яраттык. Апаның төрткеле сүзләрен ишеткәндә: «Бәлки, үз бәхетемә тапканмындыр. Бәлки, караучым булыр», – дия иде.

Аягында булганда гел театрларга йөрттем әнине. Актер булуым белән горурлана иде. Әле авылда яшәгәндә дә гастрольләргә районга кайткач, апалар клубка алып килә иде аны. Каршы алып, икенче рәткә утыртам, җилкәсенә шәлен салам да, уйнарга сәхнәгә менеп китәм. Мин уйнаганда әни әзрәк кенә карап утыра да, артына борыла, тагын бераз карый да, кабат артына борыла. Янәсе, күрәсезме, минем Нурины! Горурлана иде ул минем белән.

Әни 91 яшенә җитеп үлде. Соңгы елларын урын өстендә ятты. Икебез бер бүлмәдә йокладык. Төннәрен торып ярдәм итәр өчен, шулай үзем кучтем: караватыбыз кара-каршы иде, бер-беребезгә карашып яттык. Барысын да хатын өстенә өеп булмый бит: гастрольләрдән кайткан чагымда үзем ашаттым да, юындырдым да.

Мин Белоруссиядән гастрольләрдән кайтуга җан бирде ул. Рәмзия: «Әни сине көтте», – диде. Ул төнне әни борчыла башлагач, бабай өйрәткәнчә, авызына өч тапкыр су тамыздым. Җан биргәндә җиңел булсын өчен кешене йә кочакларга, йә кулын тотарга кирәк икән. Әнине кочагыма алдым – минем кочакта җан бирде... Еладым. Бик нык еладым... Ходай Тәгаләмә рәхмәтлемен һәм мәңге бурычлымын: әнинең соңгы сулыш алганын ишетергә мөмкинлек бирде ул миңа! Әнине Осиново зиратында җирләдек. Ләхеткә салганда: «Нури, әйдә, үзең төш», – диделәр. Төштем. Әнинең башын борып, ләхетне такта белән капларга куштылар. Өч такта... Өч такта куярга кирәк иде анда... Бер такта... Әкрен генә куям... Икенче такта... Шул вакыт: «Нури, син монда калырга тиеш», – дисәләр, шунда калырга риза идем. Бәлки, шул сүзләрне көтеп тә бик әкрен генә куйганмындыр ул такталарны. Күмелеп калырга мин риза идем... (Нуриәхмәт абый ничек кенә еламаска тырышса да, күз яшьләре ага. Ул сөйләүдән туктап, кульяулыгы белән аккан яшьләрен сөртә. – *Ч. Г.*) Өченче тактаны кулга алам... Әйтмиләр теге сүзне. Шулай әкрен генә куеп бетердем...

Җаным теләгән саен барып кайтам әни кабере янына. Сагынам!.. Баш очына басам да сөйлим дә сөйлим. Хатын белән улыма атлый торырга кушам да, әниемә серләремне ачам. Мин – әни малае. Гомерем буе әни малае булдым. Әти белән үскән булсам, әтинеке булган булыр идем... Бәлки, аның кул астына кереп, ярдәм иткән булыр идем, авыр вакытларда утырып сөйләшкән булыр идек. Ә болай кайгыны да, шатлыкны да, юклыкны да – бөтенесен әни белән бергә кичердек. Радиодан әниләргә багышланган җырлар җырлаганда тавышын көчлерәк ачып куям. Әни әни инде ул. Утызга җитсәң дә, кырыкка җитсәң дә, җитмешкә җитсәң дә... 91 яшендә китсә дә, бар нәрсәмне өзеп үзе белән алып китте әнә. Әни белән безнең арада Вәлиәхмәт булмады. Кара-каршы утырып: «Әни, кем соң минем әти?» – дип бер дә сорамадым. Ул үзе дә бу хакта үзе башлап сүз катмады.

Хәзер миңа 75 яшь тула. Әти сүзен әйтмичә яшәдем. Дөрес, хатынымның әтисенә әйттем. Бик хөрмәт иттем аны. Кыз сорап баргач та нәсел-нәсәбемне тикшереп интектермәде, әти турында сорамады. Ә Вәлиәхмәт абыйга карата ул вакытта да начар уйларым булмады, хәзер дә юк. Әмма ул чакта хәзерге акылым булса, сөйләшкән-аңлашкан булыр идем. Көрешергә кирәк булгандыр безгә. Утырып бер елашып алган булыр идек. Бәлки: «Ачуланма инде, Нуриәхмәт, шулай килеп чыкты... Үземнең дә гаиләм бар иде бит. Дүрт балам үсә иде», – дип әйткән булыр иде. Бер тапкыр: «Улым», – дип әйткән булса, миңа шул җитәр иде...

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА



Фото: Анна Арахамия

«БӘХЕТЛЕ КӨННӘРЕМ КҮП»



Лилия
ГӘРӘЕВА

– Нурлат районында хатын-кызлардан бердәнбер ташчы ул, – дип таныштырдылар Әлфия апа Гомәрова белән «Ел хатын-кызы» конкурсында. Мин аны штукатурчы-буяучыдыр, дисәм, ул чып-чын төзүче – кирпечләрдән биек-биек өйләр салучы булып чыкты. Әле мичче дә икән. Безне хәзер хатын-кызларның машина-трактор, комбайн иярләүләре дә гаҗәпләндерми. Космоска очуларына да шаккатмыйбыз. Ләкин төзүче хатын-кызга карата күңелдә нindидер аерым ихтирам туды.

Рәфкать

– Мин бит артист булам дип хыялландым. Сигезне тәмамлагач, Казандагы театр училищесына укырга да кердем хәтта. Көзгә чакырып хәбәр килде. Әти белән әни генә җибәрмәде. Ә язмышлар әнә ничек булды... – моңаюын сиздермәс өчен, ул йөзен кына гөлләренә яшерә. – Элек бер белмәгән, күрмәгән кешеләр белән хат язышу гадәте бар иде. Минем фамилиям класс журналында 23 нче булып тора. Күрше авылдагы тугызынчы класста кемнең фамилиясе шушы санга туры килә, шуңа хат язасың. Без Рамазан исемле егет белән хат языша башладык.

Ике авыл арасы ерак түгел, Рамазан мотоцикл белән килгәләп тә йөри. Берсендә абыйсын да ияртә. Күрше авыл клубында бәйрәм икән, кызны да чакыралар. Ләкин Әлфияне утырткан мотоцикл клубка түгел, башка якка борыла. Унынчыны яңа гына тәмамлаган 17 яшьлек кызны шул кичтә урлый Рамазанның абыйсы. Хатка салган фотосыннан күреп, гашыйк булган, имеш...

– Китәм, – ди Әлфия. – Яратмаган кеше белән яши алмыйм.

– Кит! Ул инде сафлыгын югалткан, үзем куып җибәрдем, диячәкмен. Сиңа түгел, миңа ышаначаклар...

Ишек келәсенә үрелгән кулы һавада эленеп кала. Күз алдына әтисе белән әнисе килә. Мондый сүзне ишетү алар өчен нинди зур хурлык булачак.

– Әти кызу кеше иде. Аннан да курыктым. Рәфкать белән шулай яшәп киттек. Аның төрмәдә утырып кайткан булуын соңыннан гына белдем.

Әлфия апага үткәндәге ул авыр көннәрне барлау һич тә җиңел түгел. Өч елдан кызы Гөлназны алып, барыбер китә ул. Әгәр дә бу елларны яшәү дип атап булса...

Әлфия апаның мәктәп, яшьлек елларыннан бер генә фотосы да сакланмаган. Булмаган өчен түгел, барысын ире утка яккан өчен...

– Башкача бер дә күрешкәнебез булмаган иде, ике ел элек мин аны больницада очраттым. Ничә көн күрше палаталарда ятканбыз. Бу кешенең чәче бигрәк ак дип карап торган идем. Гафу үтенгән булды. Әллә ничә тапкыр утырып чыккан. «Синең

күз яшьләрең төште миңа», ди. Ә мин аны күптән кичердем. Бер атнадан аны җирләгәннәр...

Булмаган яшьлегем, түккән күз яшьләрем, җимерелгән хыялларым өчен инде күптән гафу иттем...

Галимҗан

Унҗиденче җәе язмышына сынау алып килсә, егерме икенче җәе бәхет бүләк итә Әлфиягә. Ул җәйдә аларның күршесе яңа йорт җиткезә. Төзүчеләр арасында кап-кара чәчле, тимер беләкле Галимҗан да була. «Менә кемгә өйләнергә кирәк сиңа», – ди егеткә әтисе Хөсәен абзый, йөгерә-йөгерә су китергән яшь ханымга ымлап.

Үзе төзүче, үзе гармунчы Галимҗанга күп кызларның күзе төшкәндер. Ә ул Әлфияне сайлый.

Кайнатасы аны шунда ук үз бригадаларына ала. Төзүче егетләр ял итәргә утырдымы, Әлфия кулына берәрсенең мастерогын алып, берәр рәт кирпеч тезеп чыга. Ошый аңа бу эш.

– Чынлап ошый иде миңа кирпеч тезү, – дип елмая каршымдагы төзүче ханым. – Кулың ята икән, әйдә, өйрән, дип, мине бер абзыйга өйрәнчек итеп билгеләделәр. Шулай әкренләп разрядларым да артты, осталык та килде. Төзелешнең иң катлаулы җиренә – почмакларга куялар иде. Усман, Халит бабайлар, Марат абыйлар, Нәҗип, Юрий Ивановичлар миңа беркемнән бер сүз әйттермәделәр. Алар арасында берданбер хатын-кыз идем.

Хәзерге төзелешләргә карыйм да, эх, тагын бераз эшләргә иде дип кызыгам. Кирпечләрне целлофанга төреп, пачкасы белән алып килеп куялар. Безнең заманда аларны башта вагоннан үзебез бушатабыз. Аннары машина әрҗәсенә төйибез. Ул төзелешкә алып килеп дөбердәтеп аудара. Кырые кителмәгән кирпечне табып та булмас иде. Хәзер төзүчеләр «уровень» белән генә эшли, бездә «отвес» иде. «Уровень» балта осталарында бар иде бит, ник куллана белмәгәнбездер. Өйне өя башлаганда бер миллиметрга ялгыштыңмы, дүртенче катка менеп җиткәнче ничә сантиметрга җыела ул! Берничә рәтне тезгәннән соң, кире сүткән чаклар да булды.

Бераз эшләгәч, бу бригададан китәргә булдым. Икең бер җирдә эшләве кыен. Кулы алтын иде Галимҗанның, ләкин холкы дуамал иде. Аның белән курыкмыйча ничек яшисең, диләр иде. Миңа бер авыр сүз әйткәне булмады. Без бик матур яшәп киттек, – дип искә ала бәхетле чакларын Әлфия апа. – Гөлназны бик яратты ул! Беренче класска укырга киткәч, мәктәпкә кадәр җилкәсенә утыртып алып бара, кич тагын җилкәсенә утыртып алып кайта. Күтәрмә, үз аягы белән йөрсен, дип ачулана идем. Кызым аны үз әтисе дип белеп үсте. Ун-унбер яшьләр булды микән, берсендә урамда үз әбисе очрап, аңа Рәфкать турында әйткән. «Синең үз әтиең бар, Галимҗан сиңа әти түгел ул», – дигән. Елап кайтып керде кызым. «Кешенең ике әтисе булмый бит, әти берәү генә була», – дип елый. «Синең дә әтиең берәү генә. Ул – Галимҗан. Урамда акылсыз карчыклар әллә нәрсә әйтерләр, тыңлама», – дидем.

Ташир

Матур гына яшәп ятканда тагын көтелмәгән хәл. Өч көн эчендә җыенып, күз күрмәгән якларга – Байкал аръягына чыгып китәргә мәҗбүр була Галимҗан белән Әлфия. Һаман да Галимҗанның дуамаллыгы инде.

– Эштә кемгәдер сукканмы, нәрсәдер әйткәнме – китмәсәк, аны утырталар иде, – ди Әлфия апа. – Халыкларны күчереп утырту буенча дәүләт программасы бар иде ул елларда. Ике вариант тәкъдим иттеләр безгә. Берсе – Бурятия, икенчесе – Монголия. Беренчесен сайладык. Бик эссе вакытлар, поездда Гөлназга салкын тидереп, Улан-Удэда больницага эләктек. Галимҗан үзе генә китте. Өч көннән безне эзләп тапты ул. Ташир дигән авылга урнашкан. «Безне кире Татарстанга озат. Монда дәваламыйлар», – дип елыйм. «Сабыр ит!» дип чыгып киткән иде, әллә министрның үзенә үк кергән инде, кич белән беренче катка чакыралар. Чыксам, таныш түгел бер ир-ат. «Нәрсә булды?» – ди. «Нәрсә булсын, баланың үпкәсе кабарган. Монда банка куялар да, шуның белән шул», – дим. «Берәр хәл булса, шалтыратыгыз», – дип, телефон номеры калдырды.

Палатага керсәм, ыгы-зыгы купкан. Табиблар йөгереп кенә йөри. Баш табиб үзе килеп җиткән...

Больницадан чыкканда тагын шул кеше каршы алды. Юлда ашарсыз дип, ризыклар алган. «Кирәге чыгар», – дип, егерме биш сум акча бирде. Таширга кадәр автобуста бик озак кайттык. Ул безне колхоз идарәсе янында төшереп калдырды. Аптырашып торабыз. Бер урамлы гына авыл. Урамның теге очына да күз карашы җитми, бу очына да... «Әти-и-ии!» – Галимҗанны беренче булып кызым күреп алды.

Бурят авылы Таширдагы тормышыбыз шулай башланды. Кунакханәгә эшкә урнаштым, Галимҗан колхозда ашлык киптерүдә эшли...

Кызык һәм без күреп ияләнмәгән тормыш иде анда. Ике гаиләгә салынган йорт бирделәр. Беренче эш итеп идәннәрен, баскычларын юып чыгардым. Күршебез дядя Юра, нишлисең, дип, исе китеп карап тора. Моңарчы идән юганны күргәне булмаган. Миннән күреп, дядя Юраның хатыны да юа башлады. Үзе юа, үзе сукрана: «Әллә кайдан килеп, миңа эш уйлап тапты бит...»

Тайга

Төшләренә гел Кондырча керә аның. Яз, имеш. Кондырча тулып ташыган да, Әрәмәле күл белән тоташкан. Нәкъ бала чактагы кебек! Әтисе Миншакир агай ишкәкле көймәне инде әзерләп тә куйган. Шау чәчәкле алмагачлар арасыннан өйләренең түбәләре генә шәйләнә. Әрәмәлектәге шомыртларда бал кортлары туе! Шуларның гөжләгән тавышына уянып та китә аннары. Уяна да, юан-юан карагач бүрәнәләргә бермәл аптырап карап ята. Юкә мунчала белән ышкып

Әлфия апа, шалтыратып, яңалыгы белән бүлеште. «Әй табигать, серле сандык» дип аталган шигъри җыентыгы дөнья күргән.

юа-юа бузарган үз өйләре түгеллеген күреп, күңеле тула. Бал кортлары дигәне дә урман кисүчеләрнең пычкы тавышы лабаса.

Балачагы исенә төшсә, җанына дәва. И рәхәт чаклар! Алты бала үстеләр. Әтиләре дөньяның бер романтигы иде. Хатынына чәчәк җыйган ир авылда бер ул гынадыр. Басудан кайтышлый кулында йә ромашкалар, йә кыңгыраулар булыр, кочак тутырып алтын башаклар өзәр. «Минҗиһан, башаклар өлгергән бит! Исләреннән исерерлек!» – дип, шатланып кайтып керер... Акыллы иде әтиләре, гадел... Иҗтимагый яклаучы итеп куйдылар үзен. Авылда ничә кешене төрмәдән коткарып калды икән ул?! Әҗәлен дә шул гаделлеге аркасында тапты бугай. Ул көнне фермадан өч сыер югала. Каракларның артларыннан барган, күрәсең. Миншакирның арба белән капланганына авылда беркем ышанмады. Эш ачыйк, дигәннәр иде, әниләре теләмәде. Тиешле җәзаны Ходай болай да бирер... Җырчы иде әниләре! Эш арасында үзалдына тын гына җырлый иде. Аның җырлаганын Әлфия сеңелләре белән качып кына тыңларга ярата иде.

Иге дә чиге дә булмаган кара урман уртасында, җиде ят халык арасында үзе дә «Галиябану»ны көйли-көйли кыр станында ашарга пешерә әнә Әлфия. Иң якын авылга да моннан 27 чакрым. Яратты бурятлар бу тырыш татарларны. Баштарак үз араларына кертмәгәннәр иде югыйсә.

– Әле кунакханәдә эшләгән вакытым иде. Бер профессор киләсе икән, ә безнең повар авырый. «Син пешер инде», – диләр. «Сезнеңчә әзерли белмим, татарча пешерсәм генә», – дим. Бәрәңге, суган, кишер таптырдым. Байкал артында мондый яшелчәләр үсми, барысы да порошок хәлендә генә. Табып китерделәр. Эчәк-бавырдан тутырма әзерләдем. Нинди аш пешергәнемне инде хәтерләмим, үзебезчә токмачлы аш булды микән. Бурятлар үзләре ашны бик куе пешерә. Кәбестә дә сала, токмач та... Кашык басып торырлык булсын аларга. Безнең ашларны бик ошатты профессор. «Кем әзерләде боларны?» – ди. Чыгып бастым. «Рәхмәт, кызым, мондый тәмле аш ашаганым булмады», – дип, кочаклап алды. Күп нәрсәләргә өйрәттем мин ул вакытта бурят хатыннарын. Иң беренчесе – чисталыкка. Ашханәдә эшли башлагач та, андагы аламалыкны күреп, Галимҗан белән ремонт ясап, юып чыгардык. Көн дә идән юуны гадәткә керттем. И сукрандылар инде. Артык эш ясыйсың, диләр, – Әлфия апаның истәлекләренә ияреп, без кабат Бурятиягә барып кайттык. – Андагы матурлыкны күрсәгез! Урман эчләрендә тугайлар. Бездә кыр чәчәкләре ничек үссә, аларда ирислар шулай. Зәп-зәңгәр тугай! Халык күбесенчә сарык асрый. Сыерлары да бар. Аларны көн дә савып, сөтен эшкәртү юк. Муенына кыңгырау асып, тайгага чыгарып җибәрәләр. Үзе шунда бозаулый, бозавы имә.

Нурлат

Байкал аръягында биш ел яшәгәч, кире үз якларыбызга кузгала Галимҗан белән Әлфия. Икенчегә бәби көтешләре!

Август җитә. Суган йолкыйсы бар дип, Әлфия апаны алты айлык улы Радик белән авылларына кайтарып куя Галимҗан. Үзе исә егетләр белән эштән соң су коенырга була.

– Трамплиннан сикергәндә башы белән бетонга төшкән, диделәр. Мин килгәндә аңында иде. Уникенче көнне күзләрен ачмады. Аңа нибары – 34, ә улыбызга алты гына ай иде... – Әлфия апа, моңсуланып, тынып кала. – Мин декретта. Кесәдә бер тиен акча юк. Баланы бакчага алмыйлар... Август аенда кызыбызның туган көне. Галимҗан ел да карбыз күтәреп кайта иде. «Әти булмагач, быел карбыз да булмас инде», – дип елый кызым. Бераз ярдәм итмәсләр микән, дип, иремнең әниләренә киттем. Мин керүгә, акча юк, дип зарлана башлаган иде, гозеремне әйтеп тә тормадым. Хәлегезне белергә генә кердем, дип, чыгып киттем. Үзем барам, үзем елыйм. Язмышка да ачу килә, безне ташлап киткәне өчен Галимҗанга да... Күршебез Вагыйзә апа мине карап тора икән. «Ник елыйсың?» – ди. «Баланың туган көненә карбыз алырга да акчам юк бит», – дим. «Вагыйзь абыең әле генә шабашкадан кайтты. Мә, балаларга сәдака булсын», – дип, 25 сум акча чыгарып бирде. Базардагы иң зур карбызны күтәреп кайттым.

Гомерем буе күршеләрем яхшы булды минем. Бер ягы китек булса, Аллаһы Тәгалә башка яктан тигезли бит ул... – күз яшьләрен сөртеп, Әлфия апа элеккечә балкып елмая.

– Улымны яслегә урнаштырып, кабат элеккеге эшемә – төзелешкә чыктым. Көндез йортлар салабыз, төнлә белән кешеләргә гаражлар төзергә китәм. Нигезеннән башлап, түбәсенә кадәр үзем ябып төзегәнем булды. Ирләрдән катырак эшли идем. Булдыра алмыйм, көчем җитми, дия алмыйм, ике баланы үстерәсем бар.

Нурлатта эшчеләргә ике урам итеп яңа йортлар салдылар. Шул йортларга өч коелы бик матур мичләр чыгардым. Бер өйрәнгәч, авырлыгы юк. Өч коелы мичне чыгаруы кыен түгел аны, борылышларын гына тигез, пөхтә итәргә кирәк.

Сагышланган, җаны үрсәләнгән көннәрдә шәһәрнең үзәк урамнарыннан урап кайтырга ярата Әлфия ханым. Аның көче кергән биналар күп биредә.

– Язмышым катлаулы булса да, бәхетсез көннәрем юк, – ди ул. Һәм күңелдән генә шигырен укып китә:

Хуш диден, мәңгегә киттең дә,
Оныттың кайтасы юлларың.
Ялгызым үтсәм дә гомерем,
Бер минут мин ялгыз булмадым.
Гел туры бармады юлларым,
Кайдадыр борылып ялгыштым.
Балалар хакына аумадым,
Тормышка ныграк ябыштым...

Әнә шундый – рухы белән көчле, күңеле белән нәфис кеше ул төзүче Әлфия.



ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫНА ЯЗЫЛГАН ӨЧЕН – СКУТЕР, ТЕЛЕВИЗОР, ЭЛЕКТРОЧАЛГЫ БЕЛӘН БЕНЗОПЫЧКЫ, СМАРТФОННАР ҺӘМ БАШКА ТЕХНИКА

Катнашу өчен гаризалар 2021 елның 20 июленә кадәр кабул ителә
Бүләкләр уйнату 2021 елның 19 августында узачак



1 ЯЗЫЛ — 2021 елның 20 июленә кадәр «ТАТМЕДИА» АҖнең бер газета һәм бер журналына язылу (акциядә катнашучы басмалар белән tatmedia.ru сайтында танышып була)


2 ҖИБӘР — «Акция» билгесен куеп, язылу квитанцияләренең копиясен безгә җибәр (телефон номерыгызны язарга онытма). Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 ОТ — Язылган өчен телевизор, электрочалгы белән бензопычкы, смартфон. Төп бүләк – скутер!



Акция турында тулырак мәгълүматны, призлар һәм аларны алу турында tatmedia.ru сайтында белеп була.
Акциянең узу вакыты: 12.05.2021–18.08.2021. Гаризалар кабул итү 20.07.2021 кадәр.
Оештыручы «ТАТМЕДИА» АҖ. Реклама 16+ Товарлар рәсемдәгеләрдән аерылырга мөмкин.

ЗӨҺРӘКӘЙ



Зөһрәкәй... Мәҗит Гафури аңа яратып, назлап әнә шулай эндәшкән. Зөһрә Камалетдин кызы Насыйрова язучының сөекле хәләл җефете генә түгел, чын дусты, якыннардан-якын кешесе дә була. Иренең авыр язмышын уртаклашып, аның белән кулга-кул тотынышып, гел янәшәсеннән атлый ул. Газизе вафатыннан соң якты дөньяда өч кенә ел яши һәм үзе дә бакыйлыкка күчә. Бу вакытта Зөһрәгә нибары 43 яшь була. Мәҗит Гафури өчен ике улының әнисе генә булмый, илһам чыганагына, саклаучы фәрештәсенә дә әверелә ул.

Фотолар: Мирсәит Гафури архивыннан.

Хатларының берсендә Гафури аңа болай дип яза: «Мин, ниһаять, менә беренче тапкыр сезне «сөекле ханым» дип атыйм. Беренче тапкыр сезгә үземнең яратуым турында белдерергә җөрьәт итәм.

Мин сезне күптән яратам, сезне, сезнең холкыгызны, атлап йөрешләрегезне күзәтәм. Күбрәк күзәткән саен, сезгә булган мәхәббәтем дә үсә, зурая бара.

Әгәр тормыш юлдашым булыгыз дигән тәкъдимемне кабул итсәгез, моны бик зур бәхеткә санар идем. Бөтен шатлыгымны сезнең белән уртаклашыр, сезнең өчен дә тугрылыклы тормыш юлдашы булыр идем. Минем хакта үзегез дә барын да беләсез: чибәр дә түгелмен, бай да. Яхшы якларым дип исә менә боларны санарга була: белемгә тартылам, тормыш итәр өчен акчаны каләм ярдәмендә эшләп табам – мин язучы...»

Шагыйрьнең чын күңелдән, ихластан язган бу хатына Зөһрә: «Мин риза!» – дип җавап бирә. 1909 елны аларның язмышлары кушыла, ә 1910 елда исә беренче уллары Әнвәр дөньяга килә.

Яшь чакта Зөһрә тегүче була. Үз заманы өчен шактый белемле, музыкаль яктан бик сәләтле туташ санала. Татар һәм башкорт халык көйләрен яратып башкара. Бигрәк тә «Зөлхиҗҗә»не еш җырлый торган була. Әти-әниләре вафатыннан соң Зөһрә үзе, аның өч апасы һәм өч абыйсы Килемдә, Суфия Тевкелевалар утарында тәрбияләнәләр (хәзерге вакытта монда Башкортстан татарларының тарихи-мәдәни үзәге урнашкан, берничә ел аны Зөһрә Камалетдин кызының туганы Альфред Насыйров җитәкләде).

Зөһрә ханым гаиләсе турында миңа Башкортстанның атказанган укытучысы, гомер буе татар теле һәм әдәбияты укыткан Бану Юныс кызы Азамаева сөйләгән иде. Аның ире фронтовик Абдулла Азамаев – Зөһрәнең олы апасы Тәүфиканың улы, ул мәктәп директоры булып эшләде. Аның хатирәләрен барлыйбыз.

Зөһрәнең әти-әнисен – атаклы тегүчеләрне Казаннан үзенең Килемдәге утарына мәгърифәтче, меценат,

Зөһрә пешергән камыр ризыклары белән самавыр артында чәй эчәргә бик яраткан Гафури.

морза хатыны Суфия Тевкелева-Җантурина чакырып китерә. «Гаиләбезнең тегүчеләре булырсыз, мин ачкан уку йортында крестьян балаларын бу һөнәргә өйрәтерсез», – ди ул аларга. Зөһрәнең әтисе – ир-ат, ә әнисе хатын-кыз кием-салымы тегә. Аларга Тевкелевларның утарыннан ерак түгел, елга буенда урнашкан кечкенә генә йортны бирәләр. Гаиләдә биш бала үсә: Тәүфика, Мәликә, Зәкия, Зөһрә, Нуретдин, Имаметдин. Бербер артлы әти-әниләре үлеп киткәч тә, Суфия ханым аларны утарда калдыра, үз тәрбиясенә ала. Тәүфикалары кияүгә чыгып, Килемдә кала, укыта. Калган балаларны морза Тевкелев Уфадагы утарларына алып кайта. Имаметдин белән Нуретдинны миллионер Кәримовлар кибетенә приказчик итеп урнаштыра. Кызлар гимназиядә укый башлыйлар. Кызларның икенчесе – Мәликәләре сәүдәгәр Гыйльметдин Кальметьевка кияүгә чыга. Революциядән соң Мәликә белән Гыйльметдиннең уллары Төркиягә китә. Гаилә башлыгы үзе күн заводына гади эшче булып эшкә урнаша. Чишмәледә яңа йорт салып чыга – шунда яши башлыйлар. Салават Юлаевка һәйкәл салган вакытта йортларын сүтәләр, Блюхер урамыннан аларга яңа фатир бирәләр. Кече кызлары Фәридә ОСОВИАХИМда – атаклы очучы, ике тапкыр Советлар Союзы Герое Муса Гәрәевта бухгалтер булып эшли. Мәликәнең олы кызын язмыш Ташкентка ук алып китә: ул анда нәшрияттә тәрҗемәче вазыйфасын башкара. Зөһрәнең апаларының тагын берсе – Зәкия шулай ук укытучы һөнәрен сайлый, ул да революциядән соң Ташкент ягына күчеп китә. Нуретдин хатыны Кәримә белән Гоголь урамында – Мәҗит Гафуриның музей-йорты каршындагы ике катлы йортның өстәге катында гомер итә. Революциядән соң Нуретдин абый гади эшче булып эшли – әрҗәләр ясый. Ә аның җәмәгате Кәримә җиңгәй тегү тегеп көн күрә. Зөһрәнең олы абыйсы Имаметдин революциядән соң шулай ук гаиләсе белән Ташкент якларына китеп бара, анда зур кибет ача.

Зөһрә Гафури исә башта беркадәр вакыт Каргалыда, аннан Уфада кызлар мәдрәсәсендә туган тел, этика дәресләрен алып бара. Соңрак Сафроновский пристань тирәсендә урнашкан рус мәктәбендә – татар-башкорт төркемендә укыта. 1921 елда аны Красноармия мәктәбенә җибәрәләр. Мәҗит Гафуриның архивында бер фото саклана: Зөһрәне анда гимназист кызлар әйләндереп алган.

Ә кичләрен Зөһрә ханым тегү машинасы артына утыра – заказлар аңа килеп кенә тора. Гаилә бюджетына шактый өлеш кертә ул шулай. Аның «Зингер» тегү машинасы бүген Уфа шәһәренең Гоголь урамы, 28 нче йортында урнашкан Мәҗит Гафуриның Мемориаль музей-йортында тора.

Замандашлары хатирәләре буенча, Зөһрә ханым бик сөйкемле, ачык йөзле, шат күңелле булган, каядыр кунакка барганда гына түгел, ә өйдә дә һәрвакыт матур киенгән. Күлмәкләрнең гел ачык төсләләрен сайлаган, калфактан йөргән, аның өстеннән ефәк ак шәл ябына торган булган.

Ул үзенең нинди зур шәхес, атаклы язучы, шагыйрь белән гомер итүен бер минутка да исеннән чыгармаган: иренең иң тугры укучысы булган, аңа иҗат итү өчен бөтен мөмкинлекләрне тудырырга тырышкан.

Шагыйрьнең улы Әнвәр Гафури үзенең истәлекләрендә менә ниләр яза:

«1926 елда әти «Кара йөзләр» повестен тәмамлады. Бүгенгедәй хәтерлим: беркөнне ул бик озак кына язып утырды, аннан каләмен куйды да, күзлеген өскә, маңгаена күтәрде. Аннан:

– Зөһрәкәй! Килче әле монда! – дип әнине чакырды. Үзе алдында яткан кәгазьләрен тәртипкә китерә башлады.

Әни почмак якта иде. Әтинең үзен чакыруын ишетүгә ул ашыгып аның янына чыкты.

– Зөһрәкәй, шатлыгымны синең белән дә бүлешәм – мин «Кара йөзләр»не тәмамладым! Шундый зур эшкә нокта куйдым! – диде әти.

– Котлыйм сине!

Әнинең чын күңелдән сөенүе бөтен йөзенә чыккан иде.

– Вакытың булса, зинһар, укы әле, – диде аңа әти. – Кычкырып укы... Фикерләреңне дә әйтерсең...

Әни өстәл янына утырды да, шунда ук кычкырып укырга кереште. Башта ул тыныч кына укыды, аннан дулкынлана башлады, тавышы калтырарга кереште... Ә инде Галимәнең акылдан шашуы турындагы урынга җиткәч, күз яшьләрен тыймады да...»

Мөселман хатын-кызының җәмгыятьтә тоткан урыны, аның язмышына төшкән сынаулар Мәҗит Гафури иҗатында шактый зур урын алып тора. Прозасында да, поэзиясендә дә: «Кара йөзләр», «Татар хатыны», «Хәерче», «Сугышчы хатыны Хәмидә»...

Җәмгыятьтә гуманизмның дәрәҗәсе хатын-кызга, картларга һәм бала-чагага карата мөнәсәбәттә ачылуы күптән барыбызга да мәгълүм инде. Мәҗит Гафури иҗатын тирәнтен өйрәнүче белгечләр менә нинди нәтиҗәләр ясый: язучы үзенең һәр әсәре белән матур, мәңгелек мәхәббәтнең үзеннән-үзе җирдән дә үсеп чыкмавын, күктән дә төшмәвен раслый. Ул – бүләк түгел, кеше аңа үзүзе белән көрәш аша килә, рухи үсеш аша.

Мәҗит Гафури «хатын-кыз мәсьәләсе»нә үзенең карашын иҗатта гына чагылдырып калмый, ә гаиләсе үрнәгендә дә күрсәтә – җәмәгатенең иҗтимагый эшчәнлеген гел хуплап тора. Сәйфи Кудаш үзе шаһит булган бер очрак турында болай дип яза:

«Февраль революциясеннән соң Уфада бик еш кына митинглар һәм җыелышлар уза башлады. Аларда без – яшьләр беркайчан ишетмәгән нәрсәләр хакында сөйлиләр. Бәхәсләр куера, төрле сәяси фиркаләр арасында көрәш башланып

PRESSA

«Тарих Мәҗиткә нинди зур бәя бирсә, Зөһрәгә дә шундый ук бәяне бирергә тиеш!»



■ Мәҗит Гафури хатыны Зөһрә һәм уллары белән. 1922 ел.

китә, шуңа да бу җыелышлар, гадәттә бик шау-шулы була иде. Кайчакта бәхәсләр шулкадәр кыза, хәтта ике як бер-берсенә урындыклар ата башлый, йодрыклар эшкә җигелә... Билгеле инде, болай итеп бәхәсләшкәндә хакыйкатьне табу бик авыр.

Видинеевский бакчасының (бүгенге Луначарский исемендәге парк) җәйге театр бинасы халык белән шыгрым тулы: кемнедер чакырып китергәннәр, кемдер кызык эзләп үзе килгән. Уфа мөселманнарының шәһәр управасына гласныйлар сайлауга әзерлек бара. Мин залга кереп кысылганда, җыелышны алып баручы пеләш башлы ир-ат чираттагы чыгыш ясаучыны игълан итте:

– Сүз Зөһрә Камалетдиновнага бирелә!

Зал шунда ук җанланып китте, кешеләр бер-берсе белән сүз алышырга керешә. Трибунага кыю гына атлап, яшь кенә ханым күтәрелде. Башына сәйлән белән чигелгән калфак кигән, аның өстеннән ак ефәк шәл бәйләгән. Ул башта залда утыручыларга игътибарлы бер караш ташлады. Аннан тамагын кырып куйды һәм дулкынланган тавыш белән сөйли башлады:

– Әгәр сезгә кемдер: «Урам буйлап ярты гәүдәле генә кеше атлап килүен күрдем», – дисә, берегез дә ышанмас иде. «Булмаганны сөйләмә!» – дип, ярты сүздән туктатыр идегез. Әгәр әңгәмәдәшегез һаман үзенекен тукыса: «Юк, күрдем!» – дисә, сез, мөгаен, аны сары йортка ук озатыр идегез. Ә мин сезгә турысын әйтәм: бу залда да җыелышның яртысы гына. Чөнки монда хатын-кызлар юк – җыелышта алар катнашмый. Революция булган көннән алып сагыз кебек һаман бер сүзне чәйнисез: хатын-кызларга ир-атлар белән бер үк хокуклар бирергә кирәк, дисез. Ә нигә соң аны бирмисез? Беләсезме нәрсә, «хатын-кыз мәсьәләсе»н хатын-кызларның үзләре катнашында гына чишеп була аны. Бөтен мөселман хатын-кызлар исеменнән сезнең бу икейөзлегегезгә каршы чыгам!

Ничек кыю менгән булса, ул трибунадан шундый бер кыюлык белән, көчле кул чабулар астында төшеп китте. Арада усал итеп, мыскыллап елмаючылар да күренде.

Җыелышны алып баручы тәнәфес игълан итүгә, бакчага Мәҗит Гафурины эзләргә чыктым. Аны халык арасыннан шунда ук күреп алдым. Әле генә чыгыш ясаган ханым белән бара иде ул. Алар икәү нәрсәдер хакында сөйләшәләр һәм рәхәтләнеп көлешәләр иде...»

Зөһрә Гафури турында Мәҗит Гафуриның туганнары да зур җылылык белән искә ала. Язучының бертуганының кызы Халидә Булатова сөйли:

– Зөһрә апаны без барыбыз да ярата идек. Ул бик чибәр иде, шат күңелле, тавышы яңгырап тора, гел шаярта, көлдерә, безгә әкиятләр сөйли. Мәктәптә балалар укытты һәм бик әйбәт тегә дә иде. Безгә кунакка килгәндә дә тегү машинасын үзе белән алып килә торган иде: аны ишегалдына куя да, үзе үк алып килгән тукымалардан безгә күлмәкләр тегәргә керешә. Бик матур һәм тиз тегә иде Зөһрә апа. Иренең туганнарын хөрмәт итте ул. Әти эштән кайтуга (Әхсән – М. Гафуриның кече энесе. – *Л. К.*) аның өстен салдырышырга, чабата бауларын чишәргә ашыга иде.

Ә замандашлары, чордашлары язучыга хәтта беркадәр көнләшү белән дә караган. Ак көнләшү белән! Язучы Зариф Бәшири истәлекләреннән:

«Мәҗит Гафури өчен Зөһрә чын дус та була белде: һәрвакыт аның кәефен күтәрергә тырышты, илһамландырды, аның иҗатын бөтен тирәнлеге белән аңлады. Мәҗитне ул хөрмәт итте, аны беркайчан да юк-бар сораулар белән борчымады, иренең уе, фикере бары тик әдәбият мәсьәләләре белән генә мәшгуль булсын дип тырышты... Татар язучылары арасында бу яктан Мәҗиткә елмайган кадәр уңыш елмайган башка берәүне дә белмим. Тагын бер кат әйтәм: тарих Мәҗиткә нинди зур бәя бирсә, Зөһрәгә дә шундый ук бәяне бирергә тиеш!»

Шагыйрьнең Зөһрәсенә булган ихлас, җылы, самими мәхәббәте аңа багышлап язган шигырьләрендә чагыла.

Зөһрәм

Көне-төне хәл җыймыйча, йөрдең
Ике авыру карап йөгереп,
Эштән кайтканда да
авырсынмый,
Рәхәтләнеп күңелле көлеп.

Керә идең, ишектән кергәндә,
Нурлы була иде йөзләрең;
Сине тагын матурлата иде
Күккә маил зәңгәр күзләрең.

Рәнҗемә инде, Зөһрәм,
мин бик озак
Авырдым бит синең кулыңда.
Чытык йөзең
һичбер күрсәтмәдең,
Абынып егылсаң да юлыңда.

Люция КАМАЕВА-ГАФУРИ,
М. Гафури исемендәге мәдәни фонд советы рәисе.
Башкортстан. Уфа шәһәре.

РЕЗИДЕНТ TMTV

БЕЗГӘ
ЯҢА
ЙОЛДЫЗ 2
КИРӘК!

ДӨНЬЯ СИНЕ ИШЕТЕРГӘ ТИЕШ!

КАСТИНГ СТАРТ АЛДЫ

WWW.TMTV.TATAR



РЕКЛАМА 6+

«БЕЗ – БЕР АЛМАНЫҢ ИКЕ ЯРТЫСЫ»



Руслан АХУНОВ, рәссам, психолог. гаилә стажы – 20 ел; өч бала атасы.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Күпләр безне – ир-атларны күзләре белән генә күрә дип саный. Нәрсәдер кичерергә дә сәләтле икәнебез турында бик азлар искә төшерә. Хәер, ир-атлар үзләре дә бу хакта әллә ни җәелеп китеп сөйләргә яратмый. Әмма психология белән якыннан таныш кеше буларак шуны әйтәм: ир-ат сезгә карап тышкы кыяфәтегезне генә түгел, бик күп башка нәрсәләрне дә күрә: кәефегез нинди булуын, күңелегездә нинди куркулар яшеренүен... Өстегездәге күлмәкнең төсе дөньяга, тирә-юньдәгеләргә мөнәсәбәтегезне чагылдыруын да күрә ул. Әйе, әйе, хатын-кыз нинди күлмәк кияргә икәнен кәефенә карап сайлый бит. Шуңа күрә хәтта буянмаган, киенмәгән, диетаның ни икәнен оныткан чакта да, тышкы кыяфәтенең төп-төгәл яртысы аның кәефе ничек булуыннан тора. Менә шуның өчен дә миннән: «Ир-атларга нинди хатын-кызлар ошый?» – дип сораганда, беләсезме, ничек җавап бирәм? Шат күңелле!

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Эрактанрак башлыйм әле. Безнең акыл һәрнәрсәне икегә бүлә: яхшы һәм начар, уң һәм сул, кайнар һәм салкын, үткәннәр һәм киләчәк... Хатын-кыз һәм Ир-ат. Әйе, без дөньяны гел капма-каршылыкларга бүләбез. Әмма тормышның төп принцибы башкача яңгырый: капма-каршылыкларны берләштереп кенә бергәлеккә, бөтенлеккә ирешергә мөмкин. Ир-ат белән хатын-кыз табышканда гына мәхәббәт туа, алар кавышканда гына дөньяга яңа сабый аваз сала. Кайгы һәм шатлыклар аша узганда гына безгә зирәклек килә...

Ир-ат белән хатын-кыз да бер алманың ике яртысы күк: үзара мөнәсәбәтләр аша бер-беребезгә «кагылганда», шомарабыз, тигезләнәбез, «энәләр» коела... Һәм без бу «тәҗрибә» аша узып бербөтенгә әйләнергә тиеш... Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була дип сорадыгыз бит әле. Ир-атка, димәк, Хатын-кызда нәрсәдер ошамый диган сүз бу. Мондый очракта бер нәрсәгә игътибар итегез: нәкъ шундый ук сыйфат үзегездә дә юкмы? Психологиядә «чагылу» диган термин бар: кайбер сыйфатларыгызны үзенә «күчереп» алып, хатын-кыз, димәк, аларны үзгәртергә кирәген күрсәтә. Сез ул кимчелекләрне күреп, алардан котылуга, хатын-кызда да аларның берсе дә калмаячак.

3 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?

– Без Зәлия белән бер туган көндә таныштык. Күрүгә күзем төште, билгеле. Әмма тышкы кыяфәтенә карап: «Актриса бугай», – дип уйладым. «Ераграк торырга кирәк», – дидем әле үз-үземә. Ә кунактан киткәндә безгә бергә чыгарга туры килде. Сүз булсын өчен генә: «Сезне радиода эшли дип әйттеләр?» – дим. Ул: «Әйе», – диде дә... китте дә барды. Берәү булса: «Әйе!» – дип җавап бирер иде. Кылану, мактану, масаюның эзе дә юк! Алай икән дидем эчтән генә... Шул мизгелдә аның эчке дөньясын күрдем бугай: дәрәҗәсен, абруен, көчен сиздем. Аннары янына радиога бардым. Төнге эфиры иде. Буш вакыты булды да, яныма чыкты. Нәрсәдер сөйләшеп, көлешеп басып тордык. Яраргa, булганыннан яхшырак күренергә тырышуын – берсен дә сизмәдем. Юк, ул моны махсус эшләмәде, Зәлия үзе шундый.

Ә аннан мин аңа... тәкъдим ясадым. Танышып ике ай узуга. Тормышның инде ачысын-төчесен икебез дә шактый татыган идек. Зәлия белән яшәп булачагын шунда ук аңладым. Аңа ышанырга мөмкин икәнен. Тәкъдимемне кире кагар диган шигем бөтенләй юк иде. «Син бүре кебек: килдең дә, күтәреп алып та киттең», – диде ул соңыннан... «Никахсыз кавышмыйбыз!» – диде Зәлия. Мин: «Ярар!» – дидем. Беркемгә хәбәр итмәдек! Мөхәммәт хәзрәт – Зәлиянең авылдашы, «Ихлас» мәчетен төзи генә иде әле. «Андый эшне тиз тоталар, әйдәгез, иртәгә үк», – диде ул. Без утырып торырлык кына урын чистартты да... Әле төзелеп тә бетмәгән мәчеттә иң беренче никах шулай итеп безгә укылды. Ул чакта бетон заводым бар иде. Хәзрәткә мәчетне төзеп бетерешергә булыштым. Сүз уңаеннан, Уфаның яңа мәчетләре төзелешенә өлешем керү дә минем өчен сөенеч.

Булачак хатыным бары тик татар кызы гына булырга тиеш иде. Миңа бит уен уйнарга түгел, бала тәрбияләргә,

аякка бастырырга кирәк иде. Яшәргә! Ә Зәлия бик кыю ул. Әнисенә дә никахыбыз турында авылга кайткач кына әйтте. Мин шул вакыт әнисенең аңа һәрвакыт бөтен нәрсәне рөхсәт итүен аңладым. Дөресрәге, аңа ышануын. Тулысынча! Ул кабул иткән карар белән килешүен. Дөньядагы иң яхшы әби – аның әнисе! Зәлиянең гаиләдә ирне бу дәрәҗәдә хөрмәт итүе дә әнисеннән килә.

4 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Әйе, күпләр шулай сайлый. Мин дә алар рәтендә бугай... Хатыным нәкъ әнием кебек үк тәмле пешерә. Тәҗрибәле психолог буларак, хатын-кызлар, сезгә шуны әйтәм: ир-ат өчен ашау-эчү, ашказаны, чынлап та, икенче урында ук тора. Ә менә беренче урынга нәрсә куясын үзегез хәл итегез. Шаярту түгел бу. Без – ир-атлар бу яктан шактый гади затлар... Әни дүрт ел урын өстендә ятты. Без өйләнешкәндә йөрми, сөйләшми диярлек иде инде. Әмма кызыбызны күрергә, кулына алып сөяргә өлгерде әле ул.

5 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Бәлки без нәкъ менә шундый чорны кичерәбездер хәзер... Мине эшсез дияргә дә була. Мондый очракта бик күп нәрсә ир-атның үз-үзен тотышыннан да тора. Аның проблемасы – башында. Хатыны акчаны күбрәк тапканга, ир үзен түбәнсетелгән итеп хис итә икән, гаиләдә аңлашылмаучанлыклар туачак. Йә алар кечкенә бала кебек бер-берсе белән ярышалар, йә җитәкләшеп мәхәббәткә таба атлыйлар. Хатыны хезмәт хакын югалтмасын өчен, ире декретка чыгучылар да бар танышлар арасында. Ярышның эзе дә юк аларда. Сизәсезме хисләренең тирәнлеген, мөнәсәбәтләренең ныклыгын?! Берәүнең дә тормышы гел бертөрле генә бармый. Аның дулкын сыман үзгәреп торуын аңласаң, яшәргә җиңелрәк: борчулар артыннан сөенеч киләсен беләсең. Әйе, барысы да узгынчы. Әмма һәрберсенең уңай ягын таба белергә кирәк. Минем дә эштән өйгә кайтып кермәгән чакларым күп булды, ә хәзергә менә күбрәк хатыным, балаларым янында. Дөньяны өр-яңадан ачам!

6 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Акча, әлбәттә. Элек башкачарак булгандыр, ә хәзер менә шулай. Әмма акча бу очракта матди байлык турында гына түгел, ә ир-атның үз-үзенә булган ышанычы, аның төплелеге, аягында нык басып торуы турында да сөйли. Димәк, гаиләне дә алып бара алачак. Бу – мәсьәләнең тышкы ягы дисәк тә була: матди ягы. Дөньяның икенче зур өлеше – рухи як та бар бит әле. Анысында беренче урында кешелеклелек тора. Һәм монда хатын-кызларның гаҗәеп сизгерлеге турында әйтергә кирәк. Аның йөрәге күпкә зуррак.

7 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?

– Әгәр ул аңа гаилә кору максатыннан карый икән, әйе, куркытадыр. Гаилә тынычлык ярата ул... Ә инде алар – хезмәттәшләр, һәм араларында ниндидер бер ярыш бар икән, бу очракта, киресенчә, хатын-кызның чибәрлеге һәм көчлелеге үзенә тартырга да мөмкин. Әмма бер нәрсә бар: тыштан көчле күренгән хатын-кызларның җанында, гадәттә, тау-тау үпкә хисләре яшеренгән була. Психолог булып эшләү дәверендә андыйлар белән байтак очраштым. Хатын-кыз көчлерәк күренгән саен, эчтәге ул таулар да зуррак, тирәнрәк. Көчле булырга кирәкми диген сүз түгел бу. Тормыш моны таләп иткәндә, көчле дә була белсен хатын-кыз, кирәк чакта – көчсез дә.

8 Шундый очракны күзаллыйк әле: ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, арыдым дип, диванда кырын ятып тора.

– Тулы суыткыч янында ачка тилмереп утыручы ир-атлар булса, улым белән без инде ул... Зәлия, иркәләп, тәмам бозып бетерде безне. Ул күп вакыт иртүк нидер әзерләп китә. Һәм безне, гадәттә: «Ашыйсыгыз килсә, суыткычны булса да ачыгыз инде», – дип ачулана. Ә без күп вакыт, карап та, анда ни барын күрмибез «Нәрсәдер бар идемени? – дип сорыйбыз икәүләп. – Котлет та бар идеме? Бәрәңге дә?» Әмма ашаудан беркайчан проблема ясаганыбыз юк. Кайчак Зәлия 12 сәгатьлек эфирдан кайта. Әллә никадәр энергия түгеп... Безнең йорт астында гына тәмле самса саталар: әниебез бик арып кайткан чакта, улым белән йөгереп кенә шунда төшеп менәбез. Хәер, бик тырышсак, үзебез дә нидер пешерә алабыз. Мәсәлән, бәрәңгене өйдә бөтен кешедән дә тәмле кыздырам. Салат ясарга да була. Әйтәм бит, ашарга юк дип кайберәүләрдәге кебек тавыш чыкканы юк. Зәлия аш-суга бик оста. Татар милли ризыкларын еш әзерләргә тырыша. Бәлешенең ничек тәмле икәнен белсәгез!

9 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар соңга калучан.

– Ә бездә киресенчә: Зәлия җыенып бетә дә мине көтә. Әйтик, менә бакчага китәргә әзерләнәбез. Син әле уйларга да өлгермисең, ул инде унлап кәрзинне ишек төбенә китереп тезә. «Аны алдыңмы?» – дим. «Алдым!» «Моны?» «Алдым!» Берничә көнен һәрвакыт алдан планлаштырып яши торган кеше ул. Бәлки шуңадыр, аның янәшәсендә онытылам, таркауланам. Чит илгә үзем генә чыкканда бөтен нәрсәне беләм, онытмыйм. Ә Зәлия янәшәмдә булса... Кая барам, ничек барам, нәрсәгә – миннән сорамасалар хәерлерәк! Зәлия – бик яхшы җитәкче, оештыручы. Башкортстанда ул уздырган «Татар кызы» бәйгесе үзе генә дә ни тора!

10 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.

– Зәлиянең ялгышканы юк. Алай гына да түгел, аның һәр бүләге сюрприз! Кайтып-кайтып сөйли торган. Соңгы туган көнемдә ул, мәсәлән, нәкъ мин дөньяга килгән көнне чыккан «Правда» газетасы санын тапкан иде. Мәскәүдән! Төп нөсхә! Син аваз салган көнне илдә ниләр булуы хакында уку шундый кызык икән. Ә юбилеемда җырлавы! Өстәвенә, французча! Ничә еллар бергә яшәгәннән соң шулай шаккаттырды. Минем дә аны гаҗәпләндергәнем бар. Бер елны «Туган көнең белән, кадерлем!» дип язган банерга заказ бирдем. Уфадан чыккан үзәк урамда! Нидер хакында сөйләшә-сөйләшә баланы бакчага илтергә барабыз һәм ул көтмәгәндә банерда үзен күреп алды! Ике атнага дип түләгән идем, ә банерны эшләүче фирма дизайнерлары Зәлиянең фоторәсемен бик яраттылар һәм... ай ярым алмадылар.

Тулысынча укыгыз »





Кайчагында баланың тәненә ак яки алсу төстәге вак-вак төерчекләр чыга. Күбесенчә 2 яшьтән алып 6 яшькәчә балаларда күзәтелә ул. Яшүсмерләрдә дә очраштыргалый. Контагиозлы моллюск чире башлануын күрсәтүче билге булуы ихтимал аның. Татарстанның атказанган табибы, балалар дерматовенерологы, Республика клиник тире-венерология диспансерының профилактика бүлеге мөдире Нурислам ГАЙФУЛЛИН белән шул хакта сөйләшәбез.

КОНТАГИОЗЛЫ МОЛЛЮСК

Контагиозлы моллюск – балалар арасында киң таралган йогышлы авыруларның берсе. Төп сәбәбе – вируслы инфекция. Аның белән төрле яшьтәге һәм төрле җенестәге балалар авырый. Иң күп авыру очраклары – 2 яшьтән алып 6 яшькәчә балалар арасында. Яшүсмерләрдә, олыларда, хәтта өлкән яшьтәгеләрдә дә күзәтелә. Бер яшькә кадәрге балаларда очрамый диярлек. Бу, башлыча, сабыйларда әниләреннән күчкән антитәнчекләр булу белән аңлатыла.

Вирусның инкубацион чоры – ике атнадан алып ярты елга кадәр. Тән тиресенә эләккәннән соң әнә шуның кадәр вакыт ул үзен сиздермәскә мөмкин.

Беренче һәм иң төп билгесе – тән тиресендә төерләр барлыкка килү. Күп очракта ул бит, муен, җилкәләр, култык асты, беләзек тиресен зарарлый. Чабырган урын кызарырга, кычытырга мөмкин. Кашыганда зарарланган тире аша икенчел инфекция керү куркынычы да зур. Кайчагында контагиозлы моллюск баланың күз кабакларына да чыга. Мондый очракта конъюнктивит башланып китүе ихтимал.

Дөрес диагноз кую катлаулы түгел. Тәҗрибәле табиблар аны шунда ук ачыклый. Ләкин төгәллек өчен, тән тиресенең чабырган урыныннан материал алынып, микроскоп аша тикшерелергә мөмкин.

Бүгенге көндә контагиозлы моллюскка карата махсус дәвалау чаралары юк. Еш кына организм вирусны үзеннән-үзе юк итәргә сәләтле. Моллюсклардан арыну вакыты бер елга кадәр барырга мөмкин. Организмның вирусны юк итәргә көче җитмәсә, төерләр күп булса, хирургия ысулы кулланыла, төерчекләр механик ысул белән алына. Сирәк кенә лазер яисә сыек азот кулланыла. Ләкин мондый процедуралардан соң биттә эзләр калырга мөмкин. Тиренең чабыруын химик чаралар белән дә бетерергә була. Бу вирусның үзен юк итми, ләкин аның алга таба үрчүен туктата.



Ничек йога:



- тиредән тирегә тыгыз контакт вакытында;
- авыру кешенең мунчаласын, сөлгесен кулланганда;
- кием-салым һәм урын-җир аша;
- авыру баланың уенчыкларыннан;
- уртак савыт-саба аркылы.



Ничек булдырмый калырга:

- баланың кулларын гел юдырып торырга. Әлеге гади һәм җиңел ысул вирусның таралуын киметә;
- тән тиресенең чабырган урыннарына кагылмаска;
- шәхси гигиена таләпләренә җитди карарга – кеше мунчаласын, сөлгесен, тарагын, урын-җирен файдаланмаска;
- кеше киемен кимәскә.

Фото: www.pixabay.com

Билгеләре:

- тәндә төерчекләр барлыкка килә;
- әлеге төерчекләр аксыл яки сыек алсу төстә;
- төерчекләрнең зурлыгы 6 мм тирәсе, баштагы мәлдә алар вак була, тиз зураялар;
- тәннән чак кына калкып торалар;
- төерчекнең уртасы батынкы, кыл уртасында аксыл ноктасы бар;
- сытканда, төерчек эченнән эремчеккә охшаш бөлендек чыга;
- чабырган урын кайчак кычыта һәм ялкынсына.





Үзендә әлеге проблема булуын кеше күп еллар сизмәскә дә мөмкин. Гадәттә, бу аның үзенә түгел, ә якыннарына кыенлык тудыра. Сүзебез – гырлау турында. Ул нилектән була, дәвалау мөмкинме? Казан шәһәренең 16 нчы клиник хастаханәсе табибы, отоларинголог Фидель ЗИННУРОВ әнә шул сорауларга җавап бирә.

ГЫРЛЫЙСЫЗМЫ?

Гырлау – йоклаган вакытта кешенең түбән ешлыктагы тирбәнешле тавыш чыгаруы. Кайчагында бу тавыш 100 децибелга кадәр үк җитәргә мөмкин. Иң кызыгы – гырлаганын кеше үзе сизми. Табибка мөрәҗәгать итәргә аны күбесенчә туганнары, якыннары мәҗбүр итә. Йоклаганда гырлау – гаять киң таралган күренешләрнең берсе. 60 яшьтән өлкәнрәкләр арасында мондый халәттән интегүчеләр 60–65 процентны тәшкил итә. Гаиләдәгеләрнең төнге тынычлыгын алучы бу патологик тавышны йоклаган вакытта кече тел һәм аңкау мускулларының йомшаруы китереп чыгара. Моның сәбәпләре күп. Бик нык арыганда, тынычландыра торган дарулар, исерткеч эчемлекләр кулланганда моңарчы гырламый торган кешедә дә күзәтелергә мөмкин ул.

Күпләр аңа әллә ни игътибар итмәскә тырыша. Ләкин әлеге патологик процессның организм өчен җитди проблемалар китереп чыгаруы да ихтимал. Иң куркынычы – апноэ, ягъни йоклаган вакытта тын алу тукталып тору. Мондый вакытта гырлау кинәт тынып тора. Сулыш тукталып берничә секунд узуга, тын юллары мускулларына команда бирү өчен баш мие уяна. Бу хәл төн дәвамында йөзәр тапкыр кабатланырга мөмкин. Нәтиҗәдә, баш мие тиешенчә ял итми. Гырлау даимигә әйләнсә, кеше йокыдан талчыгып, хәлсезләнеп уянса, баш авырту, гел йокы килүдән зарланса, табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Еш кына ул сулыш органнары һәм казналыктагы төрле патологияләргә бәйле була. Сәбәбен ачыклап, тиешле дәвалау узганнан соң гырлау да юкка чыга. Бу аеруча яшь кешеләргә кагыла.

Гырлауны дәвалау беренче чиратта сулыш органнары чирләрен һәм стоматологик проблемаларны – казналыктагы, авыз куышлыгындагы тайпылышларны хәл итүгә кайтып кала. Шуның өчен дә гырлаудан интегүче кеше отоларинголог, стоматолог һәм сомнолог күзәтүендә булырга тиеш.

Сомнолог махсус аппаратлар ярдәмендә йоклаган вакытта кешенең кайсы мускуллары ничек эшләвен, баш миенә никадәр кислород килүен, башка күрсәткечләрне тикшерә.

Профилактика:
- борын белән сулауны җайга салу;
- авырлыкны нормада тоту;
- лор-органнарның чирләрен вакытында дәвалау;
- йокы һәм ял режимын үтәү;
- исерткеч эчемлекләр белән мавыкмау;
- тынычландыра торган даруларны үз белдегең белән кулланмау;
- эчке секреция бизләре авыруларын кисәтү.

Бу мөһим:
гырлау аркасында йоклаганда тын алу тукталу – апноэ күзәтелергә мөмкин. Кеше 10–30 секунд сулыш алмый тора.
Апноэ – организм өчен бик куркыныч халәт. Бу вакытта баш миенә, йөрәккә, башка органнарга кислород килү туктый, гипоксия баш-лана.
Сирәк очракларда үлемгә үк китерергә мөмкин.

Сәбәпләре:
- борындагы полиплар, кисталар;
- аллергия аркасында тын юллары, авыз һәм борын куышлыгының ялкынсынуы;
- аденоидлар (аеруча балаларда);
- кече телнең озын булуы;
- борын бүлгесенең авышуы;
- аңкау төзелешендә булган патологияләр;
- йоткылыкның тараюы;
- макроглоссия (телнең зураюы);
- тын юлларында барлыкка килгән шешләр;
- артык авырлык;
- йоткылык мускулларының хәлсезлеге;
- тынычландыручы препаратлар кабул итү;
- эндокрин система авырулары.



ГӨЛБАКЧА БИЗӘКЛӘРЕ

Июль – җәйнең иң купшы ае. Түтәлләрдә – яшелчәләр, агачларда җимешләр өлгерә, ә гөлбакчада күз явын алырлык күпьеллык чәчәкләр таҗ кергеген ача. Чәчәкләрнең матурлыгыннан озаграк хушланыр өчен нинди тылсымлы чаралар кулланырга икән? Кайсын кайчан күчерергә, кайчан туклантырырга? Бу сәхифәбез шул хакта.



Лаләләр, нәркисләр

Июнь аенда өлгермәгән булсагыз, лаләләрнең суганчаларын хәзер казып алырга кирәк. Монда көрәк урынына сәнәк куллану отышлырак. Көрәк белән казыганда суганчалар зарарланырга мөмкин. Яфраклары корыгач, нәркисләрнең дә суганчаларын казып алырга була. Гадәттә, аларның урынын һәр өч-дүрт ел саен алыштырып торалар. Суганчаларны киптереп, август, сентябрь аенда яңа урынга утырталар.

Розалар



Бу гөлләрне бакча патшабикәсе дип юкка гына атамыйлар. Июль аенда аларның матурлыгыннан башлар әйләнерлек. Купшылыкларын югалтмасыннар өчен, чәчәк атып бетергән бөреләрне, корыган яфракларны вакытында өзеп, ашлап, су сибеп тору мөһим. Суны бер куакка бер чиләк чамасы сибәргә кирәк.

Вакытында туклантырып торып, розаларның чәчәк ату чорын озайтырга мөмкин. Язын үсемлеккә үсәргә стартны азотлы ашламалар бирсә, чәчәк бөреләре формалашканда аңа фосфор, калий кирәк. Ә чәчәк ата башлаган чорда ул магнийга мохтаҗ. Магний чәчәкләргә җетелек өсти. Тимер исә төрле авырулардан профилактика булып тора.

✓ *Кадерле укучыларыбыз! «Сөембикә» журналы сайтында яңа фотоконкурс игълан итәбез. Бакчагызның иң матур, ямьле, күзләрне иркәләүче почмакларын фотога төшереп безгә юллагыз.*
Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт. «Сөембикә» журналы редакциясе.
Электрон адресыбыз: ssuum@yandex.ru яисә suumbike@tatmedia.com
Конкурсның нигезләмәсе – сайтта: www.syuyumbike.ru
Нәтиҗәләр сентябрьдә ясалачак. Җиңүчеләрне бүләк көтә!



Гортензияләр

Гортензияне Япониядә «суны юксынучы» дип атыйлар икән. Әлеге үсемлек дымны ярата. Суны еш һәм артык күп итмичә сибәргә кирәк аңа. Чәчәк бөреләре күренә башлагач, роза кебек, аны да фосфорлы һәм калийлы ашлама белән ашлыйлар. 15 литр суга 20 г суперфосфат һәм 20 г калий алына. Гортензия әче туфракны ярата. Туфрак селтеле булса, ул бөтенләй чәчәк атмаска мөмкин. Туфракның әчелеген лимон кислотасы, аш серкәсе (уксус), янтарь кислотасы белән арттырырга була. Лимон кислотасы 10 литр суга 1 чәй кашыгы алына. Аш серкәсе (9 процентлы) 10 литрга 100 г күләмендә салына. Моны сезонга бер тапкыр гына сибәләр.

Пионнар

Июль аенда пионнар инде чәчәк атып бетергән була. Ләкин бу аларны тәрбияләргә кирәкми дигән сүз түгел. Иң беренче эш итеп, чәчәкләрен койган барлык касәләрне дә өзеп чыгабыз. Орлык өлгертү өчен үсемлек барлык көчен сарыф итәчәк. Күпләр чалмабашның сабакларын чәчәк атып бетерү белән төптән кисеп ташлый. Болай эшләргә ярамый. Киләсе елга чәчәк бөреләре формалашсын өчен, аңа әле бу сабаклар бик кирәк. Авырулардан, корткычлардан саклар өчен, үсемлекне 1 процентлы бордос сыекчасы белән эшкәртәбез. Моның өчен 1 литр кайнар суга 100 г бакыр купоросы, 1 литр салкын суга 100 г известь салып эретелә. Һәр ике савыттагы эремәне 5 литрга җиткезеп, известьлы суны сөзәргә һәм аңа бакыр купоросы эремәсе өстәргә кирәк. Бордос сыекчасы әзерләнгән көнне үк кулланыла.

Үрчетү


Июль ае роза, сирень, гортензияләрне ботактан үрчетү өчен дә яхшы вакыт. Тамырландыру өчен сайлаган ботаклар артык яшь тә, бик карт та булмасын. Ачылмаган берничә чәчәк бөресе булган ботаклар тизрәк тамырлана. Көннәр коры торса, кичтән үсемлеккә яхшылап су сибегез, ботаклар дымга тулышсын. Тамырландырасы ботакның аскы очын нәкъ яфрак астыннан 45 градуслы почмак белән кисәләр. Өске очы исә соңгы яфрактан 1 см биектәрәк булсын. Аны да почмаклап киссәң яхшырак. Яфракларны яртылаш кисеп кыскартырга кирәк. Әзерләгән ботакларны сулы банкага яки дымлы җиргә утыртып тамырландыралар. Җиргә утырткан очракта, тамырланганчы, банка белән каплап торырга кирәк. Туфракка утыртыр алдыннан «Корневин»ише бирәр стимулятор кулланнсаң яхшы.

Фото: www.pixabay.com



ҖӘЙГЕ МАКИЯЖ

Җәйге кояш, яшеллек һәрвакыт кәефне күтәрә. Шуңа да җәй көне аеруча матур булып йөрисебез килә. Күлмәкләр, босоножкалар киябез. Бу чорда кояшта кызган биткә дә тәрбия кирәк. Җәй көне гадәттә макияжсыз йөрергә тырышабыз. Әмма мөһим очрашуларга әзерләнгәндә бизәнми мөмкин түгел. Битнең камил матурлыгыннан чыгып бәя бирәләр бит хатын-кызга. «Җәйге макияж җиңелчә һәм гади булырга тиеш. Җылы һәм нәфис, үтә күренмәле төсләр гаммасы куллану отышлы булыр», – ди визажист Ләйсән ХӘЙДӘРОВА. Җәй – ирек һәм табигыйлек чоры бит.



✔ Макияжны бит тиресен чистартудан башлыйбыз. Тоникта чылатылган мамык дисклар белән битне сөрткәннән соң дымландыра торган крем йә мист кулланабыз.

✔ Җәй өчен тональ кремнар авыр. Шуңа күрә текстурасы җиңел булган ВВ-крем сөртергә киңәш итәм. Ул бит тиресе тонында һәм SPF фактор дәрәҗәсе югары булырга тиеш. Шул чакта гына крем ультрашәмәхә нурлардан саклаячак. ВВ-кремны пумала белән сөртсәгез, тигез ятар.

✔ Күз төпләрендәге сорылыкны бетерер өчен, әз генә консилер тидерәбез. Ул бит төсеннән берәр тонга яктырак булырга тиеш.

✔ Битне коррекциялибез. Моның өчен бит тиресеннән караңгырак тондагы корректор кулланабыз. Йөзегез кояшта каралган булса, бронзатор куллану да кулай. Аны яңак сөяге астына һәм маңгайга зур пумала белән сөртәбез. Корректор белән бронзаторны бутап сөртсәң, бит төсенә акцент ясалачак. Бит алмаларына румяна тидерәбез. Җәйге макияж өчен алсу, шәфталу төсендәгеләрне сайлагыз. Ул кызынган биткә сафлык өсти. Яңак сөяге өстенә һәм борын очына, каш астына пумала ярдәмендә җиңелчә генә хайлайтер сөртәбез. Өске ирен өстенә сөртсәгез, иреннәрегез күперенке булып күренер. Җәй көне бит тирли, шуңа күрә хайлайтер белән артык мавыкмагыз. Кершәнне битнең Т-зонасына сөртәбез – ул зонага маңгай, борын һәм ияк керә.

✔ Каш сирәк булса, махсус карандаш-маркер белән буяп алабыз. Аннан соң каштагы төкләрне өскә күтәртә-күтәртә гель сөртәбез.

✔ Җәйге макияжда крем кебек тень кулланырга киңәш итәм. Аны бармак белән күз кабагына сөртәбез. Аскы керфекләр тирәсенә кечкенә пумала белән тидерәбез. Җәйге макияжда «нюд» төсләрен куллану уңышлы булыр. Бераздан коры тень сөртеп, ныгытып куябыз. Болай эшләгәндә тень көне буе торыр. Күз кабакларына ачык төсләр сөртәбез, караш ачык булсын өчен, күз сөяге буйлап корректор тидерәбез.

✔ Өске керфекләр төбенә көрән төстәге карандаш сөртәбез. Бу – керфекне куе итеп күрсәтү өчен лайфхак. Карандаш төсе нәкъ менә көрән төстә булырга тиеш, җәйге макияжда кара төс кулланмыйлар.

✔ Иннек сөртер алдыннан иренне карандаш белән буяп чыгабыз. Болай эшләгәндә иннек озак торыр. Ирен күпереп торсын өчен, ирен уртасына сыек иннек сөртү дә җитә. Җәй көне ачык, җиләк-җимеш төсендәге төсләр кулланыгыз.

✔ Биткә мист сиптереп, макияжны ныгытабыз.



QR-код аша кереп, видеодан да карый аласыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.

Чират – балконга

Йортның кайсы елда салынган булуына карамастан, балконсыз фатирны күз алдына китерү мөмкин түгел. Ни дисәк тә, бик файдалы урын инде ул. Яңа йортларда аны иркен итеп ясыйлар хәзер – үзе бер бүлмә кадәр. Менә шул мәйданга еш кына чират җитми кала түгелме соң? Хыялда йөртелгән җыйнак, чиста, заманча балкон идеяләрен тормышка ашырырга өлгермибез дә кайвакыт: фатирны сатып, яңасын алып куябыз.
Җәй – балконда тәртип кертер өчен иң кулай вакыт. Бу чорны балкон файдасына дөрес куллану серләре белән балкон яңарту эшләре буенча баш инженер Игорь ВЫШЕНСКИЙ бүлешә. «Кул җитмәс» балконны ничек үзгәртеп, яңартып була? Нинди шартларны үтәү зарур? Нинди заказларга сорау зур хәзер? Җавапны бергәләп эзлик. Балконга чират җитте!





Алсу ШАКИРОВА әзерләде.
Фото: Игорь Вышенскийның эш архивыннан.

Бүгенге трендларны исәпкә алганда, балконны өстәмә мәйдан итеп куллануга ихтыяҗ зур. Фатир бәяләре арткан саен, булган мәйданны файдалы кулланырга, аны тагын да зурайтырга омтылабыз. Яңа фатирларда, гомумән, балкон яки лоджия 5–10 квадрат метрга кадәр була. Бу кадәр мәйданны буш яткыру яки артык-портык әйберләр белән тутыру, әлбәттә, дөрес түгел. Хуҗаның ихтыяҗларын, акча мөмкинлекләрен исәптә тотып, балкон яңарту өчен берничә вариант тәкъдим итәргә мөмкин.

Иң гадие – булган балконны заманча тышлап, буяп, әйбер саклау урыннары, шкафлар ясап, матур бер кыяфәткә китерү. Болай эшләгәндә балконны үзгәртәсе, сүтәсе дә юк. Стеналарны вагонка тактасы яисә декоратив таш белән тышларга була. Балкон өчен төзелеш материаллары сыйфатлы булырга тиеш. Чөнки алар агрессив мохиттә сынала, аларга төрле һава торышы йогынты ясый. Буяу, ташлар, такталар сайлаганда белгечләр шушы үзенчәлекне күздә тотып эшли. Хәтта такталарны ике атна дәвамында фатир эчендә киптерергә киңәш итеلә.





Тәрәзә рамнарын алыштыру да балконга бөтенләй башка төсмер кертә. Балконның ике башына шкафлар урнаштырып, артык савыт-саба, инструментларны сыйдырырга була. Балкон да һәрвакыт чиста, җыелган булып күренер. Бу рәвешле эшләнгән балкон җылытылмый, салкын булып кала.

Балконга карата планнарыгыз зуррак та булырга мөмкин. Алдарак әйткәнчә, хәзер балконны җылытып, бүлмәгә тоташтыруга яисә аерым бүлмә ясауга ихтыяҗ зур. Бу вариант чыгымлырак, әлбәттә. Һәрхәлдә, тагын бер бүлмәгә зуррак фатир алудан бик күпкә арзанрак. Ләкин бу эшләрне башкару зур җаваплылык сорый. Бары тик сыналган, ышанычлы оешмалар гына мондый катлаулы эшне дөрес башкарып чыга. Иң мөһиме – бу эшләрне махсуслашкан оешмалардан рөхсәт алган очракта гына башларга мөмкин (БТИ хезмәте, архитекторлар, администрация рөхсәте).



Балконнан аерым эш бүлмәсе, ял итү урыны ясарга теләсәгез, аны җылытырга туры килә. Балконны җылытуда барлыгы 15 төрле позициядән торган эшләр исемлеге бар. Технологик процессларны дөрес башкарырга, этапларын төгәл эшләргә кирәк. Шул очракта гына балконны боз катудан, күгәрүдән, диварлар ярылудан сакларга мөмкин.

Фатир эчендә саклау урыннары, шкафлар җитәрлек булса, балконга шкаф кебек корылмалар урнаштыру кирәкми. Ике ягына уңайлы кәнәфи, гамак, бер кеше сыярлык ятып ял итү урыны да сыйдырырга була. Кичләрен яндырып куяр өчен, җыйнак кына лампалар кулланыгыз, бәләкәй җәймәләр, зур булмаган чәй өстәле җайларга мөмкин. Балкон тәрәзәсе артында хозурланырлык күренеш ачылса, тәрәзәләрен киңәйтеп, астан өскә кадәрле итеп ясарга була. Мондый алым мәйданны зурайта, киртәләрне бетерү эффекты тудыра.



Балконны җылытканда фатир белән тоташкан дивардан кала, барлык корылмалар да җылытыла. Шул исәптән, идәннәрне дә электр белән җылытыла торган итеп ясау зарур. Фатирыгыз яңа булган очракта да хәтта тәрәзәдәге стеклопакет та сыйфатлыракка алышынырга тиеш. Балконны шушы рәвешле бар яктан да җылыту алга таба ягулыкка экономия ясарга ярдәм итәчәк.

Балконны кухняга яисә бүлмәгә кушып куяр өчен, тәрәзә асты блогын сүтеп алалар. Ләкин бу эшне панель йортларда эшләп булмый, әлеге блок конструкцияне тотып торуда мөһим роль уйный. Тәрәзә астын сүтеп алу мөмкин булган очракта балкон белән бүлмә арасына ике якка этеп ачыла торган зур пыяла ишекләр куярга була. Болай эшләү җылылык контурын бозмый, рөхсәт алу да таләп ителми. Ләкин диварлар ярылмасын дисәгез, эшне тәҗрибәле, ышанычлы оешмалар башкарырга тиеш.

AELITA ROOMS
8-987-228-29-99
@aelita_rooms
/ авторские шторы / люстры /
/ дизайн-проект / карнизы /
/ производство мебели /
Мы переехали. Ждем вас по адресу:
г. Казань, ул. Родины, 24 Б
РЕКЛАМА

«Сөтлекәй» торты

«Аш-су» сәхифәбезнең бүгенге кунагы – Гөлназ ГАБДРАХМАНОВА. Һөнәре белән – СММ-белгеч, тормышта – яшь килен, ә җан таләбе буенча – тәмле ризыклар әзерләп, белгәнен башкалар белән дә уртаклашучы блогер ул. Төрледән-төрле рецептларны сынап, аларга үзенчәлекле төсмерләр өстәргә электән үк яраткан. Кулинар осталыкта ире Рүзәл дә калышмый, бергәләшеп пешеренү тагын да кызыклырак бит! Яшь гаиләнең уртак мавыгуы бу гына түгел, агачтан төрле эшләнмәләр ясау белән дә шөгыльләнә алар. Гөлназның фудблогер булып китүе әле яңа гына, ләкин шушы кыска вакытта инде аның сәхифәсен дүрт меңнән артык кеше күзәтеп бара. «Камыр ризыклары, десертларга өстенлек бирәм, – ди ул. – Десертлар әзерләү иҗат кебек үк бик мавыктыргыч. Монда тәмнәр генә түгел, төсләр дә ярашырга һәм күзне иркәләргә тиеш. Булган рецептларны төрлечә үзгәртергә, берәр төрле яңалык кертергә тырышам. «Молочная девочка» дип аталучы бик популяр әлеге тортка да мин җәй сые – җиләкләр өстәдем. Виктория җиләге урынына кура, мүк җиләге, кара җиләк алырга була. Җиләк-җимеш үзенчәлекле тәм дә бирә, тортны бизәп тә җибәрә». Баксаң, бу десертны әзерләве бер дә катлаулы түгел икән. Берничә кечкенә генә серен белсәң, һәркемнең дә уңышлы килеп чыгачак. Әзерләп карыйбызмы?



Кирәк (коржлар өчен)

- 2 йомырка;
- 400 мл куертылган сөт;
- 80 г атланмай;
- 160 г он (азрак яки күбрәк тә булырга мөмкин);
- 10 г камыр күпшәкләндергеч.

Крем өчен:

- 500 г сөт өсте (33%);
- 220 г эремчекле сыр («Творожный сыр»);
- 50–100 г шикәр оны (баллыны кем ничек ярата).
- Бизәү өчен үзегез яраткан берәр төрле җиләк (әчкелтемрәк булса, тәмлерәк).

Эш барышы

■ Тирән савытка йомырка сытабыз. Йомшарган атланмай (эретәсе түгел!), куертылган сөт салып, барысын да миксер белән туглыйбыз.

■ Он белән камыр күпшәкләндергечне бергә кушып, аз-азлап камырга сала торабыз, туктаусыз туглый торабыз. Ул коймак камырыннан чак кына куерак булырга тиеш.

■ Табага пергамент кәгазе җәеп, 18–20 сантиметрлы коймаклар салып чыгабыз. Моны форма белән башкару җайлырак. Коймаклар юка гына – ярты сантиметрлы булырга тиеш.

■ Без әзерләгән камырдан шундый 6–7 корж чыгарга тиеш.

■ Коржларны алдан ук 180–200 градуска кадәр кыздырып куйган мичтә 9–10 минут пешерәбез. Игътибар: коржларның өсте алсуланганны көтми-



без, читләре чак кына кызара башлауга ук мичтән алабыз. Суынмыйча торып, коржларны пергаменттан кубармыйбыз. Коржлар тигезле-тигезсез булса, суынганнан соң форма белән кисеп тигезлибез.

Крем әзерләү:

■ сөт өстен миксер белән яхшылап туглап күпертәбез. Ул тотрыклы булырга, кашыктан агып төшмәскә тиеш.

■ Күпертелгән сөт өстенә шикәр комы, эремчекле сыр кушып туглыйбыз.

■ җиләкне юка гына телемләп турыйбыз. Берникадәр җиләкне тортның өстен бизәргә калдырабыз. Аларын урталай гына бүләчәкбез.

Тортны җыю:

■ зур матур тәлинкәнең төбенә чак кына крем сылыйбыз. Торт шуып йөрмәсен өчен кирәк бу. Аның өстенә бер коржны куеп, мул итеп крем сылыйбыз. Корж читләтеп кенә бер рәт җиләк телемнәре тезеп чыгабыз. Аның өстенә икенче коржны куеп, шулай ук крем һәм җиләк тезәбез. Шушы рәвешле барлык коржларны да тезеп бетерәбез. Иң өскә крем сылап, җиләк белән бизибез. Калган кремны тортның кырыйларына ягабыз.

■ «Сөтлекәй» торты 1–2 сәгать суыткычта торса, тәмлерәк.

Чәйләрегез тәмле, җәйләрегез ямьле булсын!



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.



Туңдырма

Җәй челләсендә иң тансык сый – туңдырма. Ләкин кибетләрдә аның шикәрсезен табам димә. «Дөрес туклану» рубрикасының авторы Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА бу юлы безне шикәрсез генә «дөрес туңдырма» ясарга өйрәтә. Тәмле булуы өстенә, бик файдалы да әле ул.



Эремчектән һәм йомырка агыннан туңдырма

Кирәк:

- 100 г йомшак эремчек;
- 1,5 аш кашыгы коры сөт;
- 2 йомырка агы;
- тәменчә – стевия;
- 1/4 стакан 1,5% сөт;
- 1 аш кашыгы җәйге җиләкләр.

Эш барышы:

■ йомырка агын миксер белән яхшылап күпертәбез. Шуңа сак кына сөт өстибез, башка ингредиентларны кушабыз һәм коры сөт бөртекләре эреп беткәнчегә кадәр күпертүне дәвам итәбез. Куе каймак кебек масса хасил булырга тиеш. Туңдырманы пластик контейнерга салып, 4 сәгатькә туңдыргычка куябыз. Әзер булгач, өстен җиләк-җимешләр белән бизәргә мөмкин.

Бөтнекле туңдырма

Кирәк:

- 1 банка (400 мл) майлылыгы аз булган кокос сөте яисә йогырт (без кәҗә сөтеннән ясалган 4,5% лы йогырт алдык);
- 5 аш кашыгы ваклап туралган бөтнек яфрагы;
- 1/2 стакан шпинат;
- 1/2 чәй кашыгы ванилин;
- 2 аш кашыгы бал;
- 1 хөрмә җимеше;
- 30 г ачы шоколад (75% тан ким булмаганы).

Эш барышы:

■ кокос сөте яки йогыртка бөтнек, шпинат, ваниль, хөрмә җимеше һәм балны кушып, блендер белән бик яхшылап издерәбез. Бернинди төерләр дә калырга тиеш түгел;

■ Шоколадны вак-вак кисәкләргә турап, әлеге массага кушабыз һәм яхшылап катнаштырабыз;

■ туңдырманы таякчыклы эскимо өчен махсус формаларга яки контейнерга салып, төнгә туңдыргычка куеп калдырабыз;

■ әзер туңдырманы шоколад вагы белән бизәргә була.

Пестәле туңдырма

Кирәк:

- 2 өлгергән банан (туңдырылган);
- 15 г кыздырылмаган пестә (фисташка) чикләвеге;
- 150 мл су;
- бизәр һәм эченә кушар өчен бер уч пестә чикләвеге (киптерелгәне дә ярый);
- 1 чәй кашыгы ваниль порошогы.

Эш барышы:

■ 15 г чикләвекне төнгә чылатырга салып куябыз. Иртән шул чикләвекне 150 г су белән кушып, блендерда ваклатабыз – 1 стакан чамасы чикләвек сөте барлыкка килә (сөзәргә кирәкми). Без аның яртысын гына кулланачакбыз, яртысын алып куегыз;

■ бизәргә дигән чикләвектән кала, барлык ингредиентларны да чикләвек сөтенә салып, блендер белән куе каймак хәленә килгәнче издерәбез. Куерак булса, бераз чикләвек сөте өстәргә мөмкин;

■ калган чикләвекнең яртысын әзер массага кушабыз;

■ туңдырманы эскимо өчен махсус формаларда яки контейнерда туңдырабыз.

Фото: www.pixabay.com

Кысла
хатын-кыз

Кысла йолдызлыгы астында туган хатын-кызлар сизгер һәм йомшак күңелле затлар. Фантазиягә бирелеп, хыялланырга, үзләре өчен идеаль булган дөньяларына кереп китәргә яраталар. Кайвакыт аларның кәефен, эмоцияләрен аңлау кыен да булырга мөмкин. Сабыр, мәрхәмәтле, намуслы булулары белән аерылып торалар, сер саклый беләләр. Үз уйлары белән ялгызы гына тынычлыкта калырга яраталар. Шул рәвешле төрле четерекле хәлләрнең чишелешен табалар.

Мәхәббәт. Ир-атлар Кысла хатын-кызларның йомшаклыгын, хислелеген ярата. Ир-егетләрне бер караш белән гашыйк итәргә сәләтле. Кысла ярдәмгә, игътибарга мохтаҗ булып күренә белә. Шуңа күрә ирләрдә аларны саклыйсы, яклыйсы килү теләге уяна. Кыслалар тиз гашыйк булалар, партнерга тиз ияләшәләр. Ләкин мәхәббәт шаукымына бирелеп яшәвен көтмәгез. Яратуыгызны гамәлләр белән исбатласагыз, Кысланың йөрәген яулау авыр булмас.

Мөнәсәбәтләр. Тормыш итәр өчен бик тугры хатын алар. Сизгер, ир кешенең кәефен аңлап, уңай якка үзгәртергә сәләтле. Үз дөньяларына кереп китүчән булсалар да, аралашканда бик ачык кешеләр. Кыслалар белән корылган мөнәсәбәтләр тотрыклы була.

Гаилә. Кысла өчен гаиләсе һәрвакыт беренче урында. Якыннарын гаилә учагы җылысы белән әйләндереп ала, аларны яклау, саклауны төп бурычы итеп саный. Балалары да бу мохиткә кайтырга ярата, әни җылысы аларны гомер буе тартып тора. Кысланың тормыш иптәше нинди генә авырлыкларга дучар булса да, ул хәлне катлауландырмый, гаиләне һәрвакыт якларга әзер була.

Йолдызнамә
август

Кучкар. Август башында өстәмә керем, көтелмәгән эшлекле тәкъдимнәр булырга мөмкин. Ләкин яңа идеяләр белән янып йөргәндә элеккеге планнарыгыз турында онытмагыз. Янәшәдәгеләр белән бәхәс килеп чыкмасын өчен, аңлашылмаучанлыкны вакытында хәл итегез.

Үгезбозау. Августның беренче яртысында сәламәтлеккә игътибарлы булыгыз. Үз эчегезгә йомылу да хас сезгә. Бу халәттән качар өчен әлеге чорны ял итеп, сәяхәт кылып, дуслар белән аралашып үткәрегез.

Игезәкләр. Тормышыгызда үзгәрешләр күп булырга охшаган. Ләкин башта иске тормыштагы кайбер әйберләрдән арынырга кирәк. Сезгә дөрес бәя бирердәй, көчле якларыгызны күрердәй кешеләрне очратырсыз, алар киләчәк үсешегез өчен яхшы старт бирергә мөмкин.

Кысла. Уңышның яңа баскычына күтәрелерсез. Шикле проектларга вакытыгызны сарыф итүдән һәм үзегезгә матди яктан зыян салудан сакланыгыз. Акча эшли беләсез, ләкин сезгә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында финанслар өлкәсендә авырлыклар килеп чыгарга мөмкин.

Арыслан. Тау әйләндерерлек көчләр табарсыз үзегездә. Бу ай сезнең иң көчле чагыгыз, тотынган һәр эшегез дә уңышлы булыр. Күңелегез яңа офыкларга, үзгәрешләргә ашкынса да, көндәлек тормыштан читләшергә ярамый. Эштә генә түгел, мәхәббәттә дә зур җиңүләр көтә сезне.

Сөмбелә. Сезнең өчен август ае ике өлешкә бүленгән кебек булыр. Беренче яртысы бик киеренке үтәргә мөмкин, сак булыгыз. Айның икенче яртысында исә сезнең өчен бөтен ишекләр дә ачык булыр. Өстегездән авыр йөкләр төшәр, җиңеллек тоеп яшәрсез.

Бизмән. Дустанә мөнәсәбәтләр урнаштыру белән шөгыльләнер өчен уңышлы вакыт. Матурлыкка, гармониягә омтыла башларсыз. Үзегезнең тышкы кыяфәтегезгә, тән сәламәтлегенә игътибар итәр өчен кулай чор. Тормыш энергиягез болай да сүлпән хәзер, низаглы вакыйгалардан ерак торыгыз.

Чаян. Вакыйгалар агымын үз файдагызга бора аласыз. Бу мизгелне кулдан ычкындырмагыз. Сәламәтлек өчен бик файдалы булмаса да, карьера өчен август бик уңышлы ай. Яңа эш белән шөгыльләнә башласагыз, шунда ук максатка ирешүне көтмәгез. Шәхси тормышыгызны арткы планга күчереп торырга туры килер.

Укчы. Бу ай бик актив үтәр. Хаталар җибәрмәс өчен, һәр адымыгызны уйлап эшләгез. Беренче карашка катлаулы тоелган эшләрне дә иҗади җиңеллек белән башкарып чыгарсыз. Шуңа күрә коллективта да абруегыз артыр, кирәкле кешеләр белән мөнәсәбәтләрегез ныгыр.

Кәҗәмөгез. Сезнең алда бик күп яңа максатлар барлыкка килер, элеккегеләрен дә исегезгә төшерүчеләр табылыр. Алтын урталыкны тапсагыз, барлык проблемалар да уңай хәл ителер. Эш кәгазьләре белән игътибарлы булыгыз.

Сукояр. Игътибарыгызны дустанә мөнәсәбәтләргә юнәлтегез. Һәр ситуациядә компромисс табарга була. Әлеге киңәш һөнәри сферага да, шәхси тормышка да кагыла. Сезгә карата кызыксыну артыр, талантыгызны күрсәтергә мөмкинлекләр ачылыр.

Балыклар. Август сезнең өчен шактый катлаулы ай. Вакыйгалар агымына бирелсәгез, алар максатыгыздан ерак алып китәргә мөмкин. Ләкин айның икенче яртысында, үзегезне кулга алып, барлык мәсьәләләрне дә уңай хәл итәрсез.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Алсу ШАКИРОВА, Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА, Лилия ГӘРӘЕВА әзерләде.







МИЛЛИ НӘФИСЛЕК

Октябрьскийда яшәп иҗат итүче рәссам Гөлнара Фәлахова картиналарында милли нәфислек мулдан! Ә аның әсәрләренә карата тамашачылар фикере нинди соң?! «Беркемнең эшләренә дә охшамаганнар! Бик матурлар! Талантлы рәссам!», «Бик кызыклы! Хисле!», «Никадәр нәфислек!», «Нинди гүзәллек сезнең картиналарда!», «Гаҗәеп һәм могҗизаи сезнең эшләрегез!», «Шатландыралар, дулкынландыралар! Бер күрүдә гашыйк итәләр!». «Аһ, матур!», «Искиткеч талантлы сез!»… Бу соклану сүзләре үзе бер китаплык! Әмма аларга лаек булу өчен талант кына түгел, бниһая тырышлык та сорала, билгеле!

Бик кечкенәдән рәсемнәр ясый башлаган ул. Ләкин сәнгать мәктәбенә бер барып, бер бармыйча йөргән… Ошамаган кызга андагы укытулар… «Тик шулай да, мәктәпне тәмамлагач, Башкортстандагы М. Акмулла исемендәге дәүләт педагогика институтының сынлы сәнгать-графика факультетында укый башладым, – дип искә ала Гөлнара Равил кызы. – Институтта укыганда да, 2008 елда аны тәмамлагач та, төрле техникаларда ясап карадым. Минем иҗатта бер тотрыклылык бар: этника темасы белән сугарылган рәсемнәремне күңелгә сеңеп калган якты хатирәләремне барлый-барлый ясыйм. Мөгаен, балачакта алган тәрбия тәэсиредер. Мөслим районы Шуганка авылында яшәүче сөекле Фәһимә әбием минем белән гел татарча гына сөйләшә иде. Ул мине күп нәрсәгә өйрәтте.

Соңгы вакыттагы хезмәтләрем – цифралы ысул белән Procreate программасында эшләнгән. Болай ясау тиз дә, уңайлы да. Гомумән, миңа графика өлкәсе дә бик ошый! Хис-кичерешләремне күп төсләр кулланып язарга яратам. Төрле кызыклы китаплар өчен иллюстрацияләр иҗат итү дә мавыктыргыч. Иҗатның бу төренә аеруча җаваплы карыйм. Китапларны укучы кечкенә балалар, яшүсмерләр яхшы күңелле, игелекле булып үсәргә тиеш бит. Ул әсәрләр үземә дә илһам бирә! Минемчә, безнең татар халык әкиятләре – дөнья халыклары әкиятләренең матур үрнәге. Аларны бизәү – җан рәхәте!»

Гөлнара Фәлахова киездән келәмнәр иҗат итә, ул сәнгате кием-салымнарда да чагыла.

Талантлы рәссамның хезмәтләре Башкортстан һәм Татарстан күргәзмә залларында урын алган. Әсәрләре «Урал» галереясын, М. Кәрим исемендәге Яшьләр театрын, Башкортстанның М. Акмулла исемендәге дәүләт педагогика университетының сынлы сәнгать-графика факультеты музеен, Россиядәге һәм чит илләрдәге шәхси тупланмаларны бизиләр.

Башкортстанның Көнбатыш рәссамнары иҗади берлеге әгъзасы Гөлнара Равил кызы Октябрьский шәһәренең балалар сынлы сәнгать мәктәбендә укытучы булып эшли. «Һәр укытучы үзе мавыккан сәнгать юнәлешләрен алга этәрә, мин дә шулай. Максатым – кешеләрне иҗатка илһамландыру, – ди ул. – Укучыларымны һәрдаим яңа идеяләр белән мавыктырам, аларны уңышлы композицияләр төзергә өйрәтәм. Заманча язылган яңа әкиятләр бик кирәк! Бүгенге балаларга шундый әсәрләр күбрәк тә ошый». Гөлнара Равил кызының укучылары рәсемнәр дә ясый, киездән әсәрләр дә иҗат итә. Аларның Бөтенроссия күләмендәге бихисап бәйгеләрдә җиңүләре Гөлнараның талантлы педагог булуын раслый! Ул аларны милли сәнгатькә якынайта. Иҗатчының әсәрләрен башка төрки халык вәкилләре дә үз итә! «Илһамны мин тормышның үзеннән, тирә-юнемдәге иҗат кешеләреннән, табигатьтән, көйләрдән, дөньядагы төрле халыкларның мәдәниятеннән һәм мифологиясеннән алам. Проектларым өчен образлар уйларымда да туа. Рәссамнар төркеме белән бергәләп зур проектларга алыну да ошый миңа, ә кайчак бар дөньяны онытып, хыялга төренеп иҗат итәм», – ди Гөлнара.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА












ГӨЛНАРА ФӘЛАХОВА



2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ



Аршак АЛТУНЯН,
җырчы

Фото: Ксения Богданова

Аршак Алтунян – Грузиядә туган әрмән егете. Әгәр дә тышкы кыяфәтенә карамасаң, һәм аның әрмән милләтеннән булуын белмәсәң, сөйләшүен тыңлап, татар кешесе дип уйларсың. Бернинди акцентсыз, һәр аваз, һәр кушымчаны дөрес кулланып, аһәң белән сөйли. Дус-ишләре, шаяртып, «әрмән татары», дип йөртә аны. Хатыны Гөлнара белән бер малай үстерәләр.

– Миңа 6 яшь булганда, гаиләбез белән Татарстанның Биектау районы Дөбьяз авылына күченеп кайттык. Ул вакытта бары тик әрмәнчә генә белә идем. Башта – татар, аннары рус телен өйрәндем. Дөбьяз – татар авылы, бөтен дусларым татар булды. Урта белемне дә татар мәктәбендә алдым, – ди ул. – Татарча өйрәнә алмыйбыз, авыр, диючеләргә бик аптырыйм. Тормышың шушы халык арасында икән, аларның телен белмичә ничек яшәп була? Бу бит итальянча бер сүз аңламыйча Италиядә яшәгән кебек. Теләк булса, бөтен нәрсәгә өйрәнәсең. Авыр, миннән булмый диган кешедә, димәк, теләк юк.

Гаиләбез белән музыкантлар без. Мәктәптә укыганда ук төрле конкурсларда катнаша идем. Мәктәптән соң Ильяс Әүхәдиев исемендәге Казан музыка училищесында Клара Хәйретдинова классында укыдым. Шамил Әхмәтҗановтан татар халык көйләрен башкару осталыгына өйрәндем.

Аршак Алтунян исеме музыка белән кызыксынучыларга яхшы таныш. Ул – җырчы. Әрмән, рус, татар, инглиз телләрендә җырлый. Әлегә үзенең тавыш яздыру студиясен ачу һәм яңа репертуар өйрәнү белән мәшгуль. Рәшит Ваһапов исемендәге фестивальдә катнашып, быел беренче урынны алган.
Афәрин, Аршак!



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.

